– написание книги «Известные в регионах личности из татар» в двух томах (Т I. Исторические личности, Т II. Современники) (совместно с Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ);
– подготовка и издание книги «Татарские общественные объединения и их программные документы (1980-е – 2000-е гг.)» (совместно Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ);
– составление сборника «Современные татарские махалля и мечети в РФ» (совместно с Духовным Управлением РТ, РИУ и Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ);
– составление справочника «Татарские школы и школы с татарским этнокультурным компонентом в регионах РФ» (совместно с Министерством образования и науки РТ);
– написание книги «Современный сабантуй: региональный разрез» (совместно с этнографами Института истории им. Ш. Марджани АН РТ и Министерством культуры РТ);
– составление и издание справочника «Святые места у татар РФ» (совместно с Духовным Управлением РТ, РИУ и Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ);
– составление и издание справочника «Татарские населенные пункты в РФ (современная характеристика)» (совместно с Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ и институтом Татарской энциклопедии АН РТ);
– составление и издание справочника «Татарская художественная самодеятельность в регионах РФ» (совместно с Министерством культуры РТ).

Обращение Совета Всетатарского общества краеведов к краеведам и всем любителям татарской старины

Дорогие друзья!

Мы приступаем к важнейшему, общественно значимому делу – созданию современного краеведческого движения, призванного изучать и пропагандировать историю регионов и населенных пунктов, где издавна жили наши предки, продолжают жить и трудиться наши сородичи сегодня.

Скажем откровенно – история татарского народа, несмотря на значительные достижения в ее изучении в прошлом и в нынешнем столетиях, все еще известна лишь в общих чертах, многие важные ее аспекты, глубинные пласты даже не стали предметом исследования. Это и проблема древних татар, игравших выдающуюся роль в Центральной Азии, вопросы этнической истории государствообразующего народа в Улусе Джучи, татарских ханств XV–XVI вв., судьба народа в Российской империи и в советский период, а также практически лишь затронутый историками вопрос о влиянии татар, их уникальной цивилизации на соседние народы, в особенности в Восточной Европе, включая Россию, и многие другие.

Краеведческое движение, которое мы постепенно формируем, должно помочь профессиональным историкам в преодолении все еще существующих, к сожалению, в исследованиях, освещающих пройденный нашим народом длинный исторический путь, искажений и даже лжи. В том числе нам предстоит объяснить всем россиянам и мировому сообществу ту истину, которая пока еще остается скрытой – татары являются историческим народом, выступавшим в прошлом одним из формообразующих факторов на громадных просторах Евразии. И посему они имеют полное право претендовать на собственное место в сегодняшнем весьма непростом мировом процессе.

Надо иметь в виду, что мы стоим перед фундаментальными изменениями, частью которых являются урбанизационные, миграционные процессы, всеобщая информатизация общества, приводящие к коренным изменениям в расселении народов, характере трудовой деятельности. В целом, безусловно являющихся положительными названных тенденциях есть и отрицательные стороны.

В частности, существует угроза превращения татар в диаспорально расселенные городские сообщества с потерей своей территориальной протяженности. Имея в виду, что без территории нет и государственности, нам необходимо приложить все усилия не только для того, чтобы национальные сельские поселения сохранились, но и успешно приспособились к меняющимся социально-экономическим условиям, не теряя

своей издавна существующей особой роли в этнокультурном воспроизводстве. Поэтому, одной из задач краеведческого движения является показ в деталях образцов успешного сельского предпринимательства, опыта процветающих татарских сел. Через такие примеры мы должны помочь другим нашим сородичам преодолеть привитое в прошлые десятилетия, глубоко укорененное ложное представление об ущербности сельского образа жизни, о его якобы «отсталости» и «второсортности» и т.д. По этому случаю вспоминается результат одного давнего исследования, доказавшего, что труд пастуха оказался гораздо более сложным, чем рабочего конвейерного производства на КАМАЗе. Не будет лишним и напомнить: демографически человечество становится все многочисленнее и в будущем его надо будет прокормить и те группы, народы, которые смогут сохранить в своих руках земельные владения, организовать производство продуктов, в обозримой перспективе окажутся среди политически значимых общественных сил.

Если мы сможем через раскрытие истории наших населенных пунктов, регионов проживания, через объяснение того, как сельские жители, общины в прошлом самоорганизовывались и решали сообща все возникающие проблемы, сможем усилить в народе гордость за деяния предков, привьем чувство причастности к истории, к прошлому, позволяющему выстроить полноценный путь в будущее, целевая задача краеведов будет выполнена. Понятно, что это потребует от нас значительных усилий, организационного умения и деловых качеств. Но в нашем народе все это есть.

Наконец, отдельно следует сказать о создании при Всетатарском обществе краеведов специального двуязычного журнала «Туган җир/Родной край», планирующегося как ежеквартальное издание, а на начальной стадии, до накопления опыта и решения финансовых вопросов, с подготовкой двух номеров в год. Всем нам следует принять активное участие в выработке концепции данного издательского проекта. По возможности помочь в решении возникающих организационно-финансовых вопросов. Нам представляется, что Исполком ВКТ, а также руководство РТ, если с нашей стороны последует соответствующее обоснование необходимости такого издания, не откажут в поддержке данного проекта. Тем не менее, выпуск журнала, хотя и научно-популярного, является делом нелегким и без всесторонней поддержки краеведов, других любителей татарской истории, в том числе, в первую очередь, сельских предпринимателей, не может быть реализован.

Старинная татарская поговорка гласит: «Ир егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ятар» (В сердце мужчины находится оседланный конь). Нам,

как держателям национальной идентичности, следует быть готовыми дать достойный ответ на любые идеологические и иные вызовы, которые существуют сегодня и могут появиться в будущем. Как сказано в Коране, Всевышний не оставит тех, кто опирается на Него, кто сохраняет Его в душе, обеспечивая их непобедимость (Коран, Сура III, Аят 160; Сура IX, Аят 25). Но для этого мы сами должны соответствовать божественным идеалам и уметь делами доказывать наше соответствие им.

Камиль Аблязов
кандидат исторических наук,
председатель Совета ВОК

Дамир Исхаков
доктор исторических наук,
заместитель председателя ВОК

Бөтенрусия төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыятенең бюросы

1. Аблязов Камил Әлим улы – рәис, тарих фәннәре кандидаты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары, Саратов өлкәсе төбәк татар милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе, Татарстан Республикасының Саратов өлкәсендәге сәүдә-икътисад вәкиле.

2. Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы – рәиснең беренче урынбасары, тарих фәннәре кандидаты профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты Татар-болгар цивилизациясе тарихы бүлеге мөдире.

3. Габдрафиков Илдар Мәхмүт улы – рәис урынбасары, тарих фәннәре кандидаты, Р. Кузеев исемендәге тикшеренү институтының этносәясәт бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре (Уфа шәһәре).

4. Исхаков Дамир Мәүләви улы – рәис урынбасары, тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институтының баш фәнни хезмәткәре.

5. Салихов Радик Рим улы – тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты директоры урынбасары.

6. Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы – тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты директоры.

7. Закиров Ринат Зиннур улы – тарих фәннәре докторы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе.

8. Мөхәммәтшин Рәфыйк Мөхәмәтша улы – сәясәт фәннәре докторы, профессор, Россия Ислам университеты ректоры.

9. Уразаев Фәрит Язкәр улы – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты Бюросы әгъзасы, Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе җитәкчесе.

10. Бәйрәмова Фәүзия Әүхәди кызы – тарих фәннәре кандидаты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы, язучы.

11. Макаров Геннадий Михайлович – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты Керәшен татарлары һәм ногайбәкләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

12. Ситдиков Айрат Габит улы – тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең археология Институты директоры.

13. Галимов Фәнир Гыйльметдин улы – «Бөтенроссия татар авыллары» иҗтимагый оешмасының Совет рәисе.

Бөтенрусия төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыятенең советы

1. Исхаков Дамир Мәүләви улы – тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институтының баш фәнни хезмәткәре.

2. Салихов Радик Рим улы – тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты директоры урынбасары.

3. Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы – филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

4. Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы – тарих фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) Федераль университеты профессоры, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты Татар-болгар цивилизациясе тарихы бүлеге мөдире.

5. Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы – тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты директоры.

6. Измайлов Искәндәр Лерун улы – тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең археология институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

7. Ногманов Айдар Илсур улы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты Татарстан халыклары тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү бүлеге мөдире.

8. Насыйров Рафик Гомәр улы – тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының Аксубай районы мәктәп директоры.

9. Рәшитов Фрид Айни улы – тарих фәннәре докторы, профессор. Саратов шәһәре.

10. Сейдаметов Эльдар Хәлил улы – тарих фәннәре кандидаты, Кырым инжинер-педагогия университеты доценты.

11. Тычинских Зәйтүнә Аптрашит кызы – тарих фәннәре кандидаты, Себер татарларының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге җитәкчесе.

12. Шәйдуллин Рафаэль Вәли улы – тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты җитәкчесе урынбасары.

13. Йосыпов Касыйм Назыйф улы – икътисад фәннәре докторы, профессор, Русия, Татарстан һәм Башкортостан республикаларының атказанган фән эшлеклесе.

14. Габдрафиков Илдар Мәхмүт улы – тарих фәннәре кандидаты, Р. Кузеев исемендәге тикшеренү институтының этносәясәт бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре.

15. Әхмәтов Марсель Сәлах улы – география фәннәре кандидаты, доцент, Пермь татарлары аксакаллар шурасы рәисе.

16. Ислаев Фәйзелхак Габдулхак улы – тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының мәгарифне үстерү институтының тарих һәм җәмгыять белеме кафедрасы мөдире.

17. Бултачеев Ринат Әмир улы – В.Ф. Маргелов исемендәге Рязань югары һава-десант командалы училищесының чит һәм рус телләре кафедрасы доценты.

18. Сәмигулов Гаяз Хәмит улы – тарих фәннәре кандидаты, Русия антропологлары һәм этнологлары ассоциациясенең Чиләбе бүлекчәсе рәисе.

19. Кәримов Рамил Дамир улы – Самара өлкәсе Иске Ярмәк авылы һәм Камышлы районының башка татар авылларының тарихына багышланган китаплар авторы.

20. Идиатуллин Азат Корбангали улы – тарих фәннәре кандидаты, Ульян өлкәсе татарларының рухи мәдәнияте турында күп кенә монографияләр авторы.

21. Биккинин Ирек Дамир улы – Мордовия Республикасында яшәүче татарлар тарихы, мәдәнияте һәм ислам проблемаларын яктырткан күп кенә мәкаләләр авторы, Мордовиядә беренче мишәр фольклоры җыентыгын һәм Һ. Такташ шигырьләре җыентыгын төзеп бастыручы.

22. Аблязов Камил Әлим улы – тарих фәннәре кандидаты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары, Саратов өлкәсе төбәк татар милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе, Татарстан Республикасының Саратов өлкәсендәге сәүдә-икътисад вәкиле.

23. Закиров Ринат Зиннур улы – тарих фәннәре докторы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе.

24. Мөхәммәтшин Рәфыйк Мөхәмәтша улы – сәясәт фәннәре докторы, профессор, Россия Ислам университеты ректоры.

25. Уразаев Фәрит Язкәр улы – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты Бюросы әгъзасы, Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе җитәкчесе.

26. Бәйрәмова Фәүзия Әүхәди кызы – тарих фәннәре кандидаты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы, язучы.

27. Җәлил хәзрәт Фазлыев – Татарстан Республикасы Баш казые, Татарстан Республикасы Балтач районы имам-мөхтәсибе

28. Ситдиков Айрат Габит улы – тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр Акдемиясенең археология институты директоры.

29. Галимов Фәнир Гыйльметдин улы – «Бөтенроссия татар авыллары» иҗтимагый оешмасының Совет рәисе.

30. Гариф Нурулла Гыйматдин улы – тарих фәннәре кандидаты, төбәк тарихын өйрәнүче.

31. Мөхәммәтшин Җәмил Габдрәхим улы – тарих фәннәре кандидаты, Болгар музей-тыюлыгының фәнни хезмәткәре.

32. Исхаков Радик Равил улы – тарих фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының «Керәшеннәрнең һәм нагайбәкләрнең тарихын өйрәнү үзәге» өлкән фәнни хезмәткәре.

33. Зюзин Фатыйх Мөхәммәт улы – Пенза өлкәсе төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте советы рәисе.

Бөтендөнья татар конгрессының
Милли Шура рәисе
Шәйхразыев Васил Габделгаяз улына
язучы, тарих фәннәре кандидаты,
Бөтенроссия татар краеведлары
оешмасының Совет әгъзасы
Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызыннан

Мөрәҗәгать

Хөрмәтле Васил әфәнде!

Бөтендөнья татар конгрессы каршында татар төбәк тарихын (краеведлар) өйрәнүчеләр оешмасы төзелү – милләт тормышында сизелерлек вакыйга булды. Татар зыялылары бу көнгә шактый озак вакыт килделәр, шушындыйрак оешмалар узган гасырның 20-нче елларында да төзелгән булган, сәяси сәбәпләр аркасында, алар ябылуга дучар ителгән. Инде үзгәртеп кору чоры башлангач та, милли зыялылар, галимнәр, дәүләтчелек тарихы белән бергә, төбәк тарихын да өйрәнә башладылар, бөтен ил буенча авыллар, нәселләр турында китаплар язылды, шәҗәрәләр төзелде. Шулай итеп, татар төбәк тарихын өйрәнүче краеведларның зур төркеме барлыкка килде, аларны бер оешмага туплау, төрле якка сибелмичә, ачык максатлар куеп эшләргә өйрәтү көн тәртибенә килеп басты. Нәтиҗәдә, 2015 елның 29–30 октябрендә Казанда Россия татар краеведларының беренче форумы, 2016 елның 13 февралендә Татарстан Республикасы татар краеведларының оештыру корылтае, 2017 елның 24–25 мартында Казанда Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләренең 1-нче съезды булды.

Шушы корылтайда оешманың җитәкче органнары, Бюро һәм Совет та сайланды, Бөтенроссия татар краеведлары оешмасының рәисе итеп Саратов эшмәкәре Камил Әбләзев сайлап куелды. Әмма шушы көннән соң без, оешманың Совет әгъзалары, Камил әфәндене башка үз арабызда күрмәдек, ул бер тапкыр да Советны җыймады, оешманың ничек эшләве, нинди проблемалары булуы белән кызыксынмады. Камил Әбләзев хәтта 2018 елның 3–5 апрелендә Казанда үткән Татарстан Республикасы татар краеведларының киңәйтелгән форум-корылтаенда да катнашмады. Рәиснең урынбасарлары Альберт Борһанов һәм Дамир Исхаков оешманың бөтен эшен үзләре җигелеп тартырга мәҗбүр булдылар, моның өстенә «Туган җир» – «Роднон край» дип аталган татар краеведлары журналы чыга килде, яңа китапларның презентацияләре үткәрелде, урыннарга барып, төбәк тарихы буенча җыеннар, фәнни конференцияләр үткәрелде. Әмма оешма рәисенең бу эшләрдән читтә калуы, төбәк тарихчылары алдына

стратегик максатлар куеп эшләтә алмавы, матди якның һәрвакыт кискен торуы алга таба эшләрне бик нык катлауландырачак һәм тоткарлаячак.

Хөрмәтле Васил әфәнде!

Бөтендөнья татар конгрессы каршында зур авырлыклар белән татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр оешмасының төзелүе – ул милләт өчен гаять әһәмиятле эш булып тора. Бу – милләтебез өчен иң кирәкле проектларның берсе, чөнки кыйтгаларга таралган бөек татар тарихын профессиональ галимнәр генә өйрәнеп бетерә алмый, менә шундый вакытта һәвәскәр тарихчыларның ярдәме бик кирәк булачак! Хәзер бу оешмага Росиянең бөтен төбәкләреннән диярлек йөзләгән татар краеведы тартылды, Казанда арка терәге тоеп, алар тагы да дәртләнеп эшли башлады. Бу оешманы ничек тә саклап каласы иде! Ул гына да түгел, сезнең ярдәм белән тагы да җанландырып җибәрәсе иде! Рәис мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк – Камил Әбләзев я башкалар кебек җигелеп эшләсен, я китсен. Татар конгрессында краеведлар буенча бер штат та каралмаган, ул да эшне тоткарлый. «Туган җир» – «Родной край» журналын да, һичшиксез, сакларга кирәк, ул да сезнең ярдәмгә мохтаҗ. Шушы мөһим мәсьәләләр буенча безне – татар краеведларының Совет әгъзаларын бер җыеп сөйләшүегезне көтәбез.

Ихтирам белән –

язучы, тарих фәннәре кандидаты,
Бөтенроссия татар краеведлары оешмасы Совет әгъзасы
Фәүзия Бәйрәмова,
2018 ел, 27 август.

Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе Шәйхразыев Васил Габделгаяз улына – Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, тарих фәннәре кандидаты, Туган як тарихын язучылар оешмасының киңәшче төркеме әгъзасы Гариф Нурулла Гыймадетдин улыннан

ТӘКЪДИМ-МӨРӘҖӘГАТЬ

Хөрмәтле Васил әфәнде!

Бөтендөнья татар конгрессы каршында, Тарих институты белән берлектә, татар авыллары тарихын барлау, язу эшчәнлегенә бәйле төзелгән оешма милләтебез тарихын барлауда зур этәргеч бирде, һәм әйтергә кирәк, шушы чорда җирле тарихчылар тарафыннан күп эшләр эшләнде һәм эшләнә. Әмма, бу өлкәдә проблемалар, киңәшләшәсе эшләр дә бар.

Бүгенге көндә халкыбыз тарихын өйрәнүгә бәйле вазгыять шундый: Археология институты дәүләт заказларын үтәп, бары тик Зөя һәм Болгар шәһәрләре җирлегендә генә эшли. Язылган фәнни хезмәтләр бары рус телендә 50–100 тиражда басылып, архив һәм фән кешеләре арасында гына тарала Энциклопедия институты эшләгән сүзлекләр дә күп очракта, рус телендә басылып, татарча хезмәтләргә соңытын акча җитми. Тарих институтындагы вазгыятьне үзегез дә беләсездер. Анда елына 10–20 китап чыгып, аларның да 2–3 генә тарихка мөнәсәбәтле. Калганнары педагогика фәненә бәйле заказ буенча язылган хезмәтләр. Тарих институты чыгарган тарихи китаплар, сан ягыннан, җирле тарихчылар чыгарган китаплардан (ә алар сыйфат ягыннан берни белән да калышмый) дистәләрчә тапкырга кимрәк!

Шул сәбәпле, халкыбызга тарихын кайтаруда, зыялыларыбызга татар телендә язылган фәнни хезмәтләрне дөньяга чыгару өлкәсендә бердәнбер мөмкинчелек тудыручы эшчәнлек – югарыда искә алынган оешма һәм шушы оешма эшчәнлегенә бәйле чыгып килүче «Туган жир» журналы булып кала.

Авыллар тарихын өйрәнүче оешмага, съездда, җитәкче итеп, эшмәкәр Камил Әбләзев сайлап, дөресрәге сайлатып куелды. Бер төркем тарихчылар каршы булса да, бу безнең гаеп булды. Каршы чыгучыларга, Камил Әбләзевнең җитәкче буларак төп сыйфаты – акчалы кеше булуы һәм оешма канаты астында чыгачак «Туган җир» журналына акча бирәчәгенә басым ясадылар. Җитәкче сайлангач, ул үз тәкъдиме белән Бюро һәм Советка да берничә үз кешесен дә (эшләмәүчеләрне) кертте. Кабатлап әйтәм, бу безнең төп ялгышыбыз булды. Әлеге сайлау нәтиҗәсе шундый юнәлеш алды: матди ярдәм дә юк, оешма эшчәнлегендә дә активлык юк – Совет та җыелмый. Бүгенге көндә оешманы туплап, аны рухи яктан төп яшәтеп торучылар: «Туган жир» журналы һәм

оешма рәисенең урынбасарлары Дамир Исхаков һәм Альберт Борһанов тырышлыгына бәйле.

Югарыда, кыска гына рәвештә ачыклык кертергә тырышкан сәбәпләрдән чыгып, без сездән ярдәм сорыйбыз. Тарихчылар оешмасын һәм «Туган җир» журналы эшчәнлеген үз канатыгыз астына алып, оешманың эшчәнлеген җанландырып җибәрергә иде. Шушы сәбәптән безгә, сезең ярдәм белән, оешманың актив әгъзаларын җыеп сөйләшергә, фикерләшергә иде. Бәлкем оешма җитәкчесен дә алыштырырга кирәктер.

Кабатлап әйтүем, төбәкләрдә, авылларда туган як тарихын барлаучыларның күбесе актив эшли. Халкыбыз тарихын барлауда, дөньяга кайтаруда алар зур хезмәт куя. Аларга оешманың актив эшчәнлеге, ким дигәндә рухи ярдәм – теләктәшлек кирәк!

Тәкьдим-мөрәҗәгатькә игътибар итәрсез дигән фикердә калып, ихтирам белән –

язучы,
тарих фәннәре кандидаты,
***Нурулла Гариф**.*
2018 ел, 26 август.

ТӨБӘК ТАРИХЫ БУЕНЧА ФӘННИ МӘКАЛӘЛӘР

НАУЧНЫЕ ПУБЛИКАЦИИ ПО КРАЕВЕДЕНИЮ

Л.Х. Мөхәммәтҗанова

ИДЕЛ БУЕННАН СЕБЕРГӘЧӘ: «КҮР УГЛЫ» ДАСТАНЫ ТАТАРЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРӘ

«Күр углы» сюжетлы дастаннар төрекмән, үзбәк, таҗик, казакъ, каракалпак, әзәрбайҗан, төрек, аҗар, абхаз, кумык, көрд, әрмән, грузин, гарәп, һ.б. халыкларда фольклор әсәре буларак билгеле. Сюжет уртаклыклары булса да, болар һәр халыкта зур үзенчәлекләргә ия. «Кёр углы», «Кёроглы», «Кер углы», «Күр углы», «Гёр углы», «Гёроглы», «Гороглы», «Гүр углы», «Гургули», «Гургули-шо» һ.б. исемнәр белән мәгълүм дастаннарның шигърияте, стиле, күләме гаять төрле. Әмма аларны берләштерә торган, боларның күпчелеге өчен характерлы уртак яклар да бар. «Күр углы»ның төрекмән, таҗик, үзбәк, казакъ яисә әзәрбайҗан, төрек версияләре тематик яктан бер-берсе белән бәйләнмәгән дистәләгән, хәтта берничә дистә мәҗлестән (хикәяттән) гыйбарәт, бу хикәятләрне төп каһарман Күр углы һәм калган персонажлар, аларның язмышлары уртаклыгы бер әсәр итеп туплаган.

Кайбер халыкларда «Күр углы»ның популярлыгы шул кадәр зур булган, бу циклдан сюжетларның күплеге хәтта башка сюжетларны халык иҗатыннан кысрыклап та чыгарган. Әйтик, төрекмәннәрнең соңгырак чор эпик иҗатында атаклы «Алпамыш» яисә «Коркыт» цикллары очрамый, аның каравы XVII–XVIII йөзләрдән биредә милли каһарман турындагы «Күр углы» эпосы гаять киң таралган.

«Күр углы» сюжетлы дастан версияләрен шартлы рәвештә көнбатыш һәм көнчыгыш версияләр дигән ике төркемгә бүлеп карау бар. Көнбатыш версияләр дигәндә аҗар, төрек, әзәрбайҗан, ә көнбатыш версияләр дигәндә төрекмән, үзбәк, казакъ, таҗик эпик истәлекләре күздә тотыла. Төрле халыкта популярлашкан «Күр углы»ның сюжет вакыйгалары нигезендә кайчандыр булган реаль хәлләр ята, төп каһарман образы тарихи шәхескә барып тоташа. «Күр углы» – төрле халыкта фәнни яктан шактый җентекле өйрәнелгән, текстлары безнең көннәрдә кабат басып чыгарылган әсәрләрдән. Әлеге сюжетның төп вакыйгалары XVI йөз ахыры – XVII йөз башында Әзәрбәйҗан һәм Кече Азия территориясендә барган җәлә-

лидләр хәрәкәтенә бәйләп карала, бу тәңгәллекне раслый торган шактый зур материал да тупланган [Короглы: 1973. С. 134–146]. Көнбатыш версияләр көнчыгышныкыннан чынбарлык вакыйгаларын ышанычлырак яктыртулары белән күпмедер дәрәҗәдә аерылып торалар.

«Күр углы» дастанына безнең халык та битараф калмаган. Татарларга бу әсәр чагыштырмача соң – XIX йөз ахырларында язма истәлекләр аша килеп кергән. Башка халыкта беренчел чыганагы ашуг-озаннар иҗатына барып тоташкан, ягъни иң әүвәл авыз-тел әсәре булган очракта да татарлар бу әсәр белән соңрак язуга теркәлгән текстлар аша танышкан. Ашуг авызыннан язып алынган кайбер төрки версияләрнең XVIII йөз уртасында ук инде басылып та чыккан булуы турында мәгълүматлар бар. Дастан жанрында Идел буе татарлары күбрәк китаби төргә өстенлек биргән, шуңа күрә шушы сюжетка үз җирлегебездә яңа нөсхәләр барлыкка килүгә этәргечне ашуг-озаннар, ягъни чичәннәр иҗаты түгел, ә «Күр углы»ның язма текстлары биргән булу ихтималы зуррак. Шул ук вакытта Себер җирлегендә яшәүче татарларда «Күр углы»ның тел-стиле ягыннан сөйләмгә нигезләнгәне дә бар.

Дастанда сүз бара торган тарихи вакыйгаларның Идел буе татарларына һәм гомумән татарларга турыдан-туры катнашы бар дип әйтеп булмый. Халкыбыз дастанны иң беренче чиратта традицион китап культурасына омтылышы һәм әсәрнең мавыктыргыч сюжеты аркасында үз иткән, этноним, топоним, антропонимнарны үз фонетик үзенчәлекләренә яраштырып, әсәргә төрле үзгәртүләр керткән, кыскартулар ясаган, үзенә якын сюжетларга өстенлек биргән. Татар вариантлары күләме белән көнчыгыш һәм көнбатыш версияләр кебек үк зур түгел, алар белән чагыштырганда, сюжет системасы да күпкә җыйнак. Нәтиҗәдә, популяр дастанның безнең халыкка хас китаби үз версиясе хасил булган. Татар версиясе өчен иң әһәмиятлесе дә әнә шул – дастанны башкалардан үзгә рәвештә тәкъдим итү.

Шул ук вакытта уртак сюжетның тарихилыгына күзәтү ясау безнең версия-вариантларга да шактый ачыклык өстәве белән әһәмиятле. Татар вариантларында сөйләнгән вакыйгалар, биредә теркәлгән топонимик һәм антропонимик мәгълүматлар тарихи вакыйгаларга һәм башка версияләрдә чагылган эпизодларга таянып, аларга нисбәтән тикшергәндә генә бөтен тулылыгы белән ачыла. «Күр углы»ның татар вариантлары да, башка халык версияләре кебек үк, реаль вакыйгаларга бәйле булуы белән гаять дәрәҗәдә кызыклы. Үз чорында моны дастанны күчереп таратучылар да, аны укучылар да тәгаен белгән, аңлап эш иткән булырга тиеш.

«Күр углы» – версияләре шактый тирән өйрәнелгән, текстлары фәнни әйләнелешкә кертелгән дастан. Әле 1842 елда ук Лондонда А. Ходзько авторлыгында «Народная поэзия Персии» дигән китап чыгарыла. Бу китап-

ның төп өлеше нәкъ менә «Күр углы» эпосына, аның әзәрбайҗан версиясенә багышланган. 1856 елда шушы ук дастанның «Кёр Оглу. Восточный поэт-наездник» дигән исем белән инглиз теленнән рус теленә тәрҗемә ителеп бастырылуы да аерым әһәмияткә ия. Дастанның татар халкында таралган вариантлары көнчыгыш һәм көнбатыш версияләр дип карала торган төркемнәрдән һәрвакыт читтә кала килде, әлеге сюжетка бездә дә берничә нөсхәдә эпик әсәрләр сакланган булуга игътибар аз юнәлтелде.

Эпосның төрле милли версияләре күпләгән галимнәрдә зур кызыксыну уята. Татарларда «Күр углы» дастаны, аерым алганда аның В.В. Радлов тарафыннан язып алынган версиясе [Радлов: 1872. С. 258–261] турында төрекмән галиме Б.А. Каррыев [Каррыев: 1968. С. 250–254], үзебезнең галимнәребез Ф.И. Урманчеев [Урманчеев: 1984. С. 164–170], М.И. Әхмәтҗановның [Әхмәтҗанов: 2000. С. 186–192], И.Г. Закированың [Закирова: 2010. С. 371–372], Л.Х. Мөхәммәтҗанованың [Мөхәммәтҗанова: 2025] фәнни мәкаләләре мәгълүм. М. Әхмәтҗанов исә В. Радлов вариантыннан тыш «Күр углы»ның татарлардагы башка кульязма һәм басма вариантларына да әһәмият бирде, «Күр углы»ның татар дастаннары арасында һәм шул исемдәге башка халык эпосы янәшәсендә тоткан урыны турында кайбер фикерләр әйтте. Әмма татар халкының «Күр углы» дастанына татар фольклористикасында тиешле игътибар бирелеп беткән дип әйтеп булмый. Татар китаби дастаны буларак та, этник тарихыбызны, төрки-татарларның әдәби-мәдәни бәйләнешләрен барлау һәм гомумән татар версиясенең башка халыклар эпосы яссылыгында үз әһәмиятен ассызыклау җәһәтеннән ул махсус фәнни өйрәнүгә лаек. Дастан Себер территориясендә яшәүче татарларда да, Идел буенда да очравы белән төрле җирләрдә сибелеп яшәүче татарларны берләштерү функциясен дә үти.

«Күр углы» дастанын В.В. Радлов XIX йөз ахырында Төмән өлкәсендә яшәүче себер татарларыннан язып алган. Дастан прозаик характерда, фәкать берничә урында диалог яисә баш каһарман әйткән сүзләр генә ике-дүрт юллы тезмәләрдә җиткерелә. Мәсәлән:

Күрнең улы әйтте:

– Килсен ханларым, солтанларым!
Башлары миңа караган кеше килсен!
Боерылган әмерләрем инде алсын!

Яисә Күр улының Ага Цаус белән ат өстендә торып әйтешүеннән бер мисал:

Ага Цаус әйтте:

– Эстәрсәң дә инде малымны,
Син күрерсең минем көчемне.

Мине үлтерсәң, ал малымны,
Мин кайтмыймын, син кит иленә!

Шушы берничә шигъри юлдан тыш дастанның калган өлеше кыска җөмләле тезмә юлларда бәян ителә. Текстның күләме чагыштырмача зур түгел – дүрт биттән артмый. Вакыйгалар корылышы да артык катлаулы түгел, төп каһарман гамәлләренә нигезләнгән бер генә сюжет сызыгыннан гыйбарәт.

Күр батыр исемле вәзир Истанбул патшасына көтүдәге бер биянең озакламый толпар колынлаячагын хәбәр итә. Колын тугач, күк биянең әлеге кара колынчагын патша хуп күрми, аның толпар булачагына ышанмый, шуңа Күр батырны сукырайтып җәзалый. Ә колынчак, бераз үсә төшкәч, чыннан да толпарга әйләнә. Шуннан кызу канлы Күр батыр, улына кара айгырны җитәкләтеп, алдан әйткән сүзләренең хак булуын расларга дип, патша янына бара, аны каргый:

– Күрдеңме? Син минем күземне чыгардың, синең дә күзеңне чыгарсыннар! – ди. Патшаның ачуы чыга. Күр һәм аның углы качалар.

«Күр» исеменең килеп чыгышын Б.А. Каррыев ике төрле аңлата: «гүр» сүзе (таҗик, үзбәк версияләрендә төп каһарман, чыннан да, анасыннан кабердә, ягъни гүрдә туа) һәм кайбер төрки телләрдә күр сүзенең «сукыр» мәгънәсен аңлатуы белән бәйли [Каррыев: 1968. С. 227]. В. Радлов вариантына икенче аңлатма, ягъни патша тарафыннан сукырайтылган сукырның улы буларак каһарманны Күр углы исеме белән атаулары күбрәк туры килә, ә кабердә туу мотивы исә биредә урын алмаган. Алай да үзенең төрки телләрдәге төп мәгънәсе белән «күр / гүр / кер» сүзе каберне аңлата, төп каһарманның исеме дә шуңа бәйле булу ихтималы зуррак. Шул ук вакытта бу исемнең тарихи тамырлары булу мөмкинлеген дә алдарак карап узган идек.

Күр батырның улы атасын патша эзәрлекләвеннән коткарып кала, үзе Шәмливил дигән шәһәрдә «егетләр башы булып, узган-барганны коткармый, кәрванны талап тора», ягъни байлар-солтаннарны талау һәм үтерү белән шөгыльләнә. Башка милли версияләрдә вакыйгалар озын-озак итеп тәфсилләп сөйләнсә, В. Радлов вариантында шул ук вакыйга турында мәгълүмат кыска гына бер-ике җөмләдә җиткерелгән. Бу – соңгырак чор эпик стиль чагылышы, себер татарлары вариантының әүвәлге милли версияләреннән чагыштырмача соңрак формалашкан булуны раслый.

Алга таба Күр углының бер төркем батырлар башлыгы Ага Цауз (башка халыкларда, шул исәптән казан татарлары вариантындагы төрдәше – Ага Чауз) белән сугышуы һәм җиңүе, аның малын тартып алып, үзен әсир итүе тасвирлана.

Бер көнне боларга бер карт килә. Күр улы төркеме бу картның булган акчаларын талап ала. Карттан: «Бу дөньяда улың юк, кызың юк килеш

үләрсең», – дигән сүзләр ишеткәч, Күр углы аннан үзенә яраклы кыз турында сораша. Карт аңа Истанбулдагы Никар ханым дигән кыз турында әйтә. Әлеге карт образы гади генә карт булмыйча, башка милли версияләрдәге, әйтик, таҗик дастанында тәфсилләп сөйләнгән Хозыр образының бераз үзгәртеп китерелгән варианты булырга тиеш. Бу хакта татар дастанында бер сүз дә әйтелмәсә дә, картның Күр углы янына үзе килеп кергән булуы, рәнҗетелгәч, Күр угылының язмышын юрап әйткән сүзе, аңа яраклы кыз турында мәгълүмат җиткерүе карт образын изге Хозыр белән тәңгәлләштерү мөмкинлеген тудыра. Хозыр – борынгы Иран мифологиясе аша татар эпик иҗатына килеп кергән, дастаннарда еш телгә алына торган персонаж.

Шуннан Күр углы Истанбул каласына дип чыгып китә. Дастан каһарманының, кәләш эзләп, үз иленнән читкә чыгып китүе – төрки халыклар эпосында киң таралган мотив. Бу мотив махсус «героик ярәшү мотивы» дигән исем белән билгеле. Гадәттә Себер һәм Урта Азия төркиләре кәләшне башка кабиләдән ала торган булганнар, җиде буынга кадәр кан кардәшлеге булмаган очракта гына никахлашу рөхсәт ителгән. Кәләшне читтән эзләү мотивының экзогамиягә бәйле булуы турында Себернең төрки-монгол халыклары иҗатына мөнәсәбәттә Е.М. Мелетинский җентекләп яза [Мелетинский: 1963. С. 259–260]. Алтай әкияте «Кан-Пудей»да «алтын күкрәкле, көмеш аркалы» каһарман күк кызын бик еpактан, «җир белән күк тоташкан урыннан» алып кайта. Төрки һәм монгол халыклары өчен уртак әлеге сюжетның ерак кайтавазы Чура батырга багышланган дастаннарда да чагылыш тапкан булуга игътибар иткән идек [Ибраһимова: 2002. Б. 40]. Себер татарлары «Күр углы» вариантында каһарманның Никарны эзләп чыгып китүе дә әлеге традицион ярәшү-никахлашу мотивына килеп тоташа. Биредә ул үзгәргән, бу мотивка киң тукталу юк, сүз нигездә Күр углының атасын һәм үзен рәнҗеткән социаль гаделсезлеккә каршы көрәше турында бара.

Юлда әсир төшкән Күр углын зинданга ябалар, Никар ханым аны коткара. Патриархаль күчмә тормыш шартларында барлыкка килгән төрки халыклар эпосына каһарман хатынын яисә аның кәләшен бик теләп аның тигез хокуклы, акыллы ярдәмчесе итеп тасвирлау хас. Моңа мисалны без «Алпамыш»та (Барчин), «Кобланды батыр»да (Кортка), «Манас»та (Каныкей), «Чура батыр»да (Миңле Сылу яисә Гөлханыс, Акменде) һ.б. эпоста очратабыз. «Күр углы»нда да борынгыдан килә торган шушы эпик традиция чагылыш тапкан. Зинданда думбра чиртеп утыручы Күр углын күреп алган Никар ханым ярдәмендә төп герой юлын дәвам итә. Күр углы Бул бәк ханның сараена кереп, аннан бер кызны, кара атны урлап кача. Бул Бәк үзенең гаскәре белән боларны куа чыга. Ук атышып, Күр углы белән

бик каты сугышалар. Күр углына ярдәмгә аның егетләре килеп җитә. Бул бәкнең гаскәрен җиңеп, үзен Шәмливилгә әсир итеп алып кайтып китәләр. Күр углы Бул бәкне бик нык җәзалап үтертә:

– Бул бәк, сине тоткан көннәр ни булды?
Инде тиреңне суйдырам, суйдырам.
Йиреңә, халкыңа куйдырам, куйдырам,
Истамбулның капкасына илтеп куйдырам.

Күр углы Бул бәкнең эченә салам тутырылган гәүдәсен Истамбул патшасының капкасы төбенә китереп куя. Бу эшкә бик ярсыган патша даны илгә таралган Күр батырның кара атын тотып китергән кешегә үзенең кызын вәгъдә итә. Хәйлә юлы белән бу эшне Хәзәл исемле егет башкарып чыга.

Истанбул патшасы тарафыннан Күр углын һәм аның кара атын алып кайтырга дип җибәрелгән Хәзәл, Шәмливилгә килеп, Күр углына хезмәткә керә, аның ышанычын яулый. Дастанда Хәзәлнең еллар буе Күр углының малчысы булып торуы әйтелә, соңыннан ул Күр углының кара атын урлап, Истанбул патшасына качып китә.

Күр углы аны куа чыга, тиз арада хыянәтчене куып та җитә. Юлда тегермән ишегенә бәйләнгән кара атын күреп, атыннан төшкән Күр углын Хәзәл хәйлә юлы белән төп башына утырта: Күр углы тегермәннең бер ишегеннән кереп киткәч, үзе икенче ишектән чыгып, кара атны ияртеп, Күр углы атланып килгән туры атка менеп, кача. Хәзәл белә: атын калдырса, Күр углыннан мәрхәмәт булмаячак, ә качып котылса, Истанбул патшасы аңа кызын бирергә әзер. Әлеге тактик алым Хәзәл өчен уңай, әмма ул Күр углы белән дә арасын бозмый, киресенчә, аны туйга чакыра, шунда кара атны кире кайтарырга вәгъдә бирә. Соңыннан, сүзендә торып, вәгъдәсен үти.

Хәзәл – традицион героик эпос өчен типик образ түгел. Хәзәл белән Күр углы арасындагы конфликтның ике батыр арасындагы көрәш-алыш формасында түгел, ә хәйлә-мәкер катнашында чишелүе – соңгырак чор эпик традиция чагылышы. Батырлар арасындагы сугыш-орыш картинасына акыл-мәкер көрәше килеп керү белән башка китаби дастаннарда, әйтик «Каһарман Катил» героик дастанында да очрашабыз. Хәзәлнең кыйлган гамәлләре ил өчен, идея өчен түгел, ә үз амбициясеннән чыгып – патша кызына өйләнү, үзен күрсәтү өчен башкарыла. Әмма әлеге эпизод дастанда төп каһарманның дәрәҗәсен һич төшерми, киресенчә, күтәрә. Моны шул ук Хәзәлнең Истанбул патшасы ягында калмыйча, туйдан соң ук патша кызын, ягъни үзенең хатынын алып, Күр углы артыннан Шәмливилгә качып китүе үк раслый.

Дастан каһарманы Күр углы – курку белмәс батыр, җитез җайдак, үтә катлаулы хәлләрдән дә шома чыга белүче, нинди генә көчле дошманны да

җиңә алучы елгыр егет, оста оештыручы-җитәкче. Әмма шул ук вакытта бу егет – кеше үтерүче, талаучы куркыныч башкисәр, аны, атын тотып китерә алган кешегә кызын бирергә риза булып, Истамбул патшасы үзе эзләтә. Шуңа күрә бу яктан җинаятьчене аклап булмый кебек. Әмма героик дастан батырының үз-үзен тотышы бүгенге этика кагыйдәләренә һәрвакыт туры килеп бетмәве – эпос өчен табигый хәл. Күр углы холкына, һәрбер дастан каһарманына хас булганча, намуслылык, вөҗданлылык та ят түгел. Әйтик, Никар ханым зинданнан коткаргач, Күр углының качып китү я яшеренеп яту мөмкинлеге була, ә ул бу юлдан китми:

– Егетлек алай булмас, – ди, һәм, кире шәһәргә кайтып, дошманыннан каты итеп үч ала. «Егетлек алай булмас!» дигән гыйбарә текстта берничә урында кабатлана. Бу – каһарманның курку белмәс батыр булуын тасвирлау алымы, әсәрнең героик дастаннар рухына тәңгәллеген искәртә. Тагын шунысы бар: Күр углының дошманнары – һәрвакыт социаль дошманнар, алар – бай кәрванчылар, ханнар һәм патша. Әлеге факт вакыйгаларның тамырына – Күр углының җинаятьче-батыр булып әверелү сәбәпләренә алып кайта. Чыннан да, каһарманның атасы Күрне хаксызга рәнҗеттеләр, шуның нәтиҗәсендә карт күзсез калды, иленнән качарга мәҗбүр булды. Рәнҗетүче – үзенең хакимиятеннән явыз файдаланучы Истанбул патшасы. Дошманлыкның, явызлыкның сәбәбе әнә шул. Күр углы кыйлган гамәлләр үч кайтару мотивы белән башкарыла, шуңа да мантыйкый рәвештә аклана.

Биредә Күр углының үз егетләре-көрәштәшләре арасында зур авторитет булуын да истә тотарга кирәк. Һәрвакыт, һәр җирдә бу егетләр җитәкчеләренә ярдәмгә килергә әзер һәм бу бирелгәнлек көч кулланып түгел, фәкать Күр углының кодрәтен, чын батыр булуын тану бәрабәренә башкарыла.

Әле батыр туганчы ук ат белән аның арасында якын мөнәсәбәтләр урнашу – күп кенә төрки дастаннар өчен уртак күренеш. «Күр углы»ның әзәрбайҗан версиясендә Хәсән бәк атасы-баһадирның Гырат («кыр аты») кушаматлы тулпарыннан туасы җирән колын белән дуслаша. Кыргызларның «Манас»ында да шуңа охшаш эпизод бар. «Чура батыр»ның казакъ версиясендә исә Гөлханыс, каршыларына чабып килгән тулпарны күреп, «Туачак баламның аты булыр бу», – ди, һәм аның юравы чынга аша. Себер татарлары «Күр углы»нда да каһарман янында, аңа тугры кырык көрәштәш егет белән бергә, әлбәттә, төрки эпосның аерылгысыз атрибуты – каһарман үзе генә иярли ала торган тулпар аты тасвирланган.

Эпик герой – һәрвакыт горур, гаделсезлеккә түзеп тора алмый, кызу канлы һәм үз көченә нык ышанучан. Күр углына әлеге сыйфатларның һәммәсе дә хас. Дастанда ул гаделлек өчен көрәшүче курку белмәс батыр образын гәүдәләндерә.

Дастанның тел-стиль һәм шигъри үзенчәлекләренә килсәк, бу әсәрне сөйләмә вариантка якын тора дип билгеләү дөрес булыр. Халык сөйләменә хас артык озын булмаган гади яисә тезмә кушма җөмләләр, чәчмә стиль дастанны сөйләмә характердагы иҗатка якынайта.

Себер татарлары XVI йөздә иң беренче чиратта Урта Азия мөселманнары йогынтысында ислам кабул иткәннәр, ә Идел буеннан күчеп килгән казан татарлары йогынтысында исә биредә язма культурага омтылыш арткан. XIX йөз ахыры – XX йөз башларынача Урта Азия белән чиктәш татар төбәкләрендә икетеллелек күренеше булган. Берничә кардәш халык эпосын белгән импровизаторлар да мәгълүм. Мәсәлән, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге архивында «Алпамыш» дастанын казакъча да, татарча да әйткән татар кешесеннән язып алынган текст саклана [ТФА Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фонды, колл. 39]. Гомумән, кардәш төрки халыкларда ике телле чичәннәр һәм аларның эпосны ике телдә дә белүләре аерым очракта гадәти хәл булган.

Татар халкының себер татарларындагы «Күр углы» варианты – тубыл татарларының иҗади эшкәртүенә дучар булган, бай эпик җирлеккә ия дастан. Ул Урта Азия чичәннәре белән язма культура арасын үзенчәлекле тоташтыра, синкретик характердагы, ягъни үзендә индивидуаль башлангычны да, фольклор традицияләрен дә үзенчәлекле берләштергән әсәр булуы белән кызыклы. Татарлардан тыш башка бик күп төрки һәм төрки булмаган халыкларда популяр «Күр углы» дастанының XIX йөз ахырында себер татарларында табылганы башка версия һәм вариантлар өчен дә характерлы булган уртак сюжет сызыклары, эпизод, детальләргә ия. Бу вариант төрки героик эпосы рухын саклый торган дастан буларак кыйммәт. Авантюралы сюжетының социаль-көнкүреш мәсьәләләренә кагылышлы булуы, күрәсең, дастанның халыкта киң һәм төрле формада таралуына сәбәп булган.

Дастанның Татарстанда табылган кулъязма варианты бар. Аның хакында галим М. Әхмәтҗанов хәбәр итә [Әхмәтҗанов: 2000. Б. 187]. Ул кулъязма бүгенге көндә Мирасханәдә тасвирланган хәлдә саклана [Татарстан ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать инстутының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фонды, 39 колл. Сакл. бер. № 5013].

Кулъязма фәкать ике генә битлек, гарәп язуында. Текст шәмәхә кара белән 1920 елларда эшләнгән кәгазьгә язылган. Әлеге дастан бары фрагменттан гыйбарәт, 26 тезмә юлны тәшкил итә. Дастан кулъязмасының 13 нче һәм 14 нче шушы ике битеннән кала башка өлеше сакланмаган. Өзектә Күр углы уллыкка алган Хәсән ханның гаскәрдәге егетләрне яуга өндәгән чыгышы китерелә. Әлеге текстан берничә юл:

Фәрәмуш булмасын (онытылмасын. – Л.М.) имди хәтерләр.

Корыңызлар сарә (сөенеч, шатлык уңаеннан. – Л.М.) пәрдә чатырлар.

Ак керүгә савыт кигән (ак түгәрәк көбә күлмәк, кольчуга. – Л.М.) батырлар,

Я алыңлар, я үлеңләр егетләр.

Йулымызда күзе Күр углы солтан,

Гаваз ханны килтерер дип кырык арслан.

Ук үтмәгәй, кирек тиресе бу калкан (киергегә тарттырылган калкан. – Л.М.),

Я үлеңләр, я алыңлар егетләр.

Фрагмент кына булуга карамастан, кульязманы «Күр углы»ның бер варианты дип бәяләргә мөмкин. Бу шигъри өзекнең табылуы «Күр углы»ның татарларда популярлыгын раслый. Әлеге вариант себер татарларыннан язып алынган дастан сюжетыннан ерагая төшкән. Кайбер антропонимик һәм топонимик уртаклыклар, мәгълүм Күр углы турында каһарман характерындагы дастан булуы һәм бердәй мотивлар (әйтик, Күр углының баласы булмау) гына аларны бер үзәккә тупларга мөмкинлек бирә.

Аның каравы бу фрагмент кульязма дастанның басма варианты белән аваздаш. Дастанның 1894 елгы басмасында кульязмадагы шушы өзек юлга-юл кабатланган [Хикәяте Күр углы солтан: 1894. Б. 13–15]. Чагыштыру өчен югарыда мисалга китерелгән сигез юлның басма вариантта ни рәвешле кабатлануын күзәтеп үтик:

Фәрәмуш булмасын имди хәтерләр.

Корыңызлар сарә пәрдә чатырлар.

Ак керүгә савыт кигән батырлар,

Я алыңлар, я үлеңләр егетләр кырык егетләр.

Йулымызда күзе Күр углы солтан,

Гаваз ханны килтерер дип кырык арслан.

Йамылкан (атылган. – Л.М.) ук үтмәс кирек тиресе калкан,

Я алыңлар, я үлеңләр егетләр.

Татарларда кульязмада таралган дастаннар китап басу дәверендә китап булып басылып чыга торган булган. «Күр углы» вариантлары очрагында да шушы ук закончалык кабатлана: безнең көннәргә кульязма текстның зур өлеше югалган булса да, җирле наширләр аны тулы вариантында китап формасына күчереп калырга өлгергәннәр. Мәгълүм булганча, XIX йөз – XX йөз башында Казан типографияләрендә «Хикәяте Күр углы солтан» исеме белән күләмле әсәр кат-кат басыла. Әйтик, бу дастан 1889 дан алып 1916 елгача 11 тапкыр дөнья күргән. Югарыда каралган кульязма фрагменттагы юллар, кайбер лексик, морфологик һәм орфографик үзгәрешләр кичереп, нәкъ менә шушы басма хикәяттә очрый.

«Хикәяте Күр углы солтан»ның теле гарәп-фарсы алынмалары белән чуарланган һәм бүгенге көн укучысына шактый кыен аңлашыла. Күләме зур – 90 битне тәшкил итә, гарәп язуында.

Кайбер милли, әйтик, төрекмән версиясендә Күр углының бала чагыннан алып егет булганга кадәрге тормышын, геройның могҗиза юлы белән туган атын җентекле тасвирлау-бәян итү бар. Татар «Күр углы»сында әсәрнең ханнар тарихын риваять итеп, хронологик төстә берничә ханның исемен атап, шул тәртиптә Күр углының да унбиш яшендә хаким булуын бәян итеп башлануы әлеге төрки эпос традициясенә якын тора. Татар китаби дастаны Күр углы тормышындагы вакыйгаларның кайберләренә генә тукталган. Вакыйгалар тасвирланышы башка милли версияләрдәге эзлеклелеккә һәрвакыт туры килеп бетми. Бер үк исемнәр, охшаш вакыйгалар төрле уңай белән сюжетның төрле урынында очрарга мөмкин. Төрекмән, таҗик, әзәрбайҗан һ.б. версияләр бер-берсеннән аерылып торган кебек, татар дастаны да яңа җирлектә яңача корылган, әлеге иҗат процессында күп үзгәрешләргә дучар булган.

Күр углы утыз яшькә җиткәндә моның янына Хозыр галәйһиссәлам, кырык изге җан, унике имам киләләр һәм аңа изге дога багышлыйлар. Кырык яшендә болар Күр углына кабат килеп, «бездән niләр теләр идең» – дип сорыйлар. Күр углы дан-шөһрәткә ия булып озак яшәүне сорый, ә үзенең варисы итеп калдырырлык бала сорарга башына килми.

Дастанда аның күп хатыннар алып та, берсенең дә моннан бала тапмаулары турында сөйләнә. Варис кирәклеген аңлап, Күр углы, йөз яшенә җиткәндә, Исфаһан шәһәреннән Хәсән ханны алып кайтып, аны үзенең улы дип игълан итә, батыр егетләренә шул Хәсәнне башлык итеп куя.

Алга таба дастан Хәсән хан җитәкчелегендәге кырык егетнең Хункар иленә баруы турында сөйли. Биредә «Булдырык исемле итченең бер бик чибәр улы» яши икән, Күр углының шушы Гаваз ханны күрәсе, аны үзенең варисы итәсе килә. Шуңа күрә ул: «Хәсәнне тыңлап, буйсынып торыгыз», – дип, Гаваз ханны алып кайтырга Хункар иленә яу җибәрә.

Татар версиясендәге Гаваз төрле милли версияләрдә телгә алынган Айваз (Овез, Иваз, Аваз) исемле бик чибәр үсмер егет образы белән тәңгәл килә. Дастанның көнбатыш һәм көнчыгыш версияләренең һәркайсында талау-буйсындыру сугышларының берсендә Күр углының Айваз исемле бик чибәр яшь ир баланы урлап китү эпизоды бар. Әлеге үсмер егет башта Күр углы хезмәтендә аның шәраб коючысы булып тора, соңыннан үч алучы-башкисәрнең көрәштәше-фикердәшенә әверелә. Дастан версияләрендә тасвиланган әлеге эпизодның чынбарлык вакыйгаларына барып тоташуы һәм тарихи документларга нигезләнеп раслануы әһәмият-

ле. Җәләлидләр түнтәрелеше турында Төркиядәге архив документларын барлаганда Х. Короглы бу турыда гаять кызыклы тарихи мәгълүматларга юлыга. Ул менә нәрсәләр турында хәбәр итә: «Самые достоверные сведения о джалалидском движении во главе с Кёроглу сохранились в государственых архивах Турции. В указе от 1580 г., адресованном правителю Болы (главный враг героя во всех версиях эпоса) и кадию Гереде, говорится о бесчинствах, совершаемых неким Кёроглу, которого следует поймать и наказать согласно закону. Чрезвычайно любопытно, что в этом же указе упоминается о том, что Кёроглу увел с собой красивого подростка. Об этих же событиях рассказывают другие архивные документы, датированные 1579–1581 гг.» [Короглы: 1973. С. 143]. Димәк, реаль вакыйганың татар дастанына килеп кергән булу ихтималы бөтенләй юк түгел яисә мондый күренешләр – татарларга язма чыганак аша кергән басма вариантның тәрҗемәләнүе нәтиҗәсе.

Кырык егете белән Хәсән хан Хункар дәүләтенә килеп җитеп, Бәдбәхет тавында туктала. Бу тау Гөрҗестан җирендә була. Таудан түбән карап, каланың зурлыгын, капкаларының күплеген күреп каушап калган егетләргә Хәсән бәк кульязма вариантта да теркәлгән 26 юлдан торган шигъри тезмәдә бәян ителгән сүзләрне әйтә. Ул юлларның эчтәлеге егетләрне орышка үгетләүдән, Күр углы солтанның ышанычын акларга өндәүдән гыйбарәт.

Татарча «Күр углы солтан» – төрки героик эпосы рухын тулысынча саклый торган әсәр. Әйтик, баһадирга даими рәвештә изге картларның ярдәмгә килүе – төрки халыкларның дастаннарында еш очрый торган күренеш. Мәсәлән, «Алпамыш» дастанында батырга Хозыр үзе булыша. «Гашыйк Гариб»нең азәрбайҗан версиясендә каһарман шул ук Хозыр Ильяс ярдәме белән кирәкле вакытта тиешле җиренә барып өлгерә һ.б.

«Күр углы солтан»да бу мотив төрки дастаннар өчен гаять популяр икенче бер әһәмиятле күренешкә – баласызлык мотивына барып бәйләнә. Баласызлык мотивы казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, каракалпак кебек төрки халыклар эпосы өчен бик популяр. Мәсәлән, казакъ халык героик эпосы «Кобланды батыр»да Toктарбай сиксән яшенә җитә, әмма баласы булмый. Кыргыз эпопеясы «Манас»та улы булмаган Якуп кайгысыннан кан-яшь түгә. Киң таралган бу мотив Чура батырга багышланган дастаннарда да күзәтелә.

«Күр углы солтан»да баласызлык мотивы дастанның төп нигезе булып әверелгән дисәк тә хата булмас, чөнки нәкъ менә шушы проблема Күр углын башта Хәсән хан, аннары Гаваз хан өчен көрәшергә мәҗбүр итә һәм дастан сюжетын төзи.

Соңгы елларда «Күр углы» дастаныннан эпик җыр буларак аерымланган текстлар да язып алынуга игътибар итми мөмкин түгел. Әйтик, «Кируглы җыры»ның («Күр углы» эпос-дастаныннан) бер варианты Казан дәүләт консерваториясе оештырган экспедиция вакытында 1998 елда Әстерхан өлкәсе Приволжск районы Татар башмагы авылында Сәфәров Сәләхетдин Җәләлетдин улыннан (1934 елгы) язып алынган [Памятники...: 2007. С. 222–223]. Шул ук информантның шул ук дастаннан тагын бер җырны башкаруы мәгълүм, ул вариантның тулы исемен «Кируглы җыры» (Сиңа диеп килдем) дип күрсәтергә мөмкин. «Күр углы» дастаны сюжетына бәйле бу җырларда курку белмәс каһарман Күр углының башбирмәс холкы чагылыш тапкан:

Сиңа диеп килдем

Чандыбилемнән (Чандыбил – «Күруглы» дастанында эпик атама, урын, төрки версия һәм вариантларда «Чандыбил», «Чамлыбел», «Җанлыбил», «Чаглибил» кебек формаларда очрый. – Л.М.)

Синнән курыккан
Әнисеннән тумасын;
Үзем дисәм, тик төрекмән иленнән,
Синнән курыккан
Әнисеннән тумасын.
Мәйдан эченә җиттем,
Бәйгедә катнаштым,
Болгар атым ат каешны тирләтте;
Мин тордым, иңемдә кылыч уйнаттым,
Синнән курыккан
Әнисеннән тумасын! («Кируглы җыры»ннан (Сиңа диеп килдем) [Памятники...: 2007. С. 227].

«Күр углы» дастаны белән бәйләнешле мондый иҗатның булуы татарларда әлеге дастанның фольклор белән уртаклыгы әле дә дәвам итүне күрсәтә. Бүгенге көндә мөстәкыйльлеккә дәгъва кыла торган фольклор жанры – дастан җырлары арасында «Күр углы» дастанына бәйлеләре чын мәгънәсендә аерым урын алган. Алар асылда Әстерхан өлкәсендә яшәүче татарларда сакланып калган, бүгенге көндә халык иҗатының сирәк, әмма шактый актив тел-авыз иҗаты мисаллары. Татарларда «Күр углы»на кагылышлы дастан вариантларының язмада сакланганнары белән бергә XIX гасырда В. Радлов [Радлов: 1872. С. 258–261] себердә язып алган сөйләмә характердагылары һәм әле бүгенге көннәрдә дә югалып бетмәгән дастан җырлары («Кируглы җыры», «Күруглы җыры») халкыбызда «Күр углы» сюжетына корылган әсәрнең язма мәдәниятә дә, тел-авыз иҗатында да һичшиксез билгеле бер роль уйнавы хакында сөйли. «Күр

углы» сюжетына татар вариантларының язма нөсхәләре күчерелеп һәм укылып йөргән дастаннардан саналса, дастан җырлары һәм телдән язып алынган вариантлары әсәрнең фольклор тамырлары хакында искәртә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Күр углы» исеме белән бәйле дастаннар безнең халыкта кульязма һәм басма формаларда очрый. Китаби дастаннар формалашуның билгеле бер этабында «Күр углы» хикәятенең, халыкның язма әдәбиятка ихтыяҗын канәгатьләндерә торган, борынгыдан килгән традицияләребезне язуга күчереп тарата торган әсәр буларак, әһәмияте зур. Үзенең сюжет корылышы, образ-персонажлар бирелеше, вакыйгалар эзлеклелеге, күләме һ.б. ягыннан татар версиясе башка халык версияләрен кабатламавы белән үзенчәлекле. Күп яклап «Күр углы» дастаны – гаять кызыклы, бай хәзинә.

Дастан – элитар жанр. Алар һәрбер халыкта булган һәм бар дип әйтеп булмый. Эпос-дастан, бигрәк тә китаби дастаннар халыкның үткәнен бәяләгәндә аерым бер критерий ролен дә үти дияргә ярыйдыр. Халык томышын эпик сурәтли торган әсәрләре татарларның тирән тарихка ия, дәүләт тоткан, алдынгы, укымышлы халыклар булуын ассызыклый. Себер, Кавказ, Урта Азия һәм Казахстанның, Якын Көнчыгыш һәм хәтта өлешчә Европаның төрки телле һәм башка халыкларында гаять популяр «Күр углы» дастанының татарлар яшәгән төбәкләрдә дә таралганлыгы халкыбызның үзбилгеләнүен ачыклауда катнаша.

Әдәбият

1. Әхмәтҗанов М.И. Татар кульязма китабы. Казан: Тат. китап нәшр, 2000. – 270 б.
2. Закирова И.Г. «Күр углы» дастанының татар версиясе // Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. Казань: Ихлас, 2010. С. 371–372.
3. Ибраһимова Л.Х. Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. – 192 б.
4. Каррыев Б.А. Эпические сказания о Кер-углы у тюрко-язычных народов. М.: Наука, 1968. – 260 с.
5. Короглы Х.Г. Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М: Изд – во «Наука», 1973. С. 134–146.
6. Мөхәммәтҗанова Л.Х., Мөхәммәтҗанова А.Ә. «Күр углы» дастаны сюжетында вариантлылык, тарихилык, традицияләр яшәүчәнлеге // Фәнни Татарстан. 2025. № 1 (145). С. 78–89.
7. Памятники татарского народного музыкально-поэтического творчества. Вып. 1. Песни Астраханских татар. Әстерхан татарлары җыр-

лары. Сост. и нот. транскр. Е.М. Смирновой и Н.Г. Гайнуллиной. Казань: Казанская консерватория, 2007. – 552 с.

8. Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи, Ч. IV. Наречия барабинцев, тюркских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872. С. 258 – 261. (528 с.)
9. Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа. Казань: Тат. книж. изд-во, 1984. – 310 с.
10. Хикяте Күр углы солтан. Казань: Типо-литография Имп.-го ун-та, 1894. – 90 б.

А.И. Бугарчев, О.В. Степанов

СРЕДНЕВЕКОВЫЕ МОНЕТЫ ИЗ АКСУБАЕВСКОГО РАЙОНА ТАТАРСТАНА КАК МАТЕРИАЛ ДЛЯ КРАЕВЕДЧЕСКОЙ РАБОТЫ[1]

Аннотация. *В статье приводится информация о находках средневековых восточных монет на отдельных памятниках Аксубаевского района Татарстана. Это Новое Мокшино, Барское Енорускино, Нижнетатмайновские селища и Новое Ильдеряково. Серебряные и медные монеты из указанных объектов были выпущены в XIII–XIV вв.*

Ключевые слова: *монета, дирхам, пул, археологический памятник, Аксубаевский район, Татарстан, XIII–XIV вв.*

Основным источником для установления времени возникновения и существования населённых пунктов являются, по нашему мнению, находки археологического материала. И в первую очередь – монеты. Для периода средневековья различное количество находок позволяет установить этапы возникновения, подъёма и затухания экономической жизни на поселениях. Данный принцип полностью подходит для изучения памятников из Татарстана. Ранее авторами была исследована нумизматическая история Иски-Казанского археологического комплекса, где было собрано почти тысяча серебряных и медных монет [Бугарчев, Степанов: 2021]. Они были выпущены в период с X до середины XV вв. [Там же: С. 54–55]. Большое количество работ было посвящено находкам джучидских монет XIII–XV вв. из Джукетау (в границах современного города Чистополь).

Используя такие методы работы как топографический, метрологический и сравнительный, рассмотрим нумизматический материала из Аксубаевского района Татарстана. Информация собиралась нами на протяжении последних 20 лет. Было издано несколько статей, посвящённых отдельным находкам, происходящим из района [Бугарчев: 2019; Бугарчев, Павлов: 2024].

Разберём топографию находок средневековых монет.

Деревня Новое Мокшино: здесь в разное время были найдены серебряные монеты середины XIII в. – с именами монгольских каанов Мунке и Арыг-Буги (1250–1260 гг.), дирхамы с тамгой золотоордынского хана Менгу-Тимура (1266–1282) чеканки монетных дворов Биляра, Булгара и Кермана. Медные монеты с именами халифа ан-Насира и каана Мунке относятся к 1240–1250 гг. Комплекс остаётся не разобранным по типам и

[1] Доклад на данную тему был зачитан 4 апреля 2025 г. на Вторых межрегиональных Зай-Каратайских историко-краеведческих чтениях.

по метрологии. В Татарской энциклопедии написано, что деревня основана в середине XVIII в. [ТЭ: 2008. С. 463]

Деревня Барское Енорускино – известно о находках одного дирхама начала XIV в. (С/140), одного медного динара Мунке (1250-е гг.) и одного пула «тамга в треугольнике» (1320-х гг.). Но главное – здесь был найден небольшой клад серебряных монет – 16 экземпляров, который оказался очень важным для установления границ этапов булгарского денежного обращения [Бугарчев, Петров: 2018. С. 179–180]. Из статьи в Татарской энциклопедии следует, что деревня основана в XVIII в. [ТЭ: 2002. С. 305].

В статье татарстанского краеведа Р.Г. Насырова упоминаются находки с ***Нижнетатмайновских селищ*** (состоят из 7 памятников), где было обнаружено 76 средневековых монет [Насыров: 2016. С. 77].

Из других опубликованных материалов сначала укажем на статью 2019 г., где приводится 18 дирхамов и их фракций, чеканенных во второй половине XIII в. при золотоордынских ханах Менгу-Тимуре, Туда-Менгу и наместнике Кунчеке [Бугарчев: 2019]. Точное место сбора установить не удалось, известен только район находок – Аксубаевский.

В ещё одной, более поздней работе, описаны серебряные монеты, найденные в ***окрестностях посёлка Аксубаево***. Комплекс насчитывает 28 дирхамов, чеканенных на монетных дворах Булгара, Биляра, Сарайя, Нового Сарая и Гулистана. Хронологически все монеты выпускались в столетний период – в 1260-х – 1360-х гг. [Бугарчев, Павлов: 2024]. В Татарской энциклопедии приводится следующая информация – основана во второй половине XVII в. [ТЭ: 2002. С. 85].

Село Новое Ильдеряково расположено в 10 км к северо-востоку от Аксубаево. Здесь подняты два булгарских анэпиграфных дирхама начала XIV в. и семь дангов второй трети XIV в. чеканки Сарая ал-Махруса («Богохранимого»), Сарая ал-Джадид («Нового») и Гулистана. Материал ещё не издавался. В Татарской энциклопедии написано, что село основано в середине XVIII в. [ТЭ: 2008. С. 465].

Таким образом, приведённая информация свидетельствует о том, что на указанных памятниках в XIII – первой половине XIV вв. существовала активная торговая деятельность. По ряду причин после 1360-х гг. жизнь в изучаемом субрегионе затухает.

Карта археологических памятников приводится из Свода 2007 г.

На фототаблице показаны отдельные булгарские серебряные монеты XIII в., найденные в Аксубаевском районе.

ФОТОТАБЛИЦА 1
БУЛГАРСКИЕ МОНЕТЫ XIII В. ИЗ АКСУБАЕВСКОГО РАЙОНА РТ

Литература

1. Бугарчев А.И. Ранние золотоордынские монеты периода 665–690 гг. из находок в Аксубаевском районе // Человек и природа в бассейне р. Ик в историческом развитии. Актанышский район: проблемы истории и культуры. Материалы Всероссийской конференции. Вып. 19. Казань: Отечество, 2019. С. 39–41.
2. Бугарчев А.И., Павлов А.А. Джучидские монеты XIII–XIV вв. из находок в Аксубаевском районе Татарстана // Труды Камской археолого-этнографической экспедиции. Вып. XXIV / Под общей ред. А.М. Белавин; ПГГПУ. Пермь, 2024. С. 102–107. DOI: 10.24412/2658-7637-2024-24-102-107
3. Бугарчев А.И., Петров П.Н. Монетные клады Булгарского вилайата XIII – первой четверти XIV вв. Монография. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2018. 336 с., илл.
4. Насыров Р.Г. Из опыта привлечения нумизматического материала в изучении местной истории (на примере археологических памятников майнской округи) // Материалы II Региональной научно-практической конференции. Болгар, 2016. С. 76–87.
5. Свод памятников археологии Республики Татарстан. Отв. ред. А.Г. Ситдиков, Ф.Ш. Хузин. Казань, 2007. Т.3. – 528 с.
6. Татарская энциклопедия. Гл. ред. М.Х. Хасанов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. Т. 1. А-В. – 672 с.
7. Татарская энциклопедия. Гл. ред. М.Х. Хасанов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. Т. 4. М-П. – 768 с.

Илсөяр Закирова

ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫНДА АКСАК ТИМЕРНЕҢ ЭПИК БИОГРАФИЯСЕ

Алтын Урда чорының билгеле шәхесләрнең берсе Сәхибкыран Әкбәр Тимур Күрәгани Мозаффар тарихка үзенең исемендә түгел, ә кушаматы белән кереп кала. Төркиләр аны Аксак Тимер буларак беләләр, фарсылар шул ук кимчелеген истә тотып Тимур-Ленг дип атыйлар, фарсыдан Европа телләренә ул Тамерлан булып керә. Шул рәвешле кодрәтле әмирнең кимсетүле кушаматы гасырлар буена кабатланып аның исеменә әверелә.

Аксак Тимер тарихка да, халык хәтеренә, шул исәптән фольклорга да, беренче чиратта, үзенең мәгънәсез ерткычлыгы, кансызлыгы белән кереп кала. Дөрес, бөтенесе Аллаһы Тәгалә кулында, дигән принцип белән яшәгән мөселман халыкларының аның ерткычлыкларын Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән җәза, яки язмыш итеп кабул итүе дә мәгълүм.

Аксак Тимернең яулап алу сугышлары, тормыш юлы турындагы беренче хезмәтләр үзе исән вакытта ук языла башлый. Тарихчылар әмирнең үз янында «дабиран-и хас» – шәхси сәркатип һәм «фадилан-и аср» – чорының укымышлы кешеләрен тотуын, аларга үзе белән бәйле вакыйгаларны язмача теркәп бару йөкләтелгән булуны әйтәләр.

Бу хезмәтләрнең безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәренең иң беренчесе – Низам-әд-дин Шәминең «Зәфәр-намә» дигән хезмәте. Аксак Тимер Багдадны алганнан соң, Низам-әд-дин Әбдел-Вәси Шәмигә үзенең тормышын һәм аның белән бәйле тарихи вакыйгаларны язарга куша. «Зәфәр-намә», ягъни «Җиңү китабында» Аксак Тимергә кадәрле монгол дәүләтләренең кыскача тарихы һәм Тимернең 1404 елга кадәр тормышы, ул алып барган сугышлар бәян ителә. Низам-әд-дин Шәми үзенә кадәр язылган тарихи чыганакларга, документларга, шул вакыйгаларның шаһите булган кешеләр сөйләгәннәргә таяна, язмасын фольклордан килгән мотивлар белән баета. Кайбер автобиографик мәгълүматларны Аксак Тимер үзе бирә [Сборник материалов: 1941. С. 104]. Әлеге хезмәт озак еллар Аксак Тимер турында төп чыганак буларак кулланыла.

Аксак Тимергә багышланган икенче зур хезмәт тә «Зәфәр-Намә» дип атала [Сборник материалов: 1941. С. 144–199]. Авторы Шәрәф-әд-дин Али Йәзди әлеге әсәрне Аксак Тимернең вафатыннан соң яза. Хезмәтнең нигезендә Низам-әд-дин Шаминең «Зәфәр-намә»се ята. Автор безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән шактый чыганаклар белән эш итә, шулай ук Аксак Тимер яуларынының шаһитләре, катнашкан кешеләрнең сөйләгәннәренә таяна. Шуңа күрә Шәриф-әд-дин Али Йәздинең хезмәте фактик материалларга бай. Авторның Аксак Тимергә мөнәсәбәте субъек-

тив булуы күзгә ташлана, ул әмирнең һәр эшен, ягъни яулап алу сугышларын, меңнәрчә гаепсез кешеләрне юк итүен аклап кына калмый, хәтта мактаулы эш буларак бәян итә. Ул үзе тасвирлаган вакыйгалардан Аксак Тимернең 1387 елда Исфахан халкын тулысынча юк итүен дә, һиндстанга яуга чыгар алдыннан 100 мең әсирне үтерүен дә тулысынча акларлык сәбәпләр таба.

Өченче чыганак – «Искәндәр анонимы» [Сборник материалов: 1941. С. 126–138]. Бу хезмәтнең озак еллар авторы мәгълүм булмый, шуңа күрә ул фәнгә аноним исеме белән керә. В.В. Бартольд исә аның авторы Муин әд-дин Натанзи дигән кеше булуын ачыклый. «Искәндәр анонимы»ның бер бүлеге Аксак Тимергә багышланган. 1413–1414 елларда язылган бу хезмәттә башка чыганакларда булмаган фактлар да бар.

Аксак Тимер турында шул дәвер тарихчылары Хафизи Абру (1361(1358?)–1430), Абд әр-Реззак Самарканди (1413–1482), Мирхонд (1433–1498) һ.б. яза. Гарәп тарихчысы Ибн Арабшахның «Аджа’иб ал-макдур фи нава’иб Тимур» [Сборник материалов: 1884. С. 455–474] дигән хезмәте Аксак Тимергә багышланган иң зур күләмле әсәрләрнең берсе. Алдарак искә алынган авторлардан аермалы буларак, Ибн Арабшах Аксак Тимер образын идеаллаштырырга омтылмый, киресенчә аның басып алу сәләтенең бөтен тискәре якларын, аның кешелеккә китергән фаҗигасен күрсәтә һәм автор бу шәхескә нәфрәтен яшерми. Шул ук вакытта Ибн Арабшах һәр яктан объектив булып калырга омтыла – Аксак Тимернең хәрби даһилеге, оештыру сәләте, акылы һ.б. сыйфатларын да югары бәяли.

Аксак Тимер шәхесе турында мәгълүматлар рус һәм Европа тарихчылары хезмәтләрендә, елъязмачылар һәм сәяхәтчеләр язмаларында һәм истәлекләрендә дә сакланган. Мәсәлән, Рюи Гонзалес де Клавихоның Аксак Тимер белән очрашуларын бәян иткән көндәлеге хөкемдар турында кызыклы күзәтүләрен һәм объектив нәтиҗәләрен саклый [Гонсалес де Клавихо: 1881].

Аксак Тимергә багышланган күләмле хезмәтләрнең тагын берсе – «Автобиография Тимура» («Аксак Тимернең автобиографиясе») [Тамерлан. Автобиография: 2005]. Әсәрнең авторы мәгълүм түгел. Бу өлкәдә эшләгән галимнәр аның Аксак Тимер сүзләреннән язылган булу ихтималын да кире какмыйлар. Бу очракта ул соңрак хронологик яктан тәртипкә салынган, Аксак Тимернең биографиясе эпик традицияләргә туры китерелгән булырга мөмкин. Әсәр ике өлештән тора. Хезмәтнең беренче өлешендә тулы биографиясе бирелә, Аксак Тимернең үзе төзегән унике әхлакый принцибы нигезендә идеаль хөкемдар образы тудырыла. Икенче өлеш аның дәүләт һәм гаскәр белән идарә итү турындагы

фикер-карашларыннан тора, Аксак Тимернең җиде яшеннән утыз тугыз яшенә кадәр тормышы сурәтләнә. Аның 39 яшьтән соңгы тормышы хезмәтнең «Кануннар җыелмасы» («Уложение») дигән өлешендә тасвирлана [Тамерлан. Автобиография: 2005. С. 279–430] . Бу хезмәтләрне тикшергән Л. Яковлев «Автобиография» һәм «Кануннар җыелмасы» – бер үк әсәрнең ике редакциясе дигән карашта тора [Тамерлан. Автобиография: 2005. С. 5–12]. Хезмәтнең «Кануннар җыелмасы» өлеше төзелеше белән катлаулырак, үзенә күбрәк мәгълүмат сыйдырган.

Аксак Тимер 1336 нчы елда Шахрисабз шәһәреннән ерак түгел Хуҗа Илһар дигән җирдә туа. Атасы Таратай исемле бәк була. Алар монголларның төркиләшкән барлас дигән кабиләсенә карыйлар. Ул вак җирбиләүче булып, артык бай булмаса да, кабиләсендә дәрәҗәле кеше була. Аксак Тимернең тормыш юлы күпчелек хезмәтләрдә 1360 елдан, ул Тоглук-Тимергә хезмәткә кереп, Кашкадәрья виләятендә хакимлек итүеннән башлана. Шулай да Аксак Тимернең биографиясенең башлангычы турында Ибн Арабшах һәм Гонзалес де Клавихо мәгълүмат бирергә омтылалар, рус елъязмаларында да күпмедер хәбәрләр сакланган. Нигездә бу чыганаклар бер үк мәгълүматны кабатлыйлар. Әлеге чыганакларда Аксак Тимернең балачагында ук лидерлык сыйфатларына ия булуы турында сүз бара. Ул җәядән бик яхшы ата, атта йөри, яшьтәшләре арасында дәрәҗә казана һәм әкренләп үз янына нүкерләр туплый. Алар юлбасарлык, угрылык белән шөгыльләнәләр, башта күрше-тирәләрнең сарык-сыерларын урлый башлыйлар. Әкренләп юлбасарлардан торган әлеге төркем зурая, алар 300 кешегә җитәләр һәм юлларда сәүдәгәрләрне талый башлыйлар.

«Автобиография»дә Тимернең биографиясе җиде яшеннән башлана. Хезмәттә бирелгән мәгълүмат буенча, аны җиде яшендә мәктәпкә бирәләр, ул бик тиз укырга-язарга өйрәнә, тугыз яшендә мәктәптә иң яхшы укучы буларак танылa. Яшьтәшләре арасында ул хәрби бәрелешләр оештыра һәм үзе һәрвакыт «әмир» була.

Тимернең чын биографиясе шушы ике вариант арасында булырга мөмкин. Автобиография Тимернең балачактан яхшы оештыру сәләтенә ия, белемгә омтылучан, мохтаҗларга ярдәм итүче кеше буларак сурәтләсә, риваятьләр нәкъ киресен – Тимернең яшьтәшләрен җыеп кеше талавын бәян итә. Тарихчылар исә Аксак Тимернең язу танымавын, әмма шуңа да карамастан киң эрудицияле, күп өлкәләрдә мәгълүматлы һәм үз фикере булган шәхес буларак тасвирлыйлар. Ул балачактан төрки һәм таҗик телләрен, дин нигезләрен яхшы белгән. Шул ук вакытта ул игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән күчмә һәм утрак тормышны, яшәү кануннарын, кешеләрнең психологиясен дә әйбәт үзләштергән. 1360 нчы елда Туглак Тимер Мавераннахрны яулап алгач, Аксак Тимер аңа хезмәткә керә. Шул

рәвешле Тимер 25 яшендә бай гына Кашка-Дәрья вилаятенең башына килә. Әмма 1361 елда Туглак Тимер Мавәраннәһергә хөкемдар итеп үзенең улы Ильяс Хуҗаны билгеләгәч, Тимер аның белән арасын өзә. 1361–1365 елларда Тимер Казаган хан оныгы Хөсәен белән якынаеп китә. Нигездә алар бергәләп бай табыш алу максаты белән тирә-як күршеләренә һөҗүм итү белән шөгыльләнәләр. 1365 елда Тимер белән Хөсәен гаскәр туплап Ильяс хуҗага каршы яу күтәрәләр, әмма җиңелеп кире чигенергә мәҗбүр булалар. Ильяс хуҗа гаскәре белән Сәмәркандка юл тота. Сәмәрканд халкы Ильяс хуҗага көчле каршылык күрсәтә, шәһәрне яклап кала. Әмма бу халык та Тимернең мәкере алдында чарасыз була. Аксак Тимер Сәмәркандны хәйлә-мәкер белән яулап ала. Шул урында әлегә кадәр бер булып эш иткән Тимер белән Хөсәеннең юллары аерыла. 1370 елда Тимер Хөсәенне үтертә. Шушы вакыйгадан соң Аксак Тимер тормышында зур үзгәрешләр башлана. Корылтай карары белән Аксак Тимер Мавәраәннәһернең бердәнбер хакиме итеп билгеләнә. Шул вакыттан Тимернең җимерүче сәләте, ерткыч табигате тагын да ныграк ачыла башлый.

Аксак Тимер хакимияткә килүенең беренче көннәреннән ике юнәлештә эш алып бара: бер яктан бердәм, нык дәүләт төзү һәм икенчесе – басып алынган дәүләтләрне талауга корылган сугышлар. Тимер Фәрганәне яулап алып Мавәраәннәһергә куша. Яшь хөкемдарның авторитетын күтәргән икенче адымы – Харәземне Тимер дәүләте составына кертү була.

Тимернең иң зур максатларының берсе – Алтын Урданы үзенә буйсындыру, аның хакимен үзенең вассалы ясау була. Туктамыш ханның Алтын Урданың ике өлешен бергә кушуы, аның территориясен киңәйтергә омтылып басып алу походлары оештыруы да Тимернең планнарына туры килми. Җүчи Олысын яулап алырга теләп, ул берничә поход оештыра. 1391 елда хәзерге Самара белән Татарстанның Чистай шәһәре арасындагы Кондырча дигән җирдәге каты бәрелеш вакытында Туктамыш җиңелә, әмма бу Алтын Урданың җиңелүе булмый әле. Араларында көрәш дәвам итә. 1395 елда Төньяк Кавказда яңа бәрелеш була. Бу юлы Туктамышны җиңгән Тимер, Алтын Урданың башкаласы Сарай Бәркәгә барып җитеп, аны җимертә. Идел буендагы башка шәһәрләрне, шулай ук Кырым, Төньяк Кавказ һ.б. төбәкләрдәге шәһәрләренә зур зыян сала. Тимернең Алтын Урдага, Харәземгә юнәлгән яулары Урта Азияне ныгыту максатыннан оештырылган. Ә Урал, Кавказ арты территорияләренә, һәм тагын да ераграк оештырылган яулар икенче максатны – шул илләрне талауны күздә тота.

Аксак Тимернең талау сугышлары да, басып алу сугышлары да яулап алынган территорияләрнең халыклары өчен гаять мәрхәмәтсез була. Гаскәрендә шәфкать, аяу дигән төшенчәләр ят булып, яулап алынган халык таланып кына калмый, күпчелек очракта шәһәр-авыллар, еш кына аның

халкы да, тулысынча юк ителә. Шул рәвешле ул Әрмәнстан, Грузия, Әзербайҗанны, Һиндстанны, Госманлы дәүләтен басып ала. Тимернең соңгы сугышы тәмамланмыйча кала. Ул 1404 елда Кытайны яулап алу һәм талау өчен сугыш башлый, 1405 аның елда вафатыннан соң, сугыш туктала. Шул рәвешле Кытай дәүләте җимерелмичә, халкы таланмыйча кала.

Аксак Тимер күпме генә җирләрне яулап алса да, бары Мавәраәннәһерны гына үз кулында тота. Башка җирләрне үзләренең элекке хантүрәләренә яки улларына бирә. Ягъни, Тимернең дәүләте аерым феодаль биләмәләрдән тора һәм бары аның корыч ихтыяры гына барлык вассалларын буйсындырып, аларны бербөтен дәүләт буларак җыеп торырга мөмкинлек бирә. Шунлыктан Тимер үлү белән дәүләте дә таркала башлый.

Аксак Тимер тарихка да, фольклорга да берничек тә акланмаган явызлыгы белән керә. Тарихчылар явызлык эталоны булган Тимер бәкнең түбәндәге гамәлләрен теркәп калдыра: Кан түкмәскә вәгъдә биргән Тимер бәк Баязитның биш мең кешесен тереләй күмә; Галеб шәһәренең канавына тирә-якта яшәүчеләрне тереләй тутырып, өсләреннән үтеп, шәһәрне ала; Шәм-Шәриф (Дамаск) шәһәренең утыз мең кешесен храмга бикләп, тереләй яндыра; Шәм-Шәриф шәһәрен алганнан соң, сугышчыларының һәрберсенә берәр кеше башы китерерә кушыла, алардан өч башня өелә [Путешествие Ивана Шильтбергера:1866. С.19–21]. Бу очракта утыз мең конкрет сан булмыйча, күплекне генә аңлата дип уйларга мөмкин. Аксак Тимернең үзе алган шәһәрләрдәге халыкны үтереп, кеше башларыннан пирамидалар төзүе күп тарихчылар хезмәтләрендә искә алына. Явыз бәкнең ерткычлыгының иң югары ноктасы Исфахан шәһәрен алганда күзәтелә. Ул башта ирләрне һәм ундүрт яшьтән олырак ир балаларны үтерергә әмер бирә. Үтерелгәннәрнең башларыннан шәһәр уртасында тау өелә. Хатын-кызлар белән калган балаларны кырга куып чыгаралар һәм җиде яшьтән кечерәк балаларны – җиде мең сабыйны аерып алалар. Әлеге балалар аналарының күз алдында атлы гаскәр тарафыннан таптатыла [Путешествие Ивана Шильтбергера:1866. С.27]. Бу фактлар барысы Тимер бәкнең явызлыгын бәян итә, халыкларның Аксак Тимергә нинди мөнәсәбәттә булуы турында сөйли.

Тимер бәк үзен чын мөселман дип күрсәтергә омтыла, янында һәрвакыт шәехләр, дин әһелләре була. Әмма аның мөселманнар яшәгән илләргә карата кылган гамәлләре мөселман булмаган халыкларга булган мөнәсәбәттән берничек тә аерылмый.

Аксак Тимер исеме фольклорга үзе исән чакта ук кереп халык иҗатында безнең көннәргә кадәр сакланган. Образы татар халкының дастаннарында, риваятьләрендә, бәетләрдә дә тасвирлана. Татар дастаннарында ул үзенең мәшһүр замандашлары Идегәй бәк (бий) һәм Туктамыш ханга

мөнәсәбәтле тасвирлана. В.В. Радлов тарафыннан язып алынган «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи» дигән хезмәтенең Себер татарларының халык иҗатына багышланган IV томында «Аксак Тимер» дигән риваять, татар халкының «Чынгызнамә» дастаннар җыентыгында Аксак Тимергә багышланган дастан, һәм әлеге шәхескә багышланган күп санлы риваять-легендалар, язма әдәбият үрнәкләре бар.

Татар халык иҗатына һәм әдәбиятына Аксак Тимер Шәһри Болгарны, Болгар дәүләтен җимерүче, кан коючы, яндыручы вәхши «хан» буларак кереп кала.

XV йөзнең икенче яртысы, XVI йөз башында иҗат иткән Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәд Әминнең «Гыйкаб» дигән шигыре Аксак Тимергә багышланган. Шагыйрь Аксак Тимерне бөтен кешелек өстенә килгән бәла буларак тасвирлый:

Чыкны һиҗрәттән йиде йөз илледә –
Төшде галәмгә хәраблык зилзилә.

Аксак Тимернең яулап алулары аның әсәрендә бөтен дөньяның астын-өскә әйләндергән җир тетрәүләр белән чагыштырыла. Характеристика бик тискәре, ул шагыйрьнең, һәм аның иҗаты аша халыкның Аксак Тимергә булган мөнәсәбәтен белдерә:

Үзе аксак, гаклы – ахмак, фетнәдер
Золымыны изһар кылды һәр йирә.

Шунысы игътибарга лаек, Мөхәммәд Әмин Аксак Тимернең Болгар илен җимерүен Ислам дипенә кылыч күтәрү, мөселман илен җимерү, галимнәрне һәм шәехләрне юк итү буларак карый. Үзен хак мөселман буларак танытырга теләгән Аксак Тимернең мөселман халыкларга каршы яу белән чыгуын ул ахирәттә дә гафу ителмәслек гөнаһ саный:

«Йа илаһи, әйлә ул бәндәңне сән
Ахирәтдә залим вә җаһил илә», – дип яза.

Татар халкының «Чыңгызнамә»сенең икенче әсәре – «Тимер нәселе турындагы дастан». Автор үзенең героен «хәзрәте Аксак Тимер» дип атый һәм нәкъ менә шушы – явыз бәкне «хәзрәте» дип зурлау авторга үзенең героена карата булган чын мөнәсәбәтен яшерергә мөмкинлек бирә. Дастанның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт.

Һиндстан шәһәрендәге Чыңгыз хан углы Җодай хан бер көн төш күрә. Төш юраучылар әлегә тумаган баланың Җодай хан үлеменә сәбәпче булачагын әйтәләр. Авырлы хатынны эзләп табып, корсагында таптап, карынындагы баланы үтерергә телиләр. Ана карынындагы тумаган бала исән кала, ул бер аягына гарип булып туа. Исән калганга җаны тимер икән

дип, исемен дә Тимер дип куялар. Тимер бик яшьтән ятим кала. Бозаулар көтеп көн күрә. Яшьтәшләре арасында үзен «хан» итеп билгели. Үз янына яшьләрне җыеп, сатучы-сәүдәгәрләрне талап, малларын алып, үзләрен кырып яши башлыйлар. Алдау белән Җодай ханны үтерә, үзе аның урынына Һиндстанга барып хан була. Аннан Мисыр шәһәрен ала, Истанбул шәһәренә юнәлә, мәкер ярдәмендә аны да ала: үзен сырхау итеп күрсәтеп, шәһәр капкаларын ачтыра. Бер-бер артлы Хаҗи Тархан, Болгарны ала. Капкаларын ачуга карамастан, Бүләр халкын да кыра.

Әсәрдә Аксак Тимернең һәр эше Хак Тәгаләдән килә дигән караш үткәрелә: «Әмма аңа Тәңре Тәгалә яр-юлдаш булгандыр, шәһәрләр, йортлар алуга, урдалар вәйран булуга аны сәбәп кылгандыр. Һәр яхшы-яман Тәңре Тәгаләнең әмере, тәкъдире белән эшләнә. Аның боерганыннан тыш һичбер эш булмый... Тәңре Тәгалә аңа [Аксак Тимергә] яр булды» [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 26]. Аксак Тимернең Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән җәза булу мотивы очраклы түгел. Ул халыкыбызның Аксак Тимернең «Автобиография»сеннән хәбәрдар булуын күрсәтә. «Автобиография»дә Аксак Тимер үзен Аллаһы Тәгаләнең кылычы дип атый һәм кан коюларын гөнаһларны юк итү дип аңлата. Икенчедән, шул рәвешле, халык үзенең җиңелүен аңлатырга да омтыла. Әмма бу авторның Аксак Тимергә булган чын мөнәсәбәтен яшерә алмый. Һәрбер эпизодта Аксак Тимернең мәкерле асылы, мәгънәсез кан коюы, ерткычлыгы яңа яктан ачыла бара. Аксак Тимер бер кайчан да намуслы эш итми. Бала чагында бозау көтә – үзенә ышанып тапшырылган бозауларны суя. Үсеп киткәч сәүдәгәрләрне кырып, талап яши. Халык исә юлга чыгарга курка башлый. Җодай хан җибәргән илчеләрне юк итәләр, алдау юлы белән Җодай хан үзе дә үтерелә. Аксак Тимер һәр очракта намуссыз, астыртын эш итә. Ул, үзеннән көчлерәкләрне бары алдау-мәкер белән генә җиңә ала. Шаһ Солтанны да, Җодай ханны да шулай үтерә. Авторның Тимер бәккә мөнәсәбәте Шәһри Болгарны алганда да ачык күренә. Ул әрнүен яшерә алмый: «Шәһри Болгарны алдылар, харап кылдылар, йөз дә егерме дүрт олуг бик бар иде, аларның барысын да кырдылар, һәркайсының энҗе кебек хатыннарын Аксак Тимер әсир кылды» [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 28].

Дастанда Бүләр шәһәре тарихын тасвирлауга зур игътибар бирелә. Алыплар заманында Зәй тамагында Бараҗ дигән аждаха елан яши. Шундагы халык аждахадан качып Болгар янына китә һәм Бүләр шәһәрен сала. Шуңа күрә бу халыкны «Бараҗ халкы» дип йөртәләр. Халык Аксак Тимерне шул аждаха белән тиңли. «Инде Бараҗдан көчлерәк Аксак Тимер килде» [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 28]. Бүләрнең ханы – Самат хан киңәш сорап изгеләргә мөрәҗәгать итә. Изге кеше Аксак Тимер белән сугышуның файдасыз икәнен әйтә: «Сугышырга рөхсәт юк.

Хәзрәте Хуҗа Хызыр галәйһиссәлам аның гаскәрендә. Тәңре Тәгаләнең тәкъдиренә буйсынырга кирәк, капкаларны ачтыр», – ди [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 28]. Әмма капкаларны ачу да Бүләр халкын саклап кала алмый. Аксак Тимер гаскәре белән кереп коралсыз халыкны кырып сала. Коралсыз халыкны, тыныч халыкны үтерү дә Аксак Тимернең чын асылын күрсәтә. Аксак Тимер үзен танытмыйча Барадж халкы арасында йөри һәм үзе турында начар фикердә булган кешеләрне нәселе-тамыры белән һәлак итә. Аксак Тимер Бүләрдән соң Владимирга юнәлә. Владимирга җиткәч, хәзрәте Хуҗа Хызыр галәйһиссәлам килеп Аксак Тимергә: «Сиңа бу кяферләр белән сугышырга вәгъдә ирешмәде», – дип хәбәр бирде [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 30]. Аксак Тимер Владимир шәһәрен алмый. Шулай да, Владимир халкына үрелеп «кәрамәтен» күрсәтә. «Өч яшьлек тайны кяферләр тарафына ташлады. Хак Сөбханә вә Тәгаләнең кодрәте белән ул ташлаган тай кяфернең таш манастыйрын урталай ярып, бер чакырым җиргә барып төште. Тай төшкән җирдә су булды» [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 31]. Владимир каласыннан Тимер бәк Бохарага юнәлә. Автор Бохара халкының киңәшкә җыелуын сурәтли. «Ту бия суеп, халкын җыеп кай тарафка күчик дип киңәш кылдылар. Шунда халык арасыннан берәү атын мактады, берәү этен мактады, берәү алган хатынын мактады. Пешкән ит, аш ашалды, киңәш булмады, халык таркалды» [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 31].

Автор халыкның таркаулыгын әрнеп бәян итә, илбашының халкын якларга сәләтле булмавын күрсәтә. Амәт белән Самат дигән ике хан беренче булып качып китәләр. Аксак Тимер гаскәре ханны, халыкны тоталар. Алга таба Аксак Тимер Бохара халкын ислам диненә кертүче миссионер буларак хикәя ителә. «Исламны өйрәттерде, үзе бер-ике ел шул күчмә халык арасында торды, мөселманнык динен белдерде» [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 32]. Әмма халыкның ислам кабул итүе дә, аны Аксак Тимердән коткармый, ул Бохараны яулап ала, Аксак Тимер гомеренең соңын Сәмәрканд шәһәрендә үткәрә, һәм шунда фани дөньядан үтә.

Дастанда бәян ителгән вакыйгалар тарихилыкка дәгъва кыла алмый. Шул ук вакытта әсәр Аксак Тимернең шәхесе турында шактый мәгълүмат бирә. Контекстта Аксак Тимергә карата авторның тискәре мөнәсәбәте яхшы аңлашыла. Иң беренче күзгә ташланган момент – урта гасырлар әдәбиятының төп концептларының берсе – язмыш мотивы. Әлеге мотив төрки әдәбиятта да, фольклорда да бер әсәрдән икенчесенә күчә. Кешенең дә, халыкның да тормышы алдан билгеләнгән булу, Аллаһы Тәгалә тарафыннан язылган булу, алдан язылганнан – язмыштан узмыш булмау – әлеге әсәрләрдә шушы фикер уздырыла. Дастан авторы да әсәрен шушы идеягә иллюстрация рәвешендә бирелгән хикәят белән башлый.

Хикәяттә бәян ителгән вакыйгаларга карата үзенең мөнәсәбәтен дә «Ул ахмак тәкъдирне тәдбир белән бозмак теләде. Хак Тәгаләнең тәкъдире ничек бозылыр», – дип белдереп куя [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 23]. Шушы фикергә кат-кат әйләнеп кайтыла. Мәсәлән, алга таба Аксак Тимерне Аллаһы Тәгалә тарафыннан язмыш коралы итеп сайлануы турында сүз бара: «Әмма аңа Тәңре Тәгалә яр – юлдаш булгандыр, шәһәрләр, йортлар алуга, урдалар вәйран булуга аны сәбәп кылгандыр һәр яхшы-яман Тәңре Тәгаләнең әмере, тәкъдире белән эшләнә. Аның боерганыннан тыш һичбер эш булмый» [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 26].

Автор Аксак Тимернең нәселен бәян итеп, аның бер яктан да хөрмәткә лаек булмавын, чыгышы-нәселе белән дә, тәрбиясе-белеме белән дә бик түбән дәрәҗәдә торуын күрсәтә. Гаять зур территорияләрне басып алган Аксак Тимер гомере буе «бөек әмир» булып кала. Чыңгыз чорыннан килгән законнар буенча, тәхет мирас булып бары Чынгызханлыларга гына күчә. Аксак Тимер дә тәхетен Чыңгыз ханның икенче улы Чагатай нәселеннән булган Сөюргатмыш (1370–1388) һәм аның улы Мәхмүд (1388–1402) белән бүлешергә мәҗбүр була. Шулай да, фольклор әлеге шәхесне хан дип атый. Шул рәвешле Аксак Тимер бары фольклорда гына булса да, әлеге олуг дәрәҗәгә ирешә. Шулай да, әсәр башындагы хикәяткә тагын бер функция йөкләнелгән. Һиндстан шәһәрендә хан булган Чыңгыз хан углы Җодай күрсәтмәсе белән Аксак Тимерне туганчы ук үтерергә омтылалар. Туганчы ук имгәтелгән баланың бөтен дөньяга нәфрәте, ерткычлыгы шул рәвешле аклана. Әмма бу эпизод тарихи фактларга туры килми. Бу халыкның Аксак Тимернең гамәлләрен аңлатырга омтылуы гына. Фольклор туганда ук рухи һәм физик яктан имгәтелгән Аксак Тимернең бөтен дөньядан үчле булуын шул рәвешле аклый.

Рус елъязмасында сакланган мәгълүмат буенча, Аксак Тимер үсеп җиткәч, юлбасарлык белән шөгыльләнгән вакытта, имгәнә: «Единаче бо ему тогда младу сущу, во убожьстве крадый ядяше, иже у некого да украде овцю, они же абие очитиша его. Он же мняшеся убежати, но скоро многими постиженъ бысть и ятъ бысть, и удержанъ крепко, и биша его нещадно по всему телу, и умыслиша ему дати язву смертную, яко да убиють; и перебиша ногу и бедру его на полы, и абие повергоша его яко мертва, недвижющася и не дышюше; мняху убо, уже умре, и оставиша его псомъ на снедение. Едва уздравися от таковая смертоносныя язвы, въста, перекова себе железомъ ногу свою перебитую, таковою нужею храмаше; того ради прозванъ бысть Темирь Аксакъ» [Повесть о Темир Аксаке: 1981. С. 231].

Аксак Тимер бик яшьтән ятим калып, ата-ана тәрбиясе күрми. Көтү көтеп үз көнен үзе күрә. Тарихчылар да, мәсәлән, Бартольд, Аксак Ти-

мернең ерткычлыкларын аның гарип аяк-кулларының түзә алмаслык авыртулары белән бәйләп аңлаталар.

Алтын Урда дәверендә тәхеткә хокук кан белән күчә, ягъни атадан балага мирас булып тапшырыла. Дастанда тасвирланган сюжет буенча түбән катлаудан чыккан Аксак Тимернең хан булырга омтылуы бу кануннарга туры килми. Дастан кысасына кергән икенче хикәяттә Аксак Тимерне аксак кырмыскадан гыйбрәт алуы турында сүз бара. Аксак кырмысканың тырмаша-тырмаша кәшанәгә менүен күзәткән Аксак Тимер үзенә дә кырмыска кебек тырыш булырга кирәк дигән фикергә килә. Шул рәвешле алдына олы максатлар куеп, шуларга ирешә.

Дастанда Аксак Тимернең Болгар һәм Бүләр (Биләр) шәһәрләрен алуына зур урын бирелә. Аксак Тимернең әлеге шәһәрләре җимерүе күп санлы риваять-легендаларда да бәян ителә. «Казан бәете»ндә дә Аксак Тимернең Болгарны алуы турында юллар бар:

Тарихе йите йөздә килде Тимер Болгарга,
Габдулла ханның кулындин Болгар шәһәрен алдия.
[ТХИ. Бәетләр: 1983. Б. 25]

Татар халкында Аксак Тимернең Болгар һәм Биләрне алуы турында риваять-легендалар да күп. Аларда Аксак Тимернең әлеге шәһәрләрне алуы, халыкның басып алучыларга каршы көрәше, Болгар ханының улларының Иске Казанга нигез салуы турында сүз бара. Әлеге әсәрләрнең кайберләре «Аксак Тимер нәселе турындагы дастан»да очрыйлар. «Аксак Тимер» дигән риваять бер «ил падишасы»ның төш күрүе белән башлана [ТХИ. Риваять һәм легендалар: 1987. Б. 29–31]. Анда Аксак Тимернең тууы, исеменең мәгънәсе, аксак кырмыска турындагы риваять, Аксак Тимернең янына юлбасарлар җыюы, юлбасарлык белән шөгыльләнүе, Истамбулны алуы турындагы эпизодлар бар. «Аксак Тимер нәселе турындагы дастан»да булмаган бер эпизод – Аксак Тимернең Казанны һәм Дәвеш шәһәрләрен алуы тасвирлана.

«Болгарның харап булуы» дигән риваять Мөслиминең «Рисаләи Тәварих Болгария вә зикре мәүляне хәзрәте Аксак Тимер вә хәрабе шәһре Болгар» хезмәтендә теркәлгән [ТХИ. Риваять һәм легендалар: 1987. Б. 34–35]. Мөслими Аксак Тимернең Болгарны җимерүендә Болгар халкын гаепли: «Әнкыйсса, безнең Болгар әһле бозык вә гыйсъян илә мәшһүр иделәр... Аллаһы Тәгаләгә гөнаһлы булдылар. Аллаһы Тәгалә шуның өчен Аксак Тимер хәзрәтне мөсәлләт кылды» [ТХИ. Риваять һәм легендалар: 1987. Б. 34].

Берничә риваятьтә Болгар кызларының Аксак Тимер яуларына каршы көрәше турында сүз бара. Мәсәлән, «Кырык кыз» дигән риваятьтә Болгарның 40 кызның хан кызы җитәкчелегендә Аксак Тимергә каршы

сугышта һәлак булулары бәян ителә [ТХИ. Риваять һәм легендалар: 1987. Б. 36]. «Янмый торган кыз» риваятендә Габдулла ханның «үзенең акыллыгы һәм яхшылыгы өчен, изге дип аталган» кызының хөкем палатасы янганда исән калуы һәм Аксак Тимернең аны алып китүе тасвирлана [ТХИ. Риваять һәм легендалар: 1987. Б. 36].

Татар риваятьләрендә Иске Казан каласының корылуы да Аксак Тимер исеме белән бәйле. Бу әсәрләрдә Бүләр (Биләр) һәм Болгар калалары җимерелгәннән соң Казанга нигез салыну турында сүз бара. «Утсыз кайный торган Казан» дигән риваятьтә Аксак Тимернең Бүләрне алу ысулы бәян ителә. Аксак Тимер «хан» Бүләрне алырга тели, әмма күпме генә тырышса да, шәһәр Аксак Тимергә бирелми. Шуннан соң Аксак Тимер хәерче киемнәре киеп бер карчыкка керә. Теге карчык Аксак Тимернең кем икәнен белмичә шәһәрне ничек алып булганын сөйләп бирә: «Аксак Тимер хан безнең шәһәрне алма кели, ул аны күгәрчен аягына ут төртеп җибәрсә генә алыр», – ди. Аксак Тимер карчыкка бөтен әйберләрен алып Бүләрдән китәргә куша. «Кай төштә, астына ут якмыйча, казан астында ут янып китә, шунда туктап урнашып кала», – ди [ТХИ. Риваять һәм легендалар: 1987. Б. 43]. Бу риваятьнең «Бүләрне яндыру» дигән вариантында Аксак Тимер исеме телгә алынмый. Анда да күгәрченнәр тотып, аларның тәпиләренә чүпрәк бәйләп, ут төртеп җибәрелү турында сүз бара. Күгәрченнәр, Бүләрнең салам түбәле йортларындагы ояларына барып кунып, йортлар янып китүгә сәбәп була.

Аерым крепостьларны шушы ысул белән алу төрле халыкларның тарихи фольклорында һәм борынгы әдәбиятта тасвирлана. Аның бер мисалы борынгы рус әдәбияты үрнәге «Повесть временных лет»та да чагылыш тапкан. Княгина Ольганың древляннарның шәһәре Искоростеньне алуы шул рәвешле тасвирлана. Ул, ире князь Игорьне үтергән древляннарның шәһәре Искоростеньне җәй буе камап торса да, ала алмый. Шуннан соң хәйләгә керешә, һәр йорттан өчәр күгәрчен һәм өчәр чыпчык тотып бирүләрен сорый: «Она же сказала: «Нет у вас теперь ни меду, ни мехов, поэтому прошу у вас немного: дайте мне от каждого двора по три голубя да по три воробья. Я ведь не хочу возложить на вас тяжкой дани, как мой муж, поэтому-то и прошу у вас мало. Вы же изнемогли в осаде, оттого и прошу у вас этой малости» [Повесть временных лет: 1996. С. 165] Княгина Ольга чыпчык-күгәрченнәрне үзенең сугышчыларына тарата һәм һәрберсенең аягына ут төрткән сүс бәйләргә куша. Кич белән кошларны җибәрәләр. Алар кире үз ояларына, шәһәргә оча. Бөтен шәһәр яна башлый.

«Туйбикә казаны» дигән риваятьтә дә Казан шәһәренә Аксак Тимер Болгарны туздыргач, шуннан күчеп киткән кабилә нигез салуы сөйләнә [ТХИ: Риваять һәм легендалар: 1987. Б. 43]

«Иске Казан каласының корылуы» дигән риваять эчтәлеге белән «Аксак Тимер турындагы дастан»га охшаган. Монда да Болгар һәм Бүләр шәһәрләре җимерелү турында сүз бара. Аксак Тимер Болгарны җимереп, аның хөкемдары Габдулла ханны үтергәч, ике сабый баласы – шаһзадәләр исән калган. Болгар шәһәренең олылары ханның нәселен саклап калырга омтылып, аларны Бүләргә озата. Аксак Тимер Бүләрне дә алгач, ханбикә ике улын – Алтынбик һәм Галимбәкне алып, Аксак Тимернең каршына чыга: «Падишаһларның падишаһы, олы ханым-солтаным хәзрәти Биктимер! Менә мин ике улым – ханзадәләрне алып, синең хозурыңа мәрхәмәтеңне өмет итеп килдем, мин гөнаһлы Габдулла ханның хатыны, бу балалар аның ике улы. Мәрхәмәт итеп, бу ике балага аталарының рухына Коръән укырлык бер җирдә урнашып, үзебезнең Болгар йортында безгә торырга рөхсәт итсәгез иде. Сез күп яшәгез, бөтен җиһанның дәүләте, көч вә кодрәте сезгә булсын», – ди. Ханбикәнең сүзләре Аксак Тимергә бик ошый, һәм ул аларга үзләре теләгән урында кала корып торырга рөхсәт бирә. Шулай итеп Иске Казанга нигез салалар [ТХИ. Риваять һәм легендалар: 1987. Б. 45–47].

Гомумән, Аксак Тимер турындагы татар халкында таралган риваятьләрдә тарихи чыганаклар белән аваздаш эпизодлар күп. Мәсәлән, аның халык фикерен белү өчен, үзен танытмыйча халык арасында йөрүе «Утсыз кайный торган казан» дигән риваятьтә бәян ителә. Тарихчылар Аксак Тимернең халык арасында үзе турыда, аның варислары турында фикерне белер өчен үзенең үле хәбәрен таратуын язалар. Г. Клавихо язуы буенча: «Уже дважды Тамурбек выдавал себя за покойника, распространяя слухи о своей кончине в своих владениях, чтобы посмотреть, кто же восстанет, а кто возмущался, тех он тотчас хватал и предавал казни» [Клавихо: 1992. С. 343].

Йомгак ясап әйткәндә, татар фольклорында Аксак Тимер образы дастан, риваять, бәетләрдә саклана. Бу образ тарихи чыганакларга нигезләнеп тасвирланса да, ул нигездә, басып алучы, явызлыгы белән аждаха кебек шәхес буларак ачыла.

Әдәбият

1. Гонсалес де Клавихо Руи. Дневник путешествия в Самарканд ко двору Тимура: 1403–1406 / Пер. со староисп. СПб., 1881.
2. Дәфтәре Чыңгыз-намә /Китапны басмага хәзерләүче, сүзлек һәм аңлатмалар авторы – Сәлим Гыйләҗетдинов. Казан: «Иман», 2000.
3. Повесть временных лет /Подготовка текста, перевод статьи и комментаии Д.С. Мехачева. Санкт-Петербург: Наука, 1996.
4. Повесть о Темир Аксаке // Памятники литературы Древней Руси: XIV – середина XV века. М., 1981.

5. Путешествие Ивана Шильтбергера по Европе, Азии и Африке /Пер. с нем. Одесса, 1866.
6. Сборник материалов относящихся к истории Золотой Орды. Извл. из персидских сочинений собр. В.Г. Тизенгаузеном. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1941.
7. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Т. I. Извлечение из арабских сочинений, собранные В.Г. Тизенгаузеном. СПб., 1884.
8. Тамерлан. Автобиография. Уложение. М.: Изд-во ЭКСМО, 2005.
9. Тамерлан: Эпоха. Личность. Деяние / Сост., обр. и подг. текста Р. Рахманалиева. М., 1992.
10. Татар халык иҗаты. Бәетләр / Төз. Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.
11. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / Төз. С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.

Р.Р. Исхаков

УФИМСКИЕ СЛОБОДСКИЕ СЛУЖИЛЫЕ ТАТАРЫ – НАСЛЕДНИКИ АК-ИДЕЛЬ УЛУСА

Служилые татары, как особая социальная страта в составе населения Уфимского уезда, в русскоязычных документах начинают фиксироваться со времени основания крепости Уфы и возникновения одноименного уезда. В «Отводной книге по Уфе» (начало 1590-х гг.) отмечалось наличие в окрестностях Уфимской крепости Татарской слободы на р. Урюзя. Таким образом, Татарская слобода уже существовала или возникла в период строительства Уфимской крепости. Если о времени появления городского населения Уфы можно делать однозначные суждения – это были служилые люди из Центральной России и Среднего Поволжья, переселенные сюда вскоре после возведения Уфимской крепости, то со слободскими татарами не всё так однозначно. Обратимся к документам отводов поместных дач по Уфе в 1591 г. В этом году поместными окладами были пожалованы «уфимские возжи, слободские татаровя без хлебного жалования Шугарко Коккузов и Игиличко Земанов. Дано им государева жалованья пашни на Великом поле по той же реке под Высоким же бугром подле Шугуровы же да Игиликовы пашни по 4 чети в поле человеку, а в дву потому ж, оклад их сполна» [Текст: 1971. С. 266].

Итак, за службу двум слободским татарам были отведены участки пашни по 4 чети. Здесь же указывалось, в чем заключалась их служба – они были возжи, т.е. служилые люди, выполнявшие функции проводников в дальних походах. Возжами служили представители местного населения, хорошо знавшие географию и жителей данного региона. Это может говорить о том, что слободские татары Шугарко Коккузов (Шугур Кокузов) и Игиличко Земанов (Иглич Заманов) проживали здесь еще до прихода русских. Первый из них – Шугур Кокузов – фигура деятельная и неординарная, фиксируется и в других исторических документах данной эпохи. Шугур Коккузов принимал участие в строительстве Уфимской крепости, в 1601 г. в числе «уфимских татар» и «табынцев» состоял в дипломатической миссии к сыновьям сибирского хана Кучума, принимал участие в переходе на московскую службу будущего касимовского царя Араслана Алексеевича [Азнабаев: 2016. С. 276–277]. Заметная роль Шугура Кокузова в дипломатических отношениях с сибирскими Чингизидами может свидетельствовать о его тесной инкорпорации в татарскую (ордынскую) клановую структуру и заметном влиянии среди представителей татарской аристократии.

Можем предположить, что уфимские татары являлись наследниками Ак Идель улуса, проживавшими здесь еще во времена Казанского ханства

и Золотой Орды. О том, что земли по реке Белой со времен Золотой Орды были заселены оседлым мусульманским населением, говорят и письменные источники [Миргалеев, Аксанов: 2016. С.6]. Уфимские слободские татары имели развитую традицию земледельческого хозяйства. Еще до земельного отвода 1591 г. слободские татары Шугур Коккузов «с товарыщи» распахали не менее 140 десятин пашни, часть которой в результате размежевания была передана уфимским служилым людям. В конце XVI в. слободским татарам в качестве жалования за службу было отведены поместья: «Иткулу Бехтемирову, Сабанче Чилпанову, Исенбулату Коземанову, Игебердею Безгозеву, Шугуралею Кокузову «пашни на Великом поле по той же реке под Высоким же бугром подле Шугуровой же, да Игиликовой пашни по 4 чети в поле человеку, а в дву потому ж, оклад их сполна; да сенных покосов против города, за рекою за Белой Волошкою и около их пашен по 20 копен человеку. Да им же дано на семена по чети ржи, по чети овса человеку, да по осьмине ячменя человеку» [Текст: 1971. С.267]. Таким образом, задача слободских татар сводилась не только к военной и дипломатической службе, но и к частичному обеспечению Уфимской крепости хлебом.

Другой важной формой хозяйственной деятельности уфимских татар была торговля. В указной грамоте из Приказа Казанского дворца верхотурскому воеводе Д.И.Миславскому и подьячему В.Шестакову от 15 ноября 1633 г. сообщалось, что «казанские и уфимские татаравя ж» занимались скупкой «мягкой рухляди» (мехов) у ясачных людей Уфимской волости Верхотурского уезда [Материалы: 1956. С.71]. Скупка мехов имела такие широкие масштабы, что верхотурское руководство, опасаясь, что местному населению нечем будет платить ясак, было вынуждено ввести ограничения на эту деятельность. В челобитной, датируемой не позднее 17 февраля 1695 г., уфимские татары, а также мещеряки, казанские торговые люди просили освободить их от незаконных поборов в сборе торговых пошлин верхотурского заставного головы Гаврилы Калашникова [Материалы: 1956. С.83–84].

Возможно, схожие функции представители данной социальной группы выполняли и в период казанского и ногайского господства, т.е., опираясь на военно-торговые фактории, держали в своих руках пушную торговлю и контролировали сбор ясака. Важным условием жизнедеятельности таких центров было наличие оседлого земледельческого населения, которое могло обеспечить его продовольствием и организовать оборону в случае военной угрозы.

Весьма спорной выглядит точка зрения, предложенная А.Б.Азнабаевым. Он связывает происхождение уфимских слободских татар с салджиутами, проживавшими в Зауралье. Эта гипотеза строится на данных челобитной, датируемой 1695 г. В ней представители одного из родов Сал-

жаутской волости, обосновывая свои права на ясачные вотчины по рекам Синара, Миасс и Исеть ссылались на то, что они принадлежали их предку Ш. Акузову [Азнабаев: 2016. С. 276–277]. Является ли это достаточным основанием для вывода, что уфимские слободские татары происходили от салджиутов? Безусловно, нет. Практика передачи служилым татарам промысловых угодий, входивших впоследствии в состав ясачных вотчин поземельных волостей, была весьма распространенным явлением на начальном этапе формирования Уфимского уезда, т.е. в конце XVI – первой половине XVII вв. В 1606/1607[1] гг. служилый татарин (тархан) Авдуак Санбаев был испомещен земельным поместьем: пашнями, сенными покосами и лесами за Камой, на реках Буюн, Еловая, Узяр, которые впоследствии стали вотчинными владениями «башкирцев» Уранской поземельной волости Осинской дороги [Башкирское: 2015. С. 56]. Служилый человек Аудуак-бей фигурирует в шеджаре, обнаруженном в Янаульском районе Республики Башкортостан, где он указан в качестве одного из родоначальников уранцев [Азнабаев: 2016. С. 220]. В 1615/1616 гг. за помощь в поимке лидера антимосковского восстания народов Волго-Уралья – служилого татарина Арской дороги Казанского уезда Еналейки (Джан-Али) Емаметева, и сдаче его в Казань, служилым татарам «на житье» на реках Таньп и Нюлюза были пожалованы «Скилянское (Ички-Иланское) поместье» и урочища [Отдел рукописей: Л. 18]. В последующее десятилетие владельцы этого поместья уже фиксировались как «башкирцы», а их земли – как часть Ички-Иланской поземельной волости.

Промысловые угодья и пашни в окрестностях Уфимской крепости были пожалованы за службу «слободским уфимским татарам». Впоследствии однако они стали частью владений Минской поземельной волости. Сын того же Ш. Кокузова – Мангатай Шугуров, владел вотчинными землями по Минской дороге, за которые платил ясак, и был записан в ясачные книги как «башкирец», при этом он сохранял и статус служилого татарина. Названная гипотеза вызывает сомнение и в связи с довольно серьезными различиями в хозяйственной культуре и быте уфимских служилых татар и салджиутов. Если слободские татары были типичными представителями оседлого земледельческого населения, то салджиуты сохраняли полукочевой образ жизни и вплоть до второй половины XIX в. крайне неохотно осваивали хлебопашество.

Уфимские слободские татары принимали активное участие в военно-политических событиях, разворачивавшихся на территории Уфимского уезда и сопредельных регионов, связанных с московско-кучумов-

---

[1] А.Б. Азнабаев неверно датировал время пожалования А. Санбаеву земельных владений, определив его периодом правления Ивана IV.

ским противостоянием. В ходе военной компании в 1635 г. Кучумовичи совместно с калмыками осадили Уфу и разрушили Татарскую слободу. По всей видимости, в ходе военных действий погибла и часть жителей этой слободы. В 1645 г. поместные владения служилых татар Мангатая Шугурова, Кузубаша и Артуала в окрестностях Уфы считались «выморочными» и находились «в пусте», так как их владельцев «побили калмыцкие люди» [Азнабаев: 2016. С. 279]. Но уфимские татары, как особая группа в составе жителей Уфимского уезда, продолжают фиксироваться в документах и после описанных событий. А. Валиди-Тоган отмечал, что они «длительное время и вместе с семьями служили в войсках. На сегодняшний день живущие <их потомки> около Уфы, …заселяют деревни Буздяк, Каргалы, Ташлыгел, Ишанлыкел, Табалыкел и Калмаш» [Валиди-Тоган: 2010. С. 55]. Мнение А.Валиди-Тогана подтверждается наблюдениями академика П.С. Палласа, посетившего Приуралье в 1770 г.: «На западной, южной и северо-западной сторонах Уфы жительствуют так нарицаемые Уфимские Татара, свойственники Казанских, но давно уже в сих странах поселившиеся. Они составляют, особливо в околотках между реками Белою и Иком, многочисленные жилища. Сии Татара из всех Уфимских селенников беспорно самые прилежнейшие земледельцы, и по большей части люди неубогие. Да и как можно им не иметь довольствия и счастливого успеху при порядочном хозяйстве, кое между их видно... В окружности Уфы многие монументы, доказывающие жительство здесь некоего от башкирцев со всем особливого народа. Ибо две по ту сторону реки Диомы при отстоящих в 40 почти верстах от города Уфы Татарских деревнях Тирме и Калмаше находящиеся из кирпича строенные мечети, и многия при них надгробные камни от части с арабскими, а отчасти с коптическими надписями не башкирского суть происхождения. Также и находящиеся между Уфою и Бирским по обеим сторонам реки Белой укрепленные места доказывают, что они построены не башкирцами. Такое же укрепленное место находится еще от города Уфы по прямой линии к восточной стороне, почти в четырех верстах, и лежит на правом горном берегу реки сего названия» [Из сочинения: 2016. С. 435–436].

На протяжении XVII в. отмечается переход уфимских татар из категории служилых в состав ясачных людей. Интеграция их в состав «башкирцев» была продиктована прагматичными расчетами – хотя статус служилых людей и позволял им не выплачивать ясак, а также получить в качестве жалованья поместье, но количество предоставляемой им земли было незначительным для ведения сельскохозяйственной деятельности. Статус «башкирца», предоставлявший им возможность получить значительно большие земельные наделы, был для них более привлекательным.

В частности, «башкирцы» Минской поземельной волости, территория которой прилегала к Уфе сохраняли память о служилом статусе своих предков, утверждая царским чиновникам, что они происходят «от княжества и тарханства татарского и в разных местах бывшей Казанской… были пожалованы землями и другими угодьями» [Отдел рукописей: Л. 3].

– Иң башта халыкның болай да йөрәгенә төшкән налоглар арткан. Авыл хуҗалыгы налогы өстәвенә махсус сугыш налогын китереп салалар;

– 1941 елның 1 октябреннән ялгызакларга һәм баласызларга налог салына (хәрбиләр генә түләми);

– Йорт страховое һәм бәрәңге бакчасына түләүләр арта. Түли алмаган кешеләрдән ул җирне тартып алырга мөмкин буласы кисәтелә;

– 1941 елның 5 сентябрендә ВКП(б) ҮК карары белән халыктан җылы киемнәр җыю башлана. Бу чара өчен җаваплы итеп партиянең район секретаре үзе билгеләнә;

– 1942 елдан башлап махсус сугыш заемы кертелә;

– Самолетлар һәм танклар төзү өчен лоторея билетлары чыгарыла һәм аларны алу мәҗбүри була;

– Оборона фонды кертелә...

– Сугыш башлану белән хезмәт йөкләмәсе (бушлай эшләү) кертелә һәм бу йөкләмә сугыш беткәч тә дәвам итә әле. Мисал өчен юл төзү йөкләмәсен авыл халкы котлары чыгып искә ала иде. Чөнки бу йөкләмәне үтәү мәҗбүри һәм кешенең сәламәтлеге дә, гаилә хәле дә искә алынмый иде.

Бу хәл безнең авылга гына төшкән бәла түгел. Мисал өчен «Красная Татария» газетасында 1941 елның 26 июнь санында болай дип язылa (текст тәрҗемә итмичә китерелә): «В июне 1941 г. более 100 колхозников с 10 подводами выехали из Атнинского района» [Красная Татария. 26 июнь 1941 ел]. Бу олауларга төялеп киткән кешеләрнең кая, нинди эшкә тартылулары хакында язылмаган. Болай да аңлашыла: уенга, күңел ачарга җибәрелмәгән халык. Кая җибәрсәләр, кайда нинди эшкә – сорап тормаганнар ич. Нәкъ менә шушы көннәрдә үк «Барысы да фронт өчен!», «Барысы да җиңү өчен!» дигән шигарьләр көнкүрешкә керә.

Безнең авыл халкы элек тә мул тормыш белән яшәмәгән. Авылның башлангыч тарихын язганда сәбәпләре аңлатылды. Кешеләрнең бар тапканнары төрле-төрле налоглар түләүгә, утын сатып алырга китә иде (чөнки бездә урман юк, утынны күрше марилардан алырга мәҗбүр иделәр). Колхозның җирләре аз, елга кырыйлары, кызыл балчык, уңдырышлы җирләр түгел. Уңдырышлы җирләре – әнә шул безнең җирләргә китереп утыртылган русларның Атамыш авылында иде. Бу хәлне авыл халкы белеп торды. Тик гаделсезлекләргә түзми чарасы гына булмады. Тарихи әсәрләрдән укыгач та бер безнең авыл халкы өчен генә түгел, гомумән, Татарстан крестьяннары өчен гаделсезлек күзгә бәрелеп тора.

Бер генә мисал китерик. 1928 елда Татарстанда икмәк хәзерләү планын үти алмаган районнар күп була. Халык яңадан ачыга, ачлыктан шешенә башлый. «Ә бит күрше республикаларда һәм өлкәләрдә, – дип яза олуг тарихчы галимебез И.Р. Таһиров, – бөтенләй диярлек икенче хәл була. Әйтик, Татарстанга күрше булган Мәләкәс өязендә бу чорда крестьяннан икмәк җыюның нәрсә икәнен дә белмәгәннәр» [Таһиров: 1998. Б. 261].

Башка төрле салымнар, заем түләве белән дә шул ук хәл. Бу заем сугышка хәтле үк халыкның йөрәгенә төшкән салым иде. Тагын бер мисал китерик: 1928 елның 18 гыйнварында Молотов имзасы белән республика партия оешмасына крестьян заемы хакында хат җибәрелә. Хатта мондый сүзләр була: «Һәр крестьян заем облигациясен алырга тиеш. Заемны уңышлы урнаштыру крестьян хуҗалыгын күтәрер, хезмәт иясе булган крестьянның тормыш шартларын яхшыртыр» [Шунда ук: Б. 258].

Татарда «көл дә, ела да» дигән әйтем бар. В. Молотов крестьян хуҗалыгы күтәрә алмаслык салымның тормыш дәрәҗәсен яхшырта алмаслы-

гын белмәде микәнни? Чыннан да аның сүзләреннән көләсе килсә дә, еларлык хәл бит. Совет хакимияте җитәкчесе, күренекле революционер имеш…

1942 елда игълан ителгән заем да шулай ук – кеше тормышын ничек яхшыртсын ди? Аяктан екты бит инде ул түләүләр тол хатыннарны. Гадәттә Сталин заемны 5 млрд сумга чыгара да, март, апрель айларында яздыру ук башлана. Ә чыгуы хакында карар бары май ае башында (5 нче майда) игълан ителә. Акчаны, кагыйдә буенча, шул карар чыккан көннән соң гына җыя башларга тиешләр. Әмма урындагы җитәкчеләр, кешеләрнең йөрәкләренә төшеп, әйтеп киткәнчә заемга дигән исемлеккә кул куйдыру башланачагын халыкка белдерәләр. Халыкның күзеннән кан ага, яшь түгел, үз хәленең авырлыгын, балаларының ятимлеген аңлатырга тырыша. Аңлаучы юк, юк аңлаучы... Карар чыккан көннән китә «шатлыклы» җыелышлар, бөек юлбашчыга рәхмәтләр укып хат язулар, рапорт бирүләр, җырлар.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Сталин.
Син яшәсәң, без яшәрбез
Мәңге яшә Сталин!

Өебезгә кайбер кышларны колхоз кәнсәләрен кертә иде әни. Апам белән без икәү, безнең балачак. Утын табу, өй җылыту әнинең үзәгенә үткән нәрсә иде. Менә шунда кеше хәсрәтенең тирәнлеген аңлый башладым да кебек. Кич белән, төнгә каршы безнең өйгә, ягъни кәнсәләргә тол хатыннарны заемга кул куярга дип чакырталар иде. Бу чакырып сөйләшү, кешенең җанын алуга тиң. Анда елаш, заем суммасын балалар хакына бераз гына булса да кечерәйтүне үтенүләр әле дә онытылмый. Балачагымның иң күңелсез, мәңге онытмаслык күренешләре иде бу хәл.

Бу «җәзалау»ны гадәттә 3 кеше алып бара: авыл Советыннан 1 кеше, 1 укытучы (аларны да мәҗбүр итәләр иде), 1 кеше район вәкиле, яисә комсомол оешмасы әгъзасы. Аларга багышлап чыгарган җырларның берсе:

Миләшләр кызарган микән,
Болыт таралган микән.
Замана нәчәльникләре
Эттән яралган икән.

Ул акчаны кайдан табарга тиеш булды икән әниләр? Күпме түләүләр, салымнар өстәвенә бит бу заем! Соңрак, әйтеп узганча, танклар, самолетлар төзү өчен акча лотореясы да бар бит әле.

Июнь аенда ук шәһәрләрдән эвакуация белән кешеләр кайта башлый. Безнең авылга да үз авылыбыздан киткән кешеләрнең гаиләләре кайта.

Әмма бу күрешүләр бик моңсу булгандыр. Сагынып, хәл белергә дип кайту түгел бит. Бу хакта Сәләхова Әлфиянең истәлекләре бар.

Безнең авылда эвакуация белән кайткан башка кешеләрне хәтерләүчеләр юк. Күрше Югары Көектә Мурманск өлкәсе Кандалакша шәһәреннән кайтучылар булган. Алар «Социализм юлы» газетасында үзләренә булган җылы караш, хөрмәт өчен рәхмәт әйтеп язганнар икән [Социализм юлы 16 январь, 1942 ел].

Тагын бер истәлек. Дөбъяз районы Өлә авылында Украинадан эвакуацияләнгән бер хатын яшәде. Вәрига әбием, мине җитәкләп аның янына фронтта булган улы – әтиебез Әхмәт хакында сорашырга еш барып йөрде. Ул хатын күрәзәчелек белән шөгыльләнгән булгандыр, чөнки әби генә түгел, башкалар да йөргәннәр икән.

Безнең авыл болай да ярлы яшәгәнгәме, әллә кертеп урнаштырырга яраклы биналар булмаганмы – килүчеләрне хәтерләмиләр. Ә 1941 елның сентябрендә үк эвакуация белән Татарстанга килүчеләр саны 66,9 меңгә, 1942 елның февралендә инде 151719 га җиткән. Килүчеләр арасында балалар да күп – барысы 67798 бала, күбесе сабыйлар булган [Кривоножкина, Ханипова: 2011. С. 464]. Болар хакында язылды да, язалар да, үзәккә үткән хәлләр бит.

Авыллар шулай көннән-көн хәсрәткә күмелә бара, яшәү өчен шартлар булмавы бу кайгыларны тагын да тирәнәйтә. Сугыш якларыннан килгән хәбәрләр дә күңелне күтәрерлек түгел. Ә фронт өчен икмәкне чәчәсе, җыясы бар, җыелган ашлыкны җыю пунктына (Коркачык станциясенә) тапшырасы бар. Атларның тазаракларын фронтка алып бетерәләр, калган 14 башны бүреләр харап итеп китәләр. Ашлык илтәр өчен хатын-кызлар үз сыерларын җигәргә мәҗбүр булалар. Тагын елаш, тагын күз яше. Әниләр сыерларын кызганып нишләргә белмиләр иде. Чөнки сыер хуҗалыкта ачтан үлмәс өчен бердән-бер өмет, аны югалтса, балаларны ни белән туйдырырга соң?

Әйтергә кирәк сыерлар да ач бит ул чакта. Колхоз хайваннарга ашатырга 1 ц печән, 1 ц салам бирми иде бит. Шуңа күрә күп кенә сыерлар күтәрәмгә чыгалар, аларны баулар белән «асып» куялар иде.

Коркачык белән бәйле бер вакыйга хәтеремдә.

1944 елның үзәккә үткән салкын буранлы көне. Өчкә-дүрткә бөгелеп чана тарткан хатын-кызлар авылыбыздан 60 чакрым ераклыкта урнашкан шул Коркачык станциясенә ашлык илтәләр. Өсләрендә ямаулы күлмәк, иске бишмәт, кайсылары шәл урнына ашъяулык бөркәнгән, аякларында чабата. Репин картинасындагы бурлаклар кебек җан ачысы белән чана тарталар. Үсә төшкәч белдем: колхоз амбарларында ашлык калдырырга рөхсәт булмаган икән (ач балалардан, тол калган хатыннардан курыккан-

нардыр инде…). «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!» – иде бит. Шулай, орлыкны кыш башында илтәләр, язын күтәреп алып кайтып азап чигәләр иде әниләр.

Ничек чыдадылар икән?! Исән чакларында барысы да хакимияттән олы хөрмәт күреп, җанга рәхәт бер сүз ишетә алдылар микән? Юктыр, барысы да түгелдер. Шулай да, бәлки, исәннәре күреп, ишетеп калгандыр. Аларга бу олы сүзне, олы бәяне русның күренекле язучысы Федор Абрамов Россия язучылар съездында әйтеп калдырды: «Сугыш вакытында икенче фронтны хатын-кызлар ачты» – диде. Бу искиткеч ачык хакыйкать иде. Шуңа да бу сүзләр яңгырагач, зал бер мәлгә тын калды, соңыннан көчле алкышларга күмелде. Ни кызганыч, съезд үткәрелгән ел хәтеремдә калмаган.

Ә минем әнием – Сәфәрова Шәрифә Хәйретдин кызы, сугыш вакытында ишеткән бер рәхмәт сүзен, гомере буе яхшылык белән искә алып елый иде. «Ничәнче ел булды икән, язгы чәчүгә дигән орлыкны Коркачык станциясеннән күтәреп ташыйбыз. Шулай, капчыкларыбызны аллы-артлы күтәреп кайтырга чыктык. Аякта юеш чабата, арып-талып, язгы суга басмаска тырышып атлыйбыз. Шулчак станциягә солдатлар төялгән бер эшелон килеп туктады да, вагоннан берәм-берәм солдатлар сикереп төшә башлады. Без дә туктадык. Күзебез белән якыннарыбызны эзлибез, кайберәүләр «татарлар бармы, кайсы районнар?» – дип сораша ук башлады.

Менә бер өлкәнрәк кеше төште, командирлары булды ахры. Ул бик тиз генә солдатларга тезелергә кушты. Алар тезелгәч, безгә таба борылып җиргә тезләнде дә: «Спасибо», – диде. Бер сүз дә әйтә алмый калдык, солдатлар тиз генә сикерешеп менүгә, поезд кузгалып та китте». Әнинең бу истәлекне сөйләгәндә ни өчен елаганын аңлыйм. Ирләрдән ишетеп ияләнмәгән бу кадерле сүз, олы хөрмәтнең мондый чагылышы аны чиксез дулкынландырган булган, күрәсең.

Тагын бер хәл һич исемнән чыкмый. Әни белән телевизор карап утырабыз. Сугыштан азат ителгән җирләрдә хатын-кызларның, сукага җигелеп, җир сөргәннәрен күрсәтәләр. Әни бәгърем елый башлады...

– Шулай онытылмас микәнни бу газаплар, – диде ул. Үземнең дә Шәмсениса апай белән сука сукалавым һаман исемә төшә. (Сәфәрова Шәмсениса апа әниемнең якын дусты, гел бергә эшләделәр). Бригадир сукага чыгарга кушкач, башта ышанасы да килмәде. «Чи калган җирләрне сукаларсыз, анда ат та, сыер да бата (колхозда атларның юньлесе фронтка алынган, үгезләр дә бер-ике генә баш, сыер җиккән очраклар еш була иде). Җәмил абый (сүз, яше 70 тән артып киткән өлкән кеше хакында) сукагызны тотып йөрер әнә», – дип каршы сүз әйтерлекне калдырмады. Басуга бардык, җигелеп тартабыз суканы. Аяк бата, чабатаны өстерәп чыгарып булмый.

Суык балчыкка ялан аяк басып карыйбыз. Суканы тартырга юк кына бит, җитми генә бит көч. Өчәүләп утырып еладык шул чакта.

И, газиз Аллам... Тормышта үзем күргән газапларны искә алмаска мин риза. Әмма әнинекен оныта алмыйм. Аңа шул газаплары өчен кадер-хөрмәтем аз булгандыр төсле тоела, җаным әрни.

Сугыш барган саен авыл да көннән-көн кайгы-хәсрәткә күмелә барды. Фронттан кайгылы хәбәрләр килә торды. Халыкның ягарга утыны бетте, кисәргә бер агач, бер куак юк. Халык бөтен ягарга яраклы әйберне яга башлады: капка-койма, абзарлар һәм мунчалар ягылды. Авылда бары дүрт мунча калды. Халык утын таба алса, авылның югары очындагы «кара мунча»га чиратлап ягып керә. Мунчаның хуҗасы Лотфулла исемле өлкән кеше, тик нигәдер исемен үзгәртеп «Упла бабай» дип йөртәләр иде. Аны рәхмәт белән искә алган кешеләр әле дә бар.

Авыл халкы актык көченә тырышып эшләсә дә, «хезмәт көне» дигән хактан башка түләү ала алмады, бушка эшләде. Шуңа күрә җырларга кереп калды бу хәлләр:

Чабатаны киябез без,
Булмаганга аякка.
Акча дигәнне күрмәдек,
Без эшләдек таякка.

Әле дә исем китә. Сугышның 26 нчы көнендә икмәк карточка белән бирелә башлаган. Шәһәр халкы шушы карточкалар белән үзенә һәм балаларына тиешле (нормада күрсәтелгән) икмәкне ала алган. Авыл кешеләренә, ягъни шул икмәкне үстерүче хатын-кызларга, икмәк бирелмәде. Ни өчен икән? Кем белә?

Икмәкнең бөтен кешегә дә җитәрлек булмаганын акылым белән аңлыйм. Фашистлар басып алган җирләрдә сөрү җирләренең 47% калган, йөз меңнәрчә колхоз, совхоз, МТСлар җимерелгән. Әмма ач әниләр ничек итеп көнне-төнгә ялгап эшли алдылар икән? Әле, җитмәсә, безне кызганалар, безне сакларга тырышалар иде. Әнинең өзгәләнгәне бүгенгедәй хәтеремдә: «Һай балалар, күкрәгемә терәп ипи кисеп ашаткан көннәрем булыр микән сезгә» – дип елый иде ул. Бер ул гына түгел бит, бөтен авыл белән. Шуңа күрә гомер буе икмәкнең кадерен белеп, олылап яшәде әниләр.

Әнә шулай елый-елый ашлык ташыган, урак белән кырда үскән игеннәрне урып җыйган, төннәрен ындырда ашлык суккан әниләрнең ашарына икмәк юк иде. Барлы-юклы бәрәңгесен булган сыер-сарыгы белән бүлешеп ашаган авыл халкы, язга таба бөтенләй хәлсезләнә иде. Җирләр кырдан арчыла башласа, кеше җиңел сулап куя. Чөнки кырда, көз көне балчыкка күмелеп, күренми калган чергән бәрәңгеләр чыга. Ул бәрәң-

геләрне җыярга олысы-кечесе бара. Җыйган бәрәңгеләрне кайтышлый ук язгы ташу суында юып, кабыгын әрчеп кайталар иде.

Еллар үткәч, безне ачлыктан коткарган черек бәрәңгенең кешеләрдә тамак шеше (септик ангина) авыруына сәбәпче булганын документлардан укып хәйран калдым. Күз алдымнан тилмерә-тилмерә, язгы салкын балчыкка ялан тәпи баса-баса, черек бәрәңге җыйганнарым, бик еш кына тамак шеше белән җәфаланганым килеп басты. Бу авыру белән бигрәк тә безнең Татарстан һәм Казахстан халкы җәфа чиккән. 1944 елның июнь аенда алынган мәгълүматларга караганда, Татарстанда тамак шеше белән авыручылар саны 20 меңнән арткан. 6 меңнән артык кеше үлгән. Бу хәлләр хакында Татарстан эчке эшләр халык комиссары Горбулин үзенең Лаврентий Бериягә җибәргән телеграммасында болай дип күрсәткән: «Сезгә 1944 елның 23 июнендә җибәргән мәгълүматларга өстәп шуны әйтәм: 1944 елның 20 июнендә Татарстан тамак шеше белән авыручылар саны 23470, үлүчеләрнеке 6097 исәпләнә» [Новое время. 1907. №7. С. 41]. Бу мәгълүматлар бары бер ел өчен генә бит әле.

Татарстанда врачлар бу авыруга каршы «гадәттән тыш өчлекләр, бригадалар» төзеп көрәшеп караганнар каравын да, тик бу авыруны китереп чыгарган төп сәбәпне – ачлыкны алар ничек бетерсен соң?

Черек бәрәңгене бездә «күкәли» дип атыйлар иде. Белмим, кайдан бу атама килеп чыккандыр. Ач кешеләр рәхмәт әйтеп җыр чыгарганнар, аны барыбыз да җырлап йөри идек:

Күкәлидән хат килгән,
Язга кайтырмын дигән.
Колхозчыларга әйтегез,
Ачка үтермәм дигән.

Еллар үткәч, Казан педагогика институтында укыганда, Оренбург өлкәсе, Абдуллино районы Шалты авылыннан килгән бер группадашыма черек бәрәңге ашаганыбызны сөйләгәч, ул миңа кырт кисеп: «Юкны сөйләмә, кеше ничек черек бәрәңге ашасын, аз булса да ипи бар иде бит» – диде. Димәк, Оренбург өлкәсендә ашарга ипи булган, ә бездә, Татарстанда юк иде ипи, юк иде. Уйланырлык нәрсә бар монда! Күрше рус авылы Атамышта да булган бит ипи. Алар басуларыннан безнең кебек черек бәрәңге җыймады. Монысы хакыйкать! Без нәрсәләр белән туклана идек соң? Җәй башында елга буйларында кузгалак чыга. Ат кузгалагын олылар ашка турап салырга җыялар, кычыткан да шуңа китә. Песи борчагы, кәҗә сакалы, какы, чыпчык кузгалагы, балтырган – гомумән ашарга яраклы үләннәр инде.

Урак өсте җиткәч, бала-чагалар кырга, әниләренең урак урган басуларына «арыш башы уып ашарга», – дип баралар. Әмма бу хәлне колхоз

җитәкчеләре, каравылчылар күрсә, котылып калу юк, йә балаларны бик каты куркытып котларын алалар, йә, әниләрен җавапка тарталар. Хәтта төрмәгә утырткан очраклар була иде. Авылыбызда биш балалы Галимулла абыйның иң чибәр кызы Разия апаны – әле 15 нче яшенә генә чыккан үсмерне, 100 гр. ашлык өчен 2 елга төрмәгә утыркач, бөтен авыл тирән хәсрәткә батты. Аллага шөкер, ел ярымнан соң кыз бала исән-сау кайта алды. Бөтен авыл сөенде шуңа.

Шушы итәк тулы бала, карт-корыларны да тәрбияләүне үз өстенә салган хатын-кызлар авыр хезмәт өстәвенә икмәксез калды. Ипи, пешерергә түгел, ашка умач итеп салырга да он юк иде. Ә һәр колхозчы елына 300 литр сөт, 100 йомырка, 36 пот бәрәңге, 40 кг ит, сарык йоны (үлчәвен хәтерләмим) түләргә тиеш иде. Түли алмаса, өстәмә түләү салалар, булган әйбереӊ (урын-җирне) алып чыгалар.

Ничек чыдадылар алар безнең әниләр, ничек эшләделәр?! Газеталарга мөрәҗәгать итәм:

Менә «Социализм юлы» газетасының 1941 ел 6 июль саны: «Ворошилов» һәм «Таң нуры» колхозы членнары Германия фашистларына җавап итеп 3 нче бишьеллык Дәүләт заемына биргән подпискалары буенча акчасын да түләп бетерделәр» [Социализм юлы. 6 июль 1941 ел].

Сүз Иске һәм Яңа Шимбер авылы кешеләре хакында бара. Уйлап карасак, әле июль башы гына. Авыл халкы көн саен кан-яшь түгеп иң якыннарын сугышка озата. Заем түләү кирәклеге башларыннан чыкмагандыр. Чыгарга ирек бирмәгәннәрдер. Ничек итеп «түләп тә бетергәннәрен» укучыларым уйласын инде.

Олуг язучы, галим М. Мәһдиевнең бер фикере хаклы булуы белән исемнән чыкмый: «Безнең илдә журналистлар кадәр ялганчы, алдакчы кеше юктыр» – дип язган иде ул [Мәһдиев: 1993. Б. 126]. Бу бәя мәңгелек булып калды төсле.

Менә «Социализм юлы»ның 1941 елгы 2 октябрь саны. ««Таң нуры» колхозчылары Кызыл Армия сугышчыларына җылы киемнәр хәзерләү турындагы чакыруны аерым бер җылылык хисе белән кабул итте. Колхоз гомуми фондтан 30 пар бияләй һәм оекбаш бирде. Шәрәфиев Низами бер телогрейка бүләк итте. Ә 10 колхозчы берәр тире тапшырдылар» [Социализм юлы. 2 октябрь 1941 ел]. Р. Хәбибуллин мәкаләсе.

Тагын бер хәбәр, монысы 1942 елның кышы: «Таң нуры колхозы дәүләткә 150 ц, Тельман ис. колхоз 250 ц., Каганович ис. колхоз 150 ц. ашлык саттылар» [Социализм юлы. 16 январь 1942 ел].

Аллага шөкер, авылыбыз кешеләренең эшкә уңган, булган, батыр икәнлекләрен күреп үстек. Үз авылыбыз (колхозыбыз) эшләрен генә түгел күрше Түбән Көек, Атамыш колхозларының эшләренә дә булышалар

иде алар. Моны раслау өчен документлар кирәктер дип уйламыйм. Әле өлкәннәр, шөкер, исән. Кызыксынучыларга сөйләүчеләр табылыр.

Әниләр иртән эшкә киткәндә өй, ишек алларын, лапас артларын җыештырып, себереп, чүбен җыйнап китә иде. «Имеш бала-чага чүпкә ут төртеп авылны яндыру куркынычы бар». Бу дөрес чара булгандыр, гаепләрлек урын юк, тик шырпыны кайдан алырга мөмкин булды икән?

Әнием Сәфәрова Шәрифә (чын исеме Шәфифәне үзгәртеп сөйләшәләр иде), югарыда искә алынган Сәфәрова Шәмсениса белән гел бергә эшләделәр. Кайда гына эшләсәләр дә (ферма, амбар алды, сушилка, ындырда ат урынына салам ташу һ.б.), гел мактала иделәр. «Трактор» кушаматы да икесенә дә бирелгән иде. Менә алар хакында газетада укып та сөендем дә, кызгандым да. «"Таң нуры" колхозының терлекчелек фермасында эш үрнәк булырлык итеп куелган. Фермада чисталык һәм пөхтәлек. Терлекләр барысы да көрләр, тазалар һәм чисталар. Кормаларны әрәмшәрәм итмәү өчен көрәшеп, үлчәп, саламны турап һәм парлап ашаталар.

Ферма работниклары арасында дисциплина нык. (Болар Сәфәрова Шәмсениса, Сәфәрова Шәрифә, Фәтхуллина Гөлсем, ветсанитар Фәйзи иптәшләр). Ферма мөдире иптәш Гөбәйдуллина Җәмилә үзе дә һәрвакыт фермада, эшчеләр арасында була» [Социализм юлы. 21 апрель 1944 ел].

Бу мәкалә әниләрнең сыерлар өчен чиләк-көянтә белән су ташыганнарын, бау белән бәйләп күтәреп печән-салам керткәннәрен, сыерларның тиресләрен арба яки чанага төяп басуга чыгарганнарын, иртән сәгать бишенче яртыга килеп, кичке 9 тулгач кына өйгә кайтканнарын санап тормаган. Болар өстәвенә әле салкын ферма өендә чиратлап дежур торасы да бар иде бит. Һаман булып торган җыелышлар да үзәкләренә үткән нәрсә иде.

Шулай да район гәзитендә макталганнарын укып, күңелем тулды. Рәхмәт, күрә, яза белгәннәренә.

Мин әнинең фермада эшләгән чагын бик яхшы хәтерлим. Сыер савучы әниләр сөтне Кимедәге май заводына (8 км ераклыкка), кул арбасына 2 шәр бидон куеп, тартып илтәләр иде. Бидонга 30 л сөт сыйганын исәпкә алсак, 60 л сөтне (әчетергә ярамый, тизрәк илтергә кирәк). Көн саен бару кайтуга шулай 16 км йөреп тапшыралар иде. Күрше Фәхерниса апайга мин көн саен ике-өч чи бәрәңге алып керәм дә: «Фәхерниса апай, менә 2 бәрәңге, ярсаң 4 була. Үзегезгә пешергәндә миңа да пешереп бир әле» – дип сорыйм. Сорамасам да, пешерә, күрше апаны, әни үтенә бит инде. Миңа 3 яшь тулган булган икән газетадан мәкаләне укыгач исемә төште.

Тагын шунысы да булган бит: сугышта үлгәннәргә пенсия бер төрле, хәбәрсез югалганнарга икенче төрле түләнгән, күп кенә җирләрдә бер тиен дә түләнмәгән. Моны безнең авылда күп кешеләр әйтә иде. Мисал

өчен шул ук искә алынган Сәләхиева Әлфия әтисе хәбәрсез югалганга бер тиен дә пенсия алмаганын хәзер дә әйтеп тора.

Авылыбыз кешеләренең олы йөрәкле булулары, ике бәрәңгесе булса шуны бүлешеп ашаулары хакында мисалларны күп язарга була. Ул вакытта хәер эстәүчеләр күп йөри иде, булган ризыгын алардан да кызганмады халык. Хәзерге байларның ничек итеп ярлы халык хакында «нищеброд» дип кенә җибәргәннәрен язасым килми. Әмма авылда әниләрнең безнең авылыбызга килеп егылган кырым татары кызы Малимә (Мәллимә дип тә әйтәләр иде) язмышына битараф булмауларын искә алыйк әле. Рухы шатлансын, бакыйлыкка күчкәндер инде ул. Аның хакында «Хәтерләүче Мари урманнары гына түгел» дигән мәкалә язган идем. Кызыксынып укыганнар кырым татарлары хакында да белгәннәрен яңартырлар – дип ышаныйк. Укыгыз:

Хәтерләүчеләр мари урманнары гына түгел...

Гаҗәп хәл. Еллар үткән саен хәтер савыты саега икән. Әмма балачакта һәм яшьлектә булып узган вакыйгалар кеше күңелендә мәңге онытылмый, «сүнми дә, сүрелми дә» икән.

2013 елда IX Казан халыкара мөселман киносы фестивале кысаларында «Родина» кинотеатрында күрсәтелгән «Хайтарма» фильмын карагач, күңелемдә кырым татарларының олы фаҗигасенә кагылышлы истәлекләрем яңарды.

1944 елның көзе. Октябрь айлары булса кирәк, олылар бәрәңге алган вакыт (сугыш елларында бәрәңгене кырда ураклар беткәч кенә алалар иде). Миңа 4 яшь (1940 елның октябрендә туганмын), апама – 7. Өйдә көндезге чәйне эчеп утырабыз. Шул вакытта безгә ике яшүсмер һәм минем яшьләрдәге бер кыз бала килеп керде. Бу баланың өстендә юка гына күлмәк, башында да, аякларында да киеме юк иде кебек. Ул бик туңган, үзе нечкә, ябык, бик кызганыч хәлдә иде. Яшүсмерләр үзләренең татар икәнлеген әйтте. Әни аларның кырым татарлары булуын аңлады, ахры, кабатлап соравы хәтеремдә калган. Ә мин теге кыз баладан күземне ала алмыйм, ул үзе әкрен генә дерелди, күзләре тәлинкәдә калган бәрәңгеләрдә иде мескенкәемнең.

Хәзер ышанып та булмас, әмма минем бәләкәй йөрәгем аны кызганудан әллә нишләде. Мин елый башладым. Әнидән минем өстемдәге кофтаны шул кызга бирүен үтендем. Бу хәлне мин хәзер дә аңлатып бетерә алмыйм: мин ничек ул баланың фаҗигасен аңлый алдым икән?! Бәлки, акыл керә башлавы булгандыр, дип тә уйлыйм. Әнигә рәхмәт, ул минем өстемдәге шул кофтаны салдырды да кызчыкка киертте. Калган бәрәңгеләрне дә аларга ашатты. Өйдә ипи юк та юк инде, бар ризыгыбыз шул бәрәңге дә, сөт. Әни аларның барысына да сөт эчерде.

Менә ничә еллар үтте, ә күз алдымда минем өстән төшкән, юка гына кара җептән бәйләгән кофтаны киеп, елмаерга тырышкан шул 4–5 яшьлек кыз бала басып тора.

Әйтеп үтим, сугыш вакытында да, сугыш туктагач та авыл бик ярлы яшәде. Өстебезгә кияргә кием булмады. Ивановода яшәүче туганыбыз, безне кызганып, кайчак үз балаларыннан калган киемнәрне җибәргәли иде. Кофта да шулай насыйп булган иде миңа. Өстемә кияргә бүтән җылы киемем булмаса да, ничектер яхшылык эшләгәнемне аңлапмы, мин бик канәгать идем. Тик исән кала алды микән ул бала?

Тагын бер вакыйга исемдә. Әниләр амбар алдында сушилкада эшли. Без балалар, алар янына барабыз, каравылчы кумаса, нәрсә эләксә, шуны ашап, чемченеп йөрибез.

Шулай бер көнне амбар алдындагы чирәмгә бер кыз бала килеп егылды. Янына әниләр йөгереп барды. Ничә яшьләр булды икән аңа, бер 13–14 тирәсе микән? Бүгенгедәй хәтерлим, башыннан аягына кадәр соры, канатлы бетләр сарган иде аны. Сүзен әйтерлек хәле булмагандыр, ул бик кызганыч итеп ыңгыраша гына иде. Әни тиз генә өйгә кайтып, сөт, киярдәй бер күлмәк алып килде. Олылар безне «Бете иярә», дип куып торды. Кызның авызын ачып сөт йоттыра башладылар. Сарык йоны ала торган кайчы белән озын чәчләрен кыркып алдылар. Өстендәге сәләмәсен кисеп ташлап, әни алып килгән күлмәкне кидерделәр.

Күзен ачкач, аның кырым татар кызы икәнен белделәр. Исемен әллә үзе әйттеме, Мәллимә дип йөрделәр. Соңрак ул Галия апаларда яшәде, бергәләп чыпта сукты, авыл кешеләренә ияләште. Туганнарын эзләде микән, белмим. Әмма шулкадәр ачык йөзле, һәр сүзгә ышанучан, барысын да үз итә торган кыз иде ул. Әнә шул ышанучан булгангадыр, еллар үткәч, кияүгә чыкмыйча гына бер кыз бала да тапты. Бәлки, бәхетенә булгандыр.

Берничә елдан Мәллимә хәзерге Биектау (элекке Дөбъяз) районы, Өлә авылына күчеп тора башлаган. Шулай бер елны безгә 12–13 яшьләр чамасы булгандыр, Сабан туена барганда аның өен эзләп табып, хәл белергә кердек. Әйткәнемчә, бик якын итә, үз күрә иде ул безне.

Өенә кергәч, андагы чисталыкка, матурлыкка исебез китте. Өй эче бәйләгән челтәрләр, чиккән япмалар белән тулы. Киң күңелле Өлә кешеләре сәдака итеп китергәндер, дип уйлыйм ул әйберләрнең күбесен. Мәллимә үзе дә кул эшләренә – чигү, бәйләүләргә бик оста иде. Ул безне ничек кунак итәргә, кайларга ничек итеп утыртырга белми. Үзе шундый шат, әйтерсең лә көтеп алган кунаклары килгән. Янында чиста, пөхтә, чәчләре матур итеп үрелгән кызы, безгә елмаеп тора.

Йә, Аллам, рәхмәт бу Өлә авылы кешеләренә. Алар ярдәм итмәсә, өйле, тормышлы булып яши алмас иде бу кырым татары кызы.

Хәзер шуны уйлыйм: эзләмәде микән, тапмады микән үз туганнарын Мәллимә? Үзе исән түгелдер инде, баласының язмышы ничек булды икән? Өләдә гәзит укучылар булса, язып җибәрсеннәр иде белгәннәрен. Ничек кенә булмасын, халыкларыбызның уртак фаҗигасе дә, үзара ярдәмләшүе хакында да сөйли әлеге фактлар.

Еллар үткәч, педагогика институтында укыганда, бу хакта укытучыбыз Мәдинә апа Җәләлиевага сөйләгән идем. Аның да кырым татарлары язмышы белән бәйле истәлекләре бар булып чыкты. Ул болай дип сөйләде: «Студент еллары сугыш вакытына туры килде. Без күргән җәфаларны сөйләсәң – тел, язсаң – кәгазь чыдамас. Югары уку йортларында укучы кызларны урман кисәргә җибәрәләр иде. Мари урманында мин дә урман кистем. Башта агачларны кисәбез дә, 2–2,5 метрлы итеп турыйбыз. Шуннан соң тачкаларга салып, елга буена чыгарабыз. Өс-баш начар, үзегез беләсез, ашарга җитми. Әле дә хәтеремдә: октябрь-ноябрь айлары, коточкыч салкын. Без чыгарган агачларны, бозлы суга яртылаш кереп, кырым татар кызлары салга төйи, туңса да, чыгып йөгерә алмый, ярда милиционерлар тора. Йә Алла, ул кызларның исән калганнары булды микән? Мари урманнарының теле булса, бу хәлләрне гомер буе буыннардан-буыннарга сөйләр иде».

Ни кызганыч, Совет хакимияте елларында кырым татарларына карата алып барылган мәкерле һәм аяусыз сәясәтне белдермәскә тырыштылар. Фильмны фестиваль конкурсына кертмәүләрен дә башлыча шуның белән аңлатырга кирәктер. Ил тарихында кырым татарлары дигән милләт искә алынмый иде диярлек, аның кайда һәм ничек көн күрүе хакында бик иркенләп, ачыктан-ачык сөйләшү дә булмады. 1944 елда Кырым татар автономияле республикасы халкының – татарларның ике сәгать эчендә эшелоннарга төялеп, Урта Азиянең комлы далаларына, Ерак Себергә һәм Мари урманнарына илтеп ташлануын, юлда барганда меңнәрчә балаларның, хатын-кызларның, картларның (корал тота алган ирләр фронтта, гитлерчыларга каршы сугышта) ачлыктан, авырулардан кырылганын бик күпләр белмәде. Кайчандыр Кырым ярымутравында татарларның олы һәм бөек дәүләте булганы да искә алынмады.

Аллага шөкер, тарихта кайчак дөреслек тә, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр дә калкып чыга. Кырым татар халкы белән дә шулай булды.

Шунысы күңелгә җылылык бирә, бер минем әнием генә якты йөз күрсәтмәгән, ярдәм итмәгән икән кырым ятимнәренә. Үзбәк халкы арасында да аларның хәленә керүчеләр, исән-сау барып җитә алганнары белән соңгы ризыкларын бүлешүчеләр булганын да беләбез бит хәзер. Шулай, яхшылык җирдә ятмас ди халык мәкале.

Хәтер, хәтер... Яхшылыкны да, яманлыкны да онытмый. Кыз балаларның тилмерүләре дә Мари урманнары хәтерендә генә калмас әле. Киләчәк буыннар да уйларга өйрәнерләр, онытмаслар, туганлык, дуслык мөнәсәбәтләрен саклауны да үз кулларына ала белерләр дип өметләнәсе килә.

Безнең – сугыш чоры балаларының язмышы күбебез өчен уртак: артык иркәләнергә дә, матур уенчыклар белән уйнарга да туры килмәде безгә. Курчакларны да үзебез, нәрсә туры килсә шулардан ясый идек. Булмаганны таптыру да башыбызга да килмәгән. Тол калган әниләрнең бөтен хәсрәте, бөтен михнәтләре безнең күз алдында иде бит. Күбесе ертык киемнән, күбесе шәл урынына ашъяулык бәйләгән, тишек чабаталы апалар, әниләр... Әмма балалар ятимлекне сизмәсен, ачлыктан тилмермәсен өчен хәленнән килмәгәнне эшләргә тырышкан изге җаннар иде алар.

Ф.Н. Шакуров

О ВРЕМЕНИ ОСНОВАНИЯ СЕЛЕНИЯ АБДРАХМАНОВО АЛЬМЕТЬЕВСКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

При определении времени основания населённых пунктов принято ссылаться на официальные источники в архивах, прежде всего материалы ревизий, переписей населения. Даты основания татарских сёл юго-восточных районов республики обычно относят к концу 40-х гг. XVIII в., когда они впервые были зарегистрированы во время Второй ревизии. Такой подход, оправдываемый установленными правилами, не только сомнителен с точки зрения его научности, но оставляет место представлениям, в корне искажающим этническую историю татар, в том числе и различным политическим инсинуациям. В частности, получается, что татарского населения как бы не существовало лишь в силу того, что центральная власть в определенный период не имела возможности его зафиксировать, а значительная же его часть якобы появилась здесь как передовой отряд русской колонизации. Кроме того, игнорируются общеизвестные факты, например, учёт Второй ревизией не всех сословий. Между тем, сами царские чиновники, зная неполноту материалов ревизских сказок, время расселения сословия тептярей, одного из основных в данном регионе, определяли при отсутствии документов со слов жителей [Давлетбаев: 1986. С. 83–158].

Нам представляется, что при исследовании расселения татар в этих районах, во-первых, следует привлекать широкий круг русских источников, не ограничиваясь переписями. Во-вторых, обращаться к татарским источникам: родословным, народным историко-краеведческим сочинениям, текстам надгробий, устным преданиям. В-третьих, исходить из того, что местное татарское население является не только потомками переселенцев с основных территорий Казанского ханства, бежавших от насильственной христианизации и усиления экономического гнёта, но и автохтонных тюрко-татар Ногайской Орды [Исхаков: 2003]. Это подтверждается и сведениями родословных Азнакаевского региона [Әхмәтҗанов: 2001. Б. 21–29]. Указанные этнические составляющие не могут быть противопоставлены, поскольку на протяжении веков являлись частями единого политического, этнического и цивилизационного поля.

Представленные положения были использованы нами при определении времени основания села Абдрахманово Альметьевского района Республики Татарстан. Первый официальный документ, содержащий информацию об этом селении – «Ландкарта Оренбургской губернии с показанием частей протчих губерний» (1746 г.) [3: Д. 358]. Наиболее ранние

сведения о населении Абдрахманово отложились в материалах Второй ревизии, проходившей в данном регионе в 1746–1748 гг., где указаны 52 души мужского пола тептярей и ясачных татар [1: Д. 3793, Л. 19–20; Д. 2450, Л. 249–250]. Причем сословие башкир, к которому принадлежала в конце XVIII в. пятая часть его жителей, тогда еще не учитывалось. Это достаточно крупный для своего времени населённый пункт, и очевидно, он был основан заметно раньше второй ревизии, но источники с более точными датами его основания остаются неизвестными.

Кроме того, при изучении ранней истории с. Абдрахманово и ряда других населённых пунктов юго-востока Татарстана, необходимо учитывать одно немаловажное обстоятельство. Известно, что земли по рекам Зай, Шешма, Сок были пожалованы в тарханное владение казанскими ханами Мухаммед-Эмином и Сафа-Гиреем некоему Асылхузе и его сыновьям Хасану и Хусаину, по всей видимости, являвшихся лидерами проживавшего там клана. Между тем этот факт указывает на весьма значимые реалии того времени: приграничные территории Казанского ханства и Ногайской Орды находились во власти лиц, одновременно являвшихся представителями элиты Мангытского юрта и ярлычными «князьями» казанских ханов, что было выгодно каждой из сторон. Под натиском опустошительных калмыцких набегов первой трети XVII в. значительная часть населения покинула этот регион. Потомки тарханов, обосновавшиеся в Казанском уезде, помнили свою принадлежность к феодальной знати и считали себя владельцами этой территории. Некоторые из них участвовали в административном управлении, будучи назначенными российской властью на должности старшин [Исхаков: 1999]. Один из представителей этого рода – Надир Уразметов (1687–1758), организовал в первой трети XVIII в. переселение на земли между Заем и Шешмой, впоследствии названные Надыровой волостью, где он стал старшиной. В стремлении закрепить старые вотчинные земли он опирался на родственников, возвращавшихся на земли, принадлежавшие предкам, и новые населённые пункты основывались им самим и/или его сородичами [Амирханов, Габдуллин: 2003. С. 288–289].

Основатель с. Абдрахманово Абдрахман Бикметев также являлся родственником Н. Уразметова – двоюродным братом его отца – и потомком тарханов, что подтверждается как архивными данными [2: Д. 5959. Л. 453], так и родословной Н. Уразметова [Фәхретдин: 1914. Т.Б. 2]. Он приходится мне пятым прадедом. Родословная нашей семьи начинается с Бикмухаммета (Бикмет), совпадая с соответствующими сведениями, имевшимися в распоряжении Ризы Фахрутдинова (Бикмухаммет – Габдрахман – Ибрагим), и продолжается по линии одного из

сыновей Ибрагима. Она подтверждается генеалогическим исследованием краеведа Р. Амирханова, основанном на материалах переписей и метрик [Әхмәтҗанов: 2014. Б. 177–185]. Переселение многочисленного рода завершается в целом к 1729 г. [2: Д. 5959. Л. 437 об.]. Совокупность исторических обстоятельств и свидетельств позволяет принять 1729 г. как условную дату основания с. Абдрахманово, которая может быть уточнена с выявлением новых источников.

Автор благодарит известного археографа и краеведа Раифа Марданова за предоставленные материалы картографических источников XVIII в. и сведений Российского государственного архива древних актов.

Источники

1. Российский государственный архив древних актов (РГАДА) – Ф. 350, Оп. 2.
2. РГАДА – Ф. 248, Оп. 67.
3. Российский государственный военно-исторический архив – Ф. 416, Оп. 1.

Исследования

1. Амирханов Р., Габдуллин И. Надыр Уразметов // Әлмәт = Альметьевск. – Казань, 2003. С. 288–296.
2. Давлетбаев Б.С. Тептяри и их землепользование // Малоизученные источники по истории Башкирии. – Уфа, 1986. С. 78–158.
3. Исхаков Д.М. Из истории села Старое Ермаково Клявлинского района Самарской области // Из истории Альметьевского региона. – Альметьевск, 1999. С. 323.
4. Исхаков Д.М. Юго-Восток Татарстана: проблема изучения этнической истории региона XIV–XVII вв. // Әлмәт = Альметьевск, 2003. С. 67–77.
5. Әхмәтҗанов М.И. Меңъеллык татар нәселе. – Казан: Мәгариф, 2001. – 47 б.
6. Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре. Т. 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.
7. 10. Фәхретдин Р. Надир хакында // Шура. – 1914. – № 5. – 2 т.б.

МИРАСЫБЫЗНЫҢ ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАГЫЛЫШЛЫСЫ

НАШЕ ИСТОРИКО-КРАЕВЕДЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ

От редакции

Редакция сочла необходимым опубликовать этот труд известного историка, настоящего русского ученого, Михаила Георгиевича Худякова, написавшего несколько важных трудов по истории татарского и др. народов Поволжья (очерки по истории Казанского ханства, 1923; Мусульманская культура в Среднем Поволжье, 1922; Падение Казанского ханства (1551–1556), 2003 (издание наследия); Культово-космические представления в Прикамье в эпоху разложения родового общества, 1934; История Камско-Вятского края: Избранные труды, 2008 (издание наследия)). Жизнь этого крупного исследователя, родившегося в г. Малмыж Вятской губернии 3 сентября 1894 г., трагически оборвалась в годы сталинских репрессий 19 декабря 1936 г. в Ленинграде. Истинный интернационалист М.Г. Худяков, прекрасно разбиравшийся в истории и культуре народов Поволжья и Приуралья, последовательно выступал против шовинизма. За это он и был, как думается, репрессирован. В наше нелегкое время, когда некоторые призраки прошлого возвращаются, нашим читателям-краеведам будет полезно ознакомиться с этим историческим наследием русского историка. При этом напоминаем, что в следующем году исполнится 90 лет со дня его трагической гибели. Пусть эта его работа напомнит нам всем об истиннорусских интернационалистах…

М.Г. Худяков

ВЕЛИКОДЕРЖАВНЫЙ ШОВИНИЗМ В РУССКОЙ ЭТНОГРАФИИ[1]

I. ДОРЕВОЛЮЦИОННЫЙ ЛЕНИНГРАД

Шовинизм и его разновидности. История шовинизма в России. Идеологические группировки русской буржуазной интеллигенции. Особенности ленинградских научных организаций. РГО В.И. Ламанский. Русский музей. Члены РГО – Д.К. Зеленин, В.П. Семенов-Тян-Шанский (редактор

[1] Система ссылок оставлена по прежнему тексту.

девриеновского издания «Россия»). *Идеи Ламанского во время империалистической войны. Подготовка буржуазии к территориальным захватам «сопредельных стран». Возникновение КИПС.*

Великодержавный шовинизм является неотъемлемой частью идеологии крупной буржуазии и находится в тесной связи с теми концепциями капиталистического общества, которые вылились в форму расовой теории, теории переселений, теории культурных заимствований и т.п., которые чужды и враждебны методологии диалектического материализма, как методологии революционного пролетариата. Будучи близким к «зоологическому» чувству звериной, бессознательной ненависти ко всему чужому, шовинизм в капиталистическом обществе представляет собою особенную форму национализма, характеризующуюся высокомерно-презрительным отношением к другим народностям и аггрессивным стремлением данной «великой нации» или «великой державы» к территориальным захватам и поглощению соседних народов. В капиталистическом мире наблюдаются различные степени и оттенки шовинизма, причем можно различить два главных направления, которые в одинаковой степени основаны на зверином чувстве хищного собственника. Одно направление – более примитивное, более цельное, не различающее ни внешних, ни внутренних «врагов», связанное с известной узостью взглядов и ограниченностью горизонта; это направление характерно для помещичьих групп в капиталистическом обществе. Другое направление – более тонкое, устремленное преимущественно в сторону внешних «врагов» и сравнительно спокойное по отношению к народам, живущим внутри данной «великой державы»; это направление типично для крупной торгово-промышленной буржуазии. Оба направления получили отражение в истории русской общественной мысли, и оба нашли место в скромных и строгих по внешности научных произведениях буржуазных ученых, в том числе и этнографов, В настоящей работе мы не останавливаемся на шовинистической окраске общего направления буржуазной идеологии, выразившейся в расовой теории и т.п., и ограничиваемся лишь конкретными высказываниями, непосредственно направленными по адресу определенных народностей. Даже и в этом виде материал, подлежащий нашему рассмотрению, является чрезвычайно обширным. Ограничиваясь освещением главных общественных и научных течений, мы намечаем лишь основные моменты их тактики на фоне общественной жизни страны. Для того чтобы показать эти группировки и их направления, мы пользуемся почти исключительно ленинградскими и казанскими материалами. Этими материалами раскрывается деятельность двух крупных центров дореволюционной научно-общественной жизни – главный центр

научных организаций, непосредственно связанный с царским правительством, и провинциальный центр миссионерской работы, составлявший своеобразную часть буржуазной системы. Нами не использованы материалы московские, которые могут быть лучше всего освещены московскими этнографами, не использованы также и некоторые ленинградские материалы, так как охватить их в одной статье невозможно. Однако главные, наиболее существенные моменты в истории основных научно-общественных группировок в настоящей работе получают свое освещение.

Исторически шовинизм сложился в поздний период эпохи феодализма, но эта форма шовинизма, проявляющаяся вполне отчетливо и последовательно, еще не имела той полноты и всесторонности, которая характеризует форму шовинизма, складывающуюся в эпоху промышленного капитализма. Буржуазия последнего времени, располагавшая сложным бюрократическим аппаратом, имевшая в своем распоряжении печать и другие средства массовой пропаганды, превратила шовинизм в систему, охватывавшую все стороны жизни и опутывавшую население страны стальной паутиной. Великодержавный шовинизм, как идеология промышленного капитализма, оформился в третьей четверти XIX столетия. В Англии это течение было связано с Биконсфильдом и получило название «джингоизм», во Франции шовинизм определился в эпоху Второй империи в качестве воинствующего патриотизма. Германия Бисмарка и Вильгельма II и Россия Александра III – типичные страны, где шовинизм был официальной программой правительства.

В истории русской общественной мысли теория «третьего Рима», политическая программа, заключавшаяся в титуле московского государя – «государь всея Руси» и затем «царь» – первые шаги шовинистической идеологии. В середине XVI в., когда торговый капитал овладел верховною властью в Москве, шовинизм стал проводиться в жизнь решительными шагами и получил яркое отражение в литературных произведениях. Самым выдающимся практиком и крупнейшим идеологом этого направления был митрополит Макарий – глава русской церкви, регент государства в годы юности Ивана Грозного и фактический глава правительства в течение 20 лет (1542–1563). Правительство Макария предприняло завоевание Поволжья и старалось придать этим захватным войнам характер крестовых походов против мусульман. Макарий составил грандиозный план обращения всего населения Поволжья в христианство и приступил к его осуществлению, но потерпел неудачу, и грандиозный замысел провалился. Ярко-шовинистическое содержание имели публицистические произведения самого Макария (послания, поучения, речи), а также созданные в его кругу исторические труды (летописные своды и

анонимная «История о Казанском царстве», насквозь пропитанная шовинистической идеологией). Дальнейшие шаги в развитии шовинизма относятся к началу XVII столетия – публицистические произведения эпохи «Смутного времени» наполнены шовинистическими выпадами против поляков. В середине XVII в. появляется антиукраинский шовинизм. В течение четырех столетий, до самой Октябрьской революции, шовинизм был официальной платформой русского правительства. Незначительные отступления от этой платформы в сторону уступок национальной буржуазии захваченных территорий, сделанные при Екатерине II и Александре II, обусловливались необходимостью и делались неохотно.

В течение последнего столетия императорской власти в России шовинизм неизменно развивался, и влияние его неуклонно росло. В первой четверти XIX в. ярким выразителем шовинистической идеологии был: Карамзин, чрезвычайно содействовавший своей «Историей» пропаганде этого направления. Во второй четверти XIX в. оформилась шовинистическая группировка – славянофилы, и их лозунг «православие, самодержавие, народность» еще больше способствовал пропаганде шовинистической программы правительства. В третьей четверти XIX столетия обострились гонения внутри империи против поляков, украинцев, возникла новая миссионерская система, способствовавшая русификации национальностей, в сфере внешней политики одержало верх славянофильское, шовинистическое течение. Четверть века, 1880–1904 гг., является высшей фазой в развитии русского великодержавного шовинизма. Весь национальный вопрос в эти годы решался правительством в шовинистическом направлении, которое проводилось с последовательностью и беспощадностью полицейской машины. Административные учреждения, школа, церковь и печать служили главными рычагами этой машины. Практическое применение великодержавного шовинизма не оставляло в стороне от воздействия ни одной стороны общественной жизни. Революция 1905 г. нанесла первый удар проявлению шовинизма внутри государства; некоторые позиции шовинистов были подорваны (указ о веротерпимости 17 апреля 1905 г.), но после подавления революции реакционно-консервативные круги немедленно возобновили свою шовинистическую работу. В условиях обостренных классовых противоречий шовинизм последнего десятилетия царской власти в России имел особенно ожесточенный характер, отразившийся в деятельности таких организаций, как «Союз русского народа», «Русское национальное собрание», и черносотенные группировки «истинно-русских людей».

В капиталистической России деятельность этнографических учреждений и организаций обслуживала интересы правящих классов и яв-

лялась одним из вспомогательных средств для укрепления авторитета власти русских помещиков и капиталистов в глазах трудящихся масс населения. Государственная власть оказывала покровительство и отпускала из казны средства на содержание некоторых этнографических учреждений и на субсидирование этнографических организаций. Это обслуживание научными работниками царского правительства капиталистической России было запечатлено названиями самих учреждений и организаций: Музей антропологии и этнографии имени императора Петра Великого, Русский музей императора Александра III, Императорское русское географическое общество, Императорское общество любителей естествознания, антропологии и этнографии. Во главе научных учреждений стояли члены царской «фамилии»: президентом Академии наук был вел. кн. Константин Константинович, управляющим Русского музея – вел. кн. Георгий Михайлович, председателем Русского географического общества – вел. кн. Николай Михайлович, Русского археологического общества – вел. кн. Константин Константинович и т.д. «Императорские» научные общества были, в сущности, полуказенными организациями, получали правительственные субсидии и работали в полном контакте и в одном направлении с государственными учреждениями. Руководящий слой научных организаций состоял из людей, занимавших видное место среди высших чинов государственной службы. Вице-председатель РГО – П.П. Семенов-Тян-Шанский был сенатором, членом государственного совета и действительным тайным советником, председатель Этнографического отделения РГО акад. В.И. Ламанский имел чин тайного советника, директор МАЭ академик В.В. Радлов имел чин действительного тайного советника и т.д. Часть известных этнографов принадлежала к числу дворян-помещиков, пережиточно сохранявших феодальную идеологию, которая характеризовалась реакционными установками. Вокруг крупных сановников, непосредственно связанных с царским режимом, и вокруг крупных землевладельцев-помещиков, составлявших консервативный лагерь, группировался целый ряд чиновников государственной службы, тысячами нитей связанных также с господствовавшими классами и заинтересованных в неизменном существовании бюрократического режима. Сюда принадлежали, напр., такие этнографы, как Н.А. Бобровников – бывш. попечитель Оренбургского учебного округа, затем член совета министерства народного просвещения В.А. Мошков – артиллерийский генерал, Н.П. Остроумов – редактор «Туркестанских ведомостей» и др. Тесно спаяно было с царским режимом также православное духовенство, обслуживавшее интересы правивших классов и щедро субсидировавшееся из средств государственного казначейства. Из среды духовенства

вышел целый ряд этнографов, напр. Н.И. Ильминский, И.Н. Смирнов, Т.Д. Флоринский и др. Рука об руку с духовенством работали миссионеры, которые играли крупную роль в восточных губерниях, имевших в значительной степени нерусское население. С миссионерством были связаны такие этнографы, как Н.И. Ильминский, В.А. Бобровников, Н.Ф. Катанов, Н.И. Ашмарин, А.И. Емельянов и др.

Вся эта группа этнографов – помещики, крупные чиновники, выходцы из духовного звания, миссионеры – стояли на правом крыле буржуазной интеллигенции и разделяли консервативные убеждения. По отношению к национальному вопросу направление их взглядов было шовинистическим, и на целом ряде конкретных примеров это будет в дальнейшем нами показано.

Буржуазная интеллигенция не ограничивалась лишь одним правым крылом и насчитывала в своем составе представителей иного, либерального течения. Преобладающим носителем либеральных общественных взглядов в конце XIX и начале XX столетия являлась буржуазная интеллигенция, весьма неоднородная по своему составу. Прежде всего сюда входили те элементы дворянства, которые своевременно поняли выгоду отречения от феодальных привилегий и перехода к капиталистическим формам общественной жизни. Из числа дворян-помещиков вышли такие представители русского либерализма, как проф. П.Н. Милюков, акад. А.А. Шахматов и др. Затем, в ряды либеральной интеллигенции вступили разночинцы из людей всякого звания, по существу – представители мелкой буржуазии. Сюда относились некоторые земские деятели прогрессивного направления; из числа этнографов отметим деятелей 1890-х годов, во время Мултанского дела примкнувших к либеральному крылу буржуазной интеллигенции, – С.К. Кузнецова, выходца из среды мелкой буржуазии, и П.Н. Луппова, происходившего из духовного звания. В ту же эпоху определилось либеральное направление среди крупных капиталистов, которые начали вкладывать капиталы и в некоторые научные предприятия (экспедиция Сибирякова, экспедиция Рябушинского). Через высшую школу прошли выходцы из буржуазной среды, посвятившие свои силы не революционной борьбе за дело чуждого им рабочего класса, а спокойному служению «чистой» буржуазной науке. Из этой буржуазной среды вышли такие этнографы, как Д.А. Золотарев, С.И. Руденко, С.А. Теплоухов и др.

Весь этот либеральный лагерь буржуазной интеллигенции ориентировался в вопросах общественности в сторону прогрессивных течений. Пережитки феодализма являлись стеснительными для развития капитализма, и буржуазная интеллигенция стояла за отмену сословных приви-

легий, за демократические формы общественной жизни. По отношению к национальному вопросу она стояла за отмену национальных и вероисповедных ограничений, высказывалась за восстановление автономии Финляндии и Польши и за предоставление «культурной автономии» другим национальностям.

Ислам занимает достойное место в книге. Редактор совершил паломничество в Мекку и Медину. Деятели ислама всегда тепло благодарили Азата Гиззатовича за верность традициям предков, наследию отцов и дедов. Уважением аксакалов он дорожил и трогательно гордился, разбирался во многих религиозных вопросах. Для развития ислама в Западной Сибири Азат Гиззатович сделал достаточно много и приобщал читателей к этой великой религии. Мусульмане ему будут всегда благодарны. Ответы на вопросы особо привлекали внимание людей. Азат Гиззатович присутствовал на открытиях новых храмов и писал обширные статьи, которые читались на одном дыхании. Он был хорошим фотографом. Статьи дополнялись фотоиллюстрациями.

Азата Гиззатовича знали не только татары Сибири, но и других регионов России. Казань и ее великие таланты вели Азата Гиззатовича к светлым горизонтам, к прекрасному будущему – 25 страниц книги под заголовком «И, Казан, нурлы Казан, моңлы Казан» посвящены поездкам в Казань, встречам с интересными людьми, светочами татарской культуры, литературы, политики и искусства. Азат Гиззатович пишет вдохновенно, со всем жаром своего беспокойного сердца. Статья «Шигърият дулкынында» посвящена Гульшат Зайнашевой, Лене Шакирзяновой, Флере Тархановой. Фотография к статье «Әдипләребезне беләбезме?» увенчана красивой фотографией с участием Рафиса Курбанова, Шауката Сибгатуллина, Ркаиля Зайдуллина, Марселя Галиева, Рифата Сверигина, др. Прозорливость Азата Гиззатовича в каждом его слове, в каждой излучающей свет строке.

А.Г. Сагитов часто бывал в Казани – Всемирный Конгресс татар ежегодно собирал редакторов газет на трехдневные сборы. Азат Гиззатович общался со своими коллегами, передавал им свой богатый жизненный опыт, принимал у них все хорошее, прогрессивное, светлое и передовое. Газете «Яңарыш» всегда отводили призовое место среди газет, издающихся во многих регионах России. Редакторы татарских газет пропагандировали успехи «Яңарыш», в том числе опыт редактора. Известные люди Татарстана хорошо знали Азата Гиззатовича, принимали его тепло, всегда охотно общались с ним.

Азат Гиззатович был уважаемым человеком, всеобщим любимцем среди журналистов, писателей, поэтов и политиков Казани. Из Татарстана он привозил много книг, журналов, аудио- и видеокассет, дарил их своим знакомым и близким. Приезжал из Казани окрыленным, духовно

богатым, с новыми идеями и планами на будущее. Посещение Казани, общение с деятелями культуры, искусства, религии стали источником вдохновения, моральной стойкости, преданности и любви к своему народу, к любимой Родине, к природе и к самой жизни. Обо всем этом он писал в своих статьях, очерках, заметках.

Азат Гиззатович являлся своеобразным мостом, надежным связующим элементом между Татарстаном и Западной Сибирью. Гости из Казани, Уфы, из других городов, где проживает много татар, всегда приходили в редакцию «Яңарыш», встречались с Азатом Гиззатовичем. Все воспринятое, прочувствованное, пережитое он передавал своим читателям, с ними он делился своими думами, планами, предложениями. Без читательской аудитории не представлял свою работу, в общении с людьми находил свет, красоту и силу жизни.

Вопросам морали и воспитания Азат Гиззатович придавал первостепенное значение. Как педагог, он не мог далеко отходить от них. Его статьи на эту тему всегда проникновенны, читаются живо, в них много фактического материала, они пропитаны любовью к людям, излучают свет бытия и общечеловеческих ценностей, в них кредо и менталитет Азата Гиззатовича, его жизненная позиция. Любовь к людям, растениям, животным, к природе и к жизни переплетаются в сочинениях Азата Гиззатовича, его любовь всеобщая, земная, великая и лучистая. Поэтому строки, написанные Азатом Гиззатовичем, притягательны. Там нет фальши, там чистая, жизненная правда; радости и боли, переживания людей.

Культурное обслуживание населения, проведение национальных и религиозных праздников на страницах газеты отражались по-особому, приподнято, колоритно, можно сказать, даже торжественно. Концерты видных приезжих артистов не оставались незамеченными сотрудниками редакции. Если Азат Гиззатович сам не мог присутствовать на каком-то концерте, то отправлял одного из сотрудников, всесторонне проинструктировав, напутствуя как старший товарищ и большой знаток этого мероприятия. Сабантуи, национальные конкурсы и фестивали Азат Гиззатович старался посещать лично и на страницах газеты появлялись его обзорные и обширные статьи, которые затрагивали глубинные пласты народной жизни, проблемные вопросы настоящего, перспективу будущего.

Изо дня в день оттачивалось перо Азата Гиззатовича, все ярче сверкали грани его таланта; искусству писать он учился у видных татарских писателей, журналистов, поэтов. Драматург, прозаик, депутат Туфан Абдуллович Миннуллин, мечтавший побывать в Сибири, совершил свой визит вместе с известным историком и журналистом Резедой Вазихов-

ной Даутовой, посетил лауреата Тукаевской премии Якуба Занкиева. В книге особое место уделено этому важному событию! Газеты, журналы, издаваемые в Татарстане и в других регионах нашей страны, всегда находили свое место на рабочем столе Азата Гиззатовича; он искал любую новизну и охотно ее применял в своей работе. Он мастерски и талантливо приобщал людей к национальной культуре, к обычаям, традициям и религиозным праздникам. Он был просветителем народа, проводником национального духа в массы. Не только словом, но и делом, практикой своей жизни он систематически доказывал свою принадлежность своему народу; учил людей жить достойно и масштабно.

Первый редактор газеты «Яңарыш» был истинным интернационалистом, не противопоставлял людей друг другу. Лидером народа может стать тот, кто умом, душой и сердцем воспринимает все то, что присуще этому народу, кто отлично знает его прошлое, кто живет его заботами и чаяниями, кто заботится о его будущем. Азат Гиззатович был ярким лидером татар, живущих в Западной Сибири, он был их идейным вдохновителем, организатором их духовной и материальной жизни. Вот почему он не жалел своих сил, энергию для развития татарской культуры, для претворения в жизнь обычаев, традиций нашего народа. В этой области он, как маяк, будет светить долго и ярко.

Азат Гиззатович учил любить свой родной край, свой аул, детство и мать. В прошлом он черпал неиссякаемую силу, чувствовал и видел яркую красоту жизни. Он вдохновенно воспевал свой край, свое тяжелое детство, деревенский труд во имя жизни. Он душой и телом оставался деревенским. Самые нежные чувства и великую любовь он отдавал своей матери, наверное, вдвойне потому, что рос без отца, который погиб на поле брани минувшей войны. Азат Гиззатович только на несколько месяцев пережил свою мать. Он до конца жизни заботился о ней, дорожил ею, воспевал ее величайшую любовь.

Как старший из детей, он заботился о младших, старался быть примером во всем для них. Он цементировал свой род и вел его к содержательной, полнокровной жизни. Никто другой, наверное, как он, не ценил людей, тем более родных. Он был для них кумиром, надежной опорой, источником света, тепла и любви, жизненной силы. Азат Гиззатович трогательно пишет о д. Уба (Алга), где он родился и вырос, и его сыновняя любовь распространяется на необъятные просторы Сибири, на ее луга и реки, на ее леса и болота.

Книга богато и очень хорошо проиллюстрирована. Те, о ком Азат Гиззатович светло и содержательно писал, нашли свое достойное место на страницах книги. В середине декабря, в день рождения Азата Гиззатови-

ча, прошла презентация книги в областной научной библиотеке. Здесь собрались почитатели таланта Азат Гиззатовича, его родные, родственники, друзья и соратники. Выступающие говорили о большом значении книги в жизни татарского народа, о своих симпатиях и любви к редактору. Презентация подчеркнула большую, невосполнимую утрату для нашего народа

30 июня 2025 г. мэр Тюмени Максим Викторович Афанасьев подписал Распоряжение о присвоении элементу улично-дорожной сети наименования улицы Азата Сагитова. Инициатива Центра тюркологии Тюменского государственного университета в очередной раз была поддержана властями города.

Использованная литература

1. Азат Сагитов – первый редактор областной татарской газеты «Яңарыш» / авт.-сост. Х.Ч. Алишина. – Тюмень: Печатник, 2011. – 75 с. – (Жизнь замечательных людей).
2. Алишина Х.Ч. «Яңарыш» – себер татарлары тормышы энциклопедиясе» // Татар иле. – Казань, 1996. – 3 мая. – [на тат. яз.].
3. Алишина Х.Ч. «Яңарыш» – халык газетасы = [Яңарыш – народная газета] // Яңарыш. – 1996. – 20 сентября. – [на тат. яз.].
4. Алишина Х.Ч. «Яңарыш» – энциклопедия жизни сибирских татар // Яңарыш (Возрождение) / сост. А. Сагитов. – Тюмень, 2000. С. 8.
5. Алишина Х.Ч. «Яңарыш» – энциклопедия жизни сибирских татар» // Яңарыш. – 1996. – 30 апреля; То же // Татарские края. – Казань, 1996. – 29 мая.
6. Алишина Х.Ч. Азат абый турында якты истәлекләрем // Яңарыш. – Тюмень, 2020. – 25 декабря (№ 52). – [на тат. яз.].
7. Алишина Х.Ч. Азат Сәгыйтовка багышлыйм: [посвящается первому редактору газеты «Яңарыш» А.Г. Сагитову] // Яңарыш. – 2007. – 14 сентябрь (№ 37). – [на тат. яз.].
8. Алишина Х.Ч. Без – татарлар! // [Документально-хронологический сборник материалов, посвященных 15-летнему юбилею областной татарской газеты «Яңарыш»]. – Тюмень: ОАО «Тюменский дом печати», 2005.
9. Алишина Х.Ч. Газета «Яңарыш» – зеркало духовной жизни сибирских татар региона / Х.Ч. Алишина // Культура: личность, общество: материалы Всероссийской научно-методической конференции (Тюмень, 21–23 марта 1996) / науч. ред. В.В. Попов; Тюменский государственный институт искусств и культуры. – Тюмень, 1996. С. 110–112.

10. Алишина Х.Ч. На пути единения и добра: к 20-летию областной татарской газеты «Яңарыш» // Амир Юскаев / авт.-сост. Х.Ч. Алишина. – Тюмень, 2013. С. 92–95.
11. Алишина Х.Ч. Шәймиев чакыруы буенча = [По приглашению Шаймиева]: [интервью с профессором Х.Ч. Алишиной] // «Бирешмә, сакла газетаны!..» = «Не сдавайся, береги газету!..»: [документально–хронологический сборник материалов, посвященный 15-летнему юбилею областной татарской газеты «Яңарыш» («Возрождение»)] / А.Г. Сагитов; ред.-сост. А.М. Сагитова. – Тюмень, 2005. С. 110. – [на тат. яз.].
12. Алишина Х.Ч. Эпоха «Яңарыш» в духовной культуре сибирских татар // Тумашевские чтения: актуальные проблемы тюркологии: материалы III Всероссийской научно–практической конференции (Тюмень, 15 октября 2009). – Тюмень, 2009. С. 311–316.
13. Гарифуллин И.Б. Газета «Яңарыш» («Возрождение») и мое научное творчество / авт.-сост. Изиль Гарифуллин; ред. Х.Ч. Алишина. – Тюмень, 2011. – 250 с.
14. Сагитов А.Г. «Бирешмә, сакла газетаны!..» = «Не сдавайся, береги газету!..»: [документально–хронологический сборник материалов, посвященный 15-летнему юбилею областной татарской газеты «Яңарыш» («Возрождение»)] /; ред.-сост. А.М. Сагитова. – Тюмень, 2005. С. 110. – [на тат. яз.].

ТАТАР РУХЫ

ТАТАРСКИЙ ДУХ

Р.В. Шәйдуллин

«ӨМЕТ» ГАЗЕТАСЫ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН
(*Басманың 35 еллыгына багышлана*)

Россиянең башка халыклары белән берлектә татарлар, административ-территориаль берәмлектә генә түгел, ә мәгариф, мәдәният, фән һәм массакүләм мәгълүмат чаралары системасы ярдәмендә формалашкан һәм яшәп килгән бердәм мәгълүмати-мәдәни киңлектә дә милли үзенчәлекләрен саклыйлар. Татар милләте үсешендә вакытлы матбугатның аерым роле татарларның төбәкләргә һәм башка илләргә таралып урнашуы белән аңлатыла. Аерым алганда, XX гасырның 90 нчы елларында һәм хәзерге вакытта татарларның этномәдәни яңарыш һәм үсеш процесслары милли вакытлы матбугатның динамик эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйләнгән.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!

Эмет

Өмет

1989 елдан чыга

12+

ЗОЛОТОЙ ФОНД ПРЕССЫ 2015

УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ МЕДАЛЬЛЕ АТНАЛЫК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ

№ 17 (1841) ЖОМГА, 25 АПРЕЛЬ 2025 ЕЛ САЙТ: https://www.emet73.ru

1 май – Яз һәм хезмәт көне

Хөрмәтле Ульяновск өлкәсендә яшәүчеләр! Сезне Яз һәм хезмәт көне уңаеннан котлыйм!

Беренче май безнең илдә иң яраткан гаилә бәйрәмнәренең берсе һәм шулай ук Россиянең бәйсез профсоюзлары Федерациясе эгидасы астында хезмәт ияләрен берләштерүче көн булып кала.

Бүген хезмәт кешесе – алыштыргысыз һәм кыйммәтле белгеч, көнбатыш санкцияләренә һәм замана таләп иткән башка гади булмаган хәлләргә карамастан, без аның куллары белән илебез экономикасын яңа дәрәҗәгә күтәрәбез. Шушы бәйрәм көнендә без төрле тармакларда, шул исәптән дәүләт оборона заказы сферасында лаеклы дәрәҗәдә намуслы хезмәт итүче барлык ульяновскилыларга рәхмәт сүзләребезне юллыйбыз. Юбилейлы елда – Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә бу аеруча зур әһәмияткә ия.

Кадерле ульяновскилылар! Сезгә һәм сезнең гаиләләрегезгә иминлек, барлык башлангычларда уңышлар һәм яңа профессиональ казанышлар телим!

Ульяновск өлкәсе Губернаторы Алексей Русских.

ПУСТЬ ВЕСНА ВДОХНОВЛЯЕТ НА НОВЫЕ ДОСТИЖЕНИЯ! 1 МАЯ

Мәктәпләр яңартыла

Ульяновск өлкәсенең 10 мәктәбендә федераль программа буенча ремонт эшләре башланды.

Губернатор Алексей Русских В.В.Кашкадамова исемендәге 7 нче кадетлар мәктәбендә ремонт эшләренең нәтиҗәләрен бәяләде. Әлеге мәгариф учагына милләттәшебез Илһамия Маллямова җитәкчелек итә.

"Ульяновскиның 7 нче кадетлар мәктәбендә капиталь ремонт тәмамланды. Язгы каникуллардан соң килгән балалар яңа классларны, спорт залын, ашханәне һәм рекреацияләрне күреп чиксез шатландылар. Биредә 950 бала белем ала. Мәктәп моннан 50 ел элек төзелгән. Барлык класс кабинетлары да заманча җиһазландырылган – физика буенча лаборатория соклану тудыра, ә ОБЗР кабинетында яңа манекеннар һәм электрон тир урын алган. Мәктәп тирәсендәге территорияне төзекләндерү мәсьәләсен дә карадык. 7 нче мәктәп базасында УАЗ һәм механика заводы белән берлектә яшь электронщиклар өчен "ТехноПрофи" профориентацияләү клубы ачу күздә тотыла. 11 нче лицейда да ремонт эшләре башланды. Быел федераль үзәк ярдәмендә төбәкнең 12 мәктәбе капиталь яңартылачак",- диде регион башлыгы.

Мариин гимназиясендә, 13 нче гимназиядә, 2 нче гимназиядә һәм 91 нче мәктәп-интернатта, Ишеевка лицеенда, Димитровградның 23 нче мәктәбендә, Троицк-Сунгур казаклар мәктәбендә, шулай ук Николаевка, Инза, Мәләкәс һәм Чынлы районнары мәктәпләрендә бер еллык һәм ике еллык контрактлар буенча капиталь ремонт эшләре башкарыла.

Салаховлар сынатмас!

Ульяновск өлкәсендә "Ел гаиләсе" конкурсының өлкә этабы старт алды.

Чынлы районы Карабаевка авылында яшәүче Салаховлар гаиләсе "Ел гаиләсе" өлкә конкурсының "Күп балалы гаилә" номинациясендә катнаша. Ә Зур Нагаткино авылында гомер итүче Хакимовлар гаиләсе төбәк бәйгесенең "Гаилә – традицияләрне, гореф-гадәтләрне саклаучы" номинациясендә иҗади осталыгын күрсәтә.

Әлеге конкурс быел инде 20 нче тапкыр үткәрелә, ә Ульяновск өлкәсе Губернаторының "Ел гаиләсе" дип исемләнгән премиясе 2025 елда 17 нче мәртәбә тапшырылачак. "Ел гаиләсе – 2025" конкурсында катнашучыларны бүләкләү тантанасы күркәм традиция буенча 15 майда – Халыкара гаилә көнендә узар дип көтелә.

Татар телен яхшы белүчеләр

Казанда татар теле һәм әдәбияты буенча XII нче Халыкара олимпиаданың йомгаклау этабы узды.

Хәзер инде традициягә кергән олимпиадага Россиянең 28 төбәгеннән 500дән артык укучы, шулай ук Казахстан, Төркия, Кыргызстан һәм Әзәрбәйҗан вәкилләре килгән иде. Татар телен иң яхшы белүчеләр язма этап, сөйләм бәйгесе һәм проект эше номинацияләрендә үзләренең осталыкларын күрсәттеләр.

Быел Халыкара олимпиадада Ульяновск өлкәсеннән җиде бала - Николаевка районы Зур Чирекле мәктәбе, Иске Кулаткы район үзәгенең 1 нче мәктәбе һәм Димитровград шәһәренең Г.Тукай исемендәге 22 нче мәктәбе укучылары катнашты. Николаевка районы Зур Чирекле урта мәктәбенең 11 сыйныф укучысы Мәрьям Даньялова призер исеменә лаек булды. Мәрьямне һәм мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нәсиха Ягудинаны чын күңелдән котлыйбыз!

Май бәйрәмнәрендә 2 тапкыр 4әр көн ял итәчәкбез

Май бәйрәмнәрендә ике тапкыр 4әр көн ял итәчәкбез: 1-4 май һәм 8-11 май аралыгында. Бу хакта "РИА Новости" Дәүләт Думасының Социаль сәясәт комитеты башлыгы Ярослав Нилов сүзләренә таянып яза.

Аның искәртеп үтүенчә, озын яллар бәйрәм көннәрен күчерүгә бәйле. Быел 4 гыйнвар шимбәгә туры килеп, Хөкүмәт карары нигезендә, шул шимбә ялы 2 майга күчерелгән. 23 февраль – якшәмбе ялы исә 8 майга калдырылган.

Следующий номер газеты "Өмет" выйдет в пятницу, 2 мая 2025 года.

Бүгенге шартларда татар газеталарының төп максат һәм бурычлары – иҗтимагый һәм гражданлык татулыгы үзгенә әверелү, татар халкында хәзерге цивилизацияле җәмгыять өчен ярашлы культура дәрәҗәсе фор-

малаштыруга ярдәм итү. Шул ук вакытта вакытлы матбугат басмалары «дүртенче хакимият» структураларында эшләүчеләрнең югары әхлакый җаваплылыгына ирешергә, мәгълүмат «трансляторы» булырга, теге яки бу мәсьәлә буенча үз фикерен белдерергә һәм аны нигезләргә дә тиеш. Соңгысы милләтара мөнәсәбәтләрнең заман чынбарлыгында формалашып килүче яңа мәдәни халәтеннән чыгып, милли сәясәттә дөрес акцентлар урнаштыруда аеруча зур әһәмияткә ия. Бу таләпнең үтәлешен һәрдаим күз уңында тоту – татар матбугатының бурычы.

Хәзерге татар газеталарының халык тормышында роле бәяләп бетергесез, алар әдәби телне саклау, асыл милли үзенчәлекне тапшыру вазифасын үтәү белән беррәттән, татар халкын башка халыкларның мәдәниятләре белән үзара бәйләнешкә тарта, аларның якынаюына ярдәм итә. Шул ук вакытта алар Россия Евразиясенең гаять зур территориясендә таралып яшәүче халкыбызның төрле этник бергәлекләре мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерүдә мөһим роль уйныйлар.

Быел – 2025 елда, татар вакытлы матбугаты барлыкка килүгә 120 ел тулды. 1905 елның 19 маенда Санкт-Петербургта татар телендә беренче рәсми атналык газета бастыруга рөхсәт бирелә һәм газета 1905 елның сентябрендә Санкт-Петербургта «Нур» исеме белән дөнья күрә. Аның нигезләүчесе, мөхәррире һәм нашире күренекле мәгърифәтче, Россия дин эшлеклесе Гатаулла (Атаулла) Баязитов була. Россия рәсми даирәләрендә абруе булуга карамастан (1871 елда Санкт-Петербургка чакырып алына, 2 нче мәхәлләне җитәкли, соңрак хәрби ахун вазифасына билгеләнә; бер үк вакытта Россия Тышкы эшләр министрлыгы Азия департаментының Көнчыгыш телләр бүлегендә тәрҗемәче һәм төрки телләр укытучысы була, башкаладагы төрле уку йортларында ислам дине нигезләрен укыта), газета чыгарырга рөхсәт алуга ул бик зур авырлык белән генә ирешә. Аңа татар телендә газета чыгару мәсъәләсе буенча Россия империясенең төрле хөкүмәт органнары кабинетларында утырган чиновниклар алдында дистә ярым еллар дәвамында бик күп тапкыр баш иярга туры килә. Беренче мәртәбә 1891 елның ноябрендә ул Санкт-Петербургта рус һәм татар телләрендә «Һәфтә» («Атна») газетасын чыгаруга рөхсәт сорап гариза яза. Ләкин мәгърифәтченең үтенече, рәсми органнарның гаризага карата язылган резолюциясендә күрсәтелгән түбәндәге сәбәпләр: рус-татар газетасына зур ихтыяҗ булмау; рус телендә нәшер ителгән «Туркестанские ведомости» (Ташкент шәһәре) һәм «Акмолинские областные ведомости» (Омск шәһәре) рәсми газеталарының сарт (үзбәк – «Туркестон вилоятиниң газети») һәм кыргыз (казах – «Дала уелатының газети») телләрендәге кушымталары булуга нигезләнеп, кире кагыла. Бу газеталарда патша даирәсе тормышыннан алынган кыскача мәгълүматлардан,

Төркестан генерал-губернаторының җирле халыкка кагылышлы боерыклары һәм боерыкларының тәрҗемә ителүе турындагы хәбәрләрдән, югары администрациянең яңа боерыкларыннан, Россия сәүдәсе һәм сәнәгатенең торышына багышланган мәгълүматлардан тыш, тарихи һәм этнографик эчтәлектәге мәкаләләр, шулай ук әлеге төбәк халыкларына хас кайбер гадәтләрнең (мәсәлән, җирле наркотиклар куллану) зарарын, табигать күренешләрен (ай тотылу, җир тетрәүләр) фәнни яктан аңлаткан, төбәктәге кайбер үзенчәлекле вакыйгаларга кыскача тасвирлама биргән, гаҗәеп ачышлар һәм уйлап табулар, фән, сәнгать һәм әдәбият, сәнәгать һәм һөнәрчелек өлкәсендәге яңалыклар, алгарышлар турындагы язмалар басыла.

Шуннан соң, ният иткән газетасының программасын әлеге басмалар юнәлешендә беркадәр үзгәртеп, Г. Баязитов татар телендә газета чыгару турында дәүләт структураларына яңа гариза юллый. Бу үтенеченә ул гомумән җавап алмый. 1893 елда ул берничә тапкыр «Чишмә» гаилә газетасын чыгару өчен рөхсәт алырга омтылыш ясап карый. Болары да патша хакимияте тарафыннан җавапсыз калдырыла. Ниһаять, 1895 елда «Нур» исемендәге газета чыгарырга рөхсәт алуга ирешелә. Бу юлы газета чыгару идеясе югары дәрәҗәле түрәләр, аерым алганда дәүләт секретаре В.К. Плеве тарафыннан хуплана; Казаннан махсус депутатлар килә, ләкин Санкт-Петербург цензура комитетының Көнчыгыш цензоры В.Д. Смирнов Г.Баязитов башлангычына кабат аяк чала. Ниһаять, 1905 елның 2 сентябрендә, бары тик буржуаз-демократик революция шаукымы дулкынында, Россиядә татар телендәге беренче матбугат басмасы дөнья күрә. Аны чыгаруга рөхсәт биргән документны, татар телендә нинди дә булса матбугат басмасының дөнья күрүен еллар дәвамында максатчан рәвештә тыя килгән В.Д. Смирнов үзе имзаларга мәҗбүр була. Ә шулай да, чынлыкта, беренче татар газетасы үзенә гасыр катламы аша юл яра: татар зыялылары туган телләрендә вакытлы басма нәшер итү өчен 1808 елдан бирле көрәшә, патша хөкүмәте белән үзара тартыш йөз елга якын дәвам итә.

Санкт-Петербургта «Нур» газетасының балкып чыгуы Россиянең барлык мөселман җәмәгатьчелеге тарафыннан зур өмет белән каршы алына. Газета 1905–1914 елларда нәшер ителә. 1910 елга тиражы 2,5 мең данә тәшкил итә. Анда Петербург һәм губерна татар җәмгыятенең рухи, эшлекле һәм иҗтимагый тормышы мәсьәләләре яктыртыла, Россиядә һәм чит илләрдә мөселманнарның тормышына һәм эшчәнлегенә күзәтү бирелә, Россия мөселманнары тормышының төрле өлкәләренә кагылышлы рәсми дәүләт актлары һәм канун күрсәтмәләре басыла. «Нур» басмасы татарларның вакытлы матбугат эшен үстерүенә зур этәргеч бирә. 1906 ел-

ның октябрендә Казанда «Казан мөхбире» газетасы чыга башлый, аның программасында татар мәнфәгатен, халыкның тигезлеккә һәм ireккә (дин, сүз, шәхес иреге һ.б.) омтылышын яклау алга куела. Татар телендә бер-бер артлы «Йолдыз», «Вакыт», «Идел», «Фикер», «Ил», «Тормыш», «Урал», «Азат», «Таң йолдызы», «Бәянелхак», «Әл-Ислах» һәм башка матбагалар дөнья күрә.

19 май – татар профессиональ журналистикасы тарихында башлангыч нокта. 1998 елның 24 июнендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы 19 майда Татарстан Республикасының матбугат көнен бәйрәм итү турында карар кабул итә. Татарстан Республикасы Матбугаты көне уңаеннан бу көнне, гадәттәгечә, журналистика һәм массмедиа өлкәсендә «Бәллүр каләм» республика конкурсына йомгак ясала һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы үткәрелә.

Бүген, массакүләм мәгълүмат чараларының бик күп төрләре гамәлдә булуга карамастан, милли газеталар Россия халыклары милли-мәдәни тормышында зур урын били. Алар арасында Ульяновск өлкәсе татарлары өчен нәшер ителүче «Өмет» газетасы да бар. 2024 елның декабрендә газета 35 еллык юбилеен зурлап билгеләп үтте. Әлеге вакытлы басма Россия төбәкләрендә демократия җилләре исә башлагач, Октябрь революциясеннән соң төрлесе төрле елларда ачылып, Татарстаннан читтә чыгып килгән һәм илле-алтмыш еллар чамасы тукталып торган татар басмалары арасында беренчеләрдән булып чыга башлый, аның тәүге саны 1989 елның 30 декабрендә дөнья күрә. «Өмет» артыннан Россиянең татарлар күпләп яшәгән башка өлкәләрендә дә бер-бер артлы унга якын газета, шулар арасыннан Самарада – «Бердәмлек», Киров өлкәсендә (Малмыж шәһәре) – «Дуслык», Оренбургта – «Яңа вакыт», Төмәндә – «Ак калфак», «Яңарыш» һәм башка газеталар нәшер ителә башлый. 1990 елларда Татарстан Республикасында татар телендә 74 газета һәм 24 журнал (шулардан дәүләт газеталары – 52, журналлар – 19) чыга.

Совет илендәге үзгәртеп кору җилләре вакытында барлыкка килгән иҗтимагый-сәяси шартларда, шуңа да карамастан зур авырлыклар белән ачылган «Өмет» газетасына тернәкләнеп китү бик җиңел булмагандыр, әлбәттә. Бу басма милли энтузиастлар ярдәмендә чыгарыла һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерелә. Казан һәм Ульяновск милләтпәрвәрләре газетага идея-тематик юнәлеш сайларга, аның үз йөзен булдырырга ярдәм итәләр. Ул, әлбәттә, Ульяновск өлкәсендә 1930 еллардан бирле нәшер ителеп килгән Иске Кулаткы район газетасы «Күмәк көч»тән аерылып торырга тиеш була. Төп максаты татар телен, халкыбызның үзенчәлекле бай мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү контекстында Ульяновск татарларын берләштерү дип билгеләнгән яңа газета алдына

зур бурычлар куела. Җирле татар җәмәгатьчелеген милли-мәдәни яктан агарту, укучы яшьләрне татар халкының үткәне һәм хәзерге тормышыннан алынган төрле тарихи-мәдәни материаллар белән мәгълүмати тәэмин итү юлы белән милли-патриотик рухта тәрбияләү иң мөһим бурычларыннан берсе итеп билгеләнә. Бер үк вакытта газета җитәкчелегенә редакция коллективын формалаштыру, басманың төп рубрикаларын булдыру һәм бизәлеш-дизайнны кайгырту, тираж туплау, типография эшчәнлеген көйләү, газетаны тарату һәм башка бик күп мөһим мәсьәләләр белән берьюлы шөгыльләнергә туры килә. 1990 елның 1 гыйнварында газетаның баш мөхәррир итеп Галимҗан Насыйров билгеләнә. Дөрес, ул бу вазифада ике ай чамасы гына (28 февральгә кадәр) эшли, ә аннары эстафетаны Казан дәүләт университетын тәмамлаган белгечкә – Исхак Хәлимовка тапшыра. Исхак Хәлимов баш мөхәррир вазифаларын бүгенге көнгә кадәр бик уңышлы башкарып килә.

Ышаныч белдереп, шәкертен бу җаваплы вазыйфага хәер-фатиха биреп озаткан остазын искә алсак, Исхак Хәлимовка бәхет елмайган дип әйтергә кирәк. Аның һәм бик күпләрнең остазы – Флорид Имамәхмәт улы Әгъзамов – Казан дәүләт университеты журналистика бүлегенең беренче җитәкчеләренең һәм татар журналистика мәгарифенең барлыкка килү һәм үсеш чорын символлаштыручыларның берсе. Идел-Урал буе массакүләм мәгълүмат чаралары өчен журналистлар – һәм җитәкчеләр дип тә әйтергә кирәк, чөнки алар башлыча шул журналистлар арасыннан үсеп чыга – аның җитәкчелегендә әзерләнә. Үзәк массакүләм мәгълүмат чараларында да, бигрәк тә телевидение өлкәсендә, Казан университетын тәмамлаган белгечләр шактый. Флорид Имамәхмәт улы фәнгә үз исемен язып калдыру өчен түгел, ә күбрәк студентлар һәм үзе җитәкләгән бүлек (соңрак факультет) өчен эшләгән галим иде. Эстафетаны Ф. Әгъзамовтан алып калган декан, шулай ук аның шәкерте Васил Гарифуллин (журналист, филология фәннәре докторы, профессор, Казан федераль университетының Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институты Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбенең Милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире) аны шундый сүзләр белән искә ала: «Ул безнең укуыбызны кайгырту белән бергә, тулай торакка килеп, безнең ничек яшәвебезне, проблемаларыбыз бармы-юкмы икәнен сораша һәм һәркемнең иҗади эшчәнлеге белән кызыксына иде. Уку йортын тәмамлаганда ул безгә нинди юлга басарга кирәклеге турында киңәшләр дә бирде».

Студент Исхак Хәлимов та Флорид Әгъзамовның киңәше белән диплом эшен татар телендә уңышлы яклаганнан соң, туган ягына – Ульяновск өлкәсенә журналист итеп юллана, анда ул, әйтелгәнчә, «Өмет»

газетасына баш мөхәррир итеп билгеләнә. Исхак Хәлимовка үз планнарын үзгәртергә туры килә: диплом эшен татарча язып яклау һәм үсеше алгарышлы булмаган төбәккә эшкә җибәрелү мәгънәсендә генә түгел, бәлки Ульяновск татарларының этномәдәни һәм иҗтимагый-сәяси тормышында үзгәрешләр башланган катлаулы заманнарда шул үзгәрешләрнең башында торырга һәм аларны чагылдырып барырга тиешле газетаны җитәкләү, тормышта үз урынын эзләү мәгънәсендә дә. Белүемчә, университетта укыган биш ел эчендә күбесенчә рус телендә язган, диплом эшен рус телендә әзерләү, рус газетасы редакциясендә эшләү хыялы белән яшәгән егеткә ниятләрен үзгәртергә һәм татар газетасы баш мөхәррире вазифаларын җилкәсенә алырга туры килә. Университетны тәмамлаганнан соң аның нинди кыен хәлгә элэгүен мәктәптә татар теленнән төпле белем алудан мәхрүм калган, туган тел буенча дәресләр этномәдәни компонент (татар әдәбияты һәм туган тел) рәвешендә генә укытыла торган мәктәптә укып чыкканнар яхшырак аңлар. Кыска гына вакыт эчендә аңа татар әдәби теле өлкәсендә белемнәрен үстерү чарасын күрергә, милли-мәдәни дөньяга баштанаяк чумарга һәм бу өлкәдә фикер сөрешен киңәйтергә туры килә. Һәм ул моңа ирешә. Монда, әлбәттә, мәктәптә һәм университетта яхшы уку гына түгел, ә хезмәт сөючәнлек, табигатьтән бирелгән журналистлык таланты һәм оештыру сәләте дә чагылыш тапкан дип уйларга кирәк.

Васил Гарифуллин истәлекләренә әйләнеп кайтыйк: «Мин университетны тәмамлагач, аның янына (Ф.И. Әгъзамовка – Р.Ш.) килеп: «Рөхсәт итсәгез, аспирантурада калырга теләр идем», – дигәнемне хәтерлим. Ул катгый рәвештә: «Юк, калмыйсың. Журналистларны иҗатка өйрәтү өчен үзеңә зур тормыш тәҗрибәсе узарга кирәк. Мин синең кайда эшләячәгең турында сөйләштем инде. Телевидение һәм радиотапшырулар буенча Дәүләт комитетында көтәләр сине. Анда өч ел эшлисең һәм тупланган тәҗрибә белән безгә кире кайтасың». Мөгаен, Исхак Хәлимов та Ульяновскига шундый килешү буенча, журналистлык эшендә тәҗрибә туплау өчен юллангандыр.

Исхак Хәлимов менә 35 ел инде «Өмет» газетасының баш мөхәррире буларак Ульяновск өлкәсе татарларына хезмәт итә. Иҗат коллективын булдыру, аның әгъзаларыннан менә дигән журналистлар әзерләү, билгеле, газетаның баш мөхәррриренең эшчәнлеге белән бәйле. Аның чын журналистлар булдыруга күп көч куйганын газетаны укучылар бик яхшы сизәләр. Баш мөхәррир һәр әдәби хезмәткәрне дөрес сайлап алып, аның урынын сәләте һәм омтылышларыннан чыгып билгели белә. Дөрестән дә, газета чыгару катлаулы процесс. Редакциядә эшләүче һәр хезмәткәргә берничә һөнәр үзләштереп, еш кына берничә вазыйфа башкарырга туры

килә. Бүген коллективта алты-җиде кеше эшли, алар дөньядагы, илдәге һәм төбәктәге хәлләрдән һәрвакыт яхшы хәбәрдар, интервью да ала, очрашулар да уздыра, язмасын да өлгертә, фотога да төшерә, яңа темалар, рубрикалар тәкъдим итә, сәхифәләр ача, бик күп операцияләрне компьютерда үзләре башкара.

Хәзерге вакытта «Өмет» газетасы атнага бер тапкыр 12 биттә һәм айга бер тапкыр 16 биттә чыга. 2012 елдан башлап, айга бер тапкыр «Без бергә» кушымтасы чыгып килә. Әлеге кушымтаны Татарстан Республикасының «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы гамәлгә куя, ә «Шәһри Казан» газетасы аны «Өмет»кә әзерләп бирә. Кушымтада Татарстан, милли тормыш яңалыклары, татар халкының күренекле шәхесләре, дәүләт эшлеклеләре белән әңгәмәләр урын ала. 2025 елның 25 апреленә «Өмет» газетасының 1841 саны дөнья күрә.

Россиянең өлкә татар газеталары арасында хәзеге вакытта «Өмет» тираж күрсәткече буенча беренче урынны били – газетаның тиражы 2008 елда – 6 мең, 2012 елда – 7,1 мең, 2023 елда – 4,6 мең, 2025 ел башында 4 меңнән артык данә тәшкил итә. Газетаны халык ярата, аңа язылалар. Әлбәттә, бу казанышта «Өмет»нең баш мөхәррире һәм хезмәткәрләренең роле әйтеп бетергесез зур. Төрле авырлыкларга һәм ыгы-зыгыларга карамастан, редакция коллективы җитәкчесе Исхак Хәлимов үзе җитәкләгән басманың милли-мәдәни кыйбласын дөрес билгеләп, алдан юл ярып бара. Баш мөхәррирнең дипломат булуы, халык белән дә, хөкүмәт белән дә, хезмәткәрләр белән дә уртак тел табып эшләве аркылы газета зур казанышларга иреште. «Өмет»нең 35 еллык тантанасында Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы Президиумы әгъзасы, Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе Башкарма комитеты рәисе, җәмәгать эшлеклесе, журналист Рәмис Сафин әлеге басма турында горурланып шундый сүзләр әйтте: «Бүген төбәкләрдә газеталар күп чыга. Яшерен-батырын түгел, төрле хәлдәгеләре бар. Тик без, бередәгеләр, беркайчан да түбәтәебезне салып, акча җыеп йөрмәдек. Хөкүмәт ярдәмендә булдык. Губернаторларыбыз һәрвакыт ярдәм итте. Милли газеталарны, милли телевидениене алып баруда булышлыкларын һәрдаим тоеп тордык». Шул ук вакытта ул газетаны түбәндәгечә характерлады: «Чынлап та, «Өмет» яратып укый торган басма. Анда бөтен темага да язмалар бар. Җирле яңалыкларны да җиткерә ул, гаилә-мәхәббәт мәсьәләләре дә күтәрелә анда, шигърият һәм котлаулар да чыга, мәзәкләр дә басыла. Теләсә кайсы яшьтәге укучыга барып җитә торган газета бу. Соңгы вакытта уртак проектыбызны – балалар сәхифәсен яңарттык. Балаларга матур язмалар, конкурслар ошап китте».

Төрле елларда нәшер ителгән саннарга ясалган контент-анализ газетаның шактый киң тематик рубрикациясе булуын күрсәтә. Басма дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында иҗтимагый-сәяси мәгълүматны, татар халкының телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү, яшьләргә рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү мәсьәләләрен үз эченә ала. Шул ук вакытта газетада күп еллар дәвамында әйдәп баручы темаларның берсен татар халкын Ульяновск өлкәсендә яшәүче барлык милләтләр һәм конфессияләр вәкилләре белән үзара аңлашу һәм дуслык рухында тәрбияләү тора. Соңгы вакытта күпмилләтле Ульяновск төбәге өчен актуаль булган милли һәм дини экстремизмны кисәтү темасына аерым игътибар бирелә башлады. Үткәрелгән контент-анализдан шулай ук тагын бер нәтиҗә ясау мөмкин: газета каләм ияләре өчен иң мөһимен күз уңында тота – аларның иҗат җимешләрен халыкка җиткерергә тырыша. «Өмет» хезмәткәрләре һәр авторны үз итәләр, аларга канат куярга һәм һәркайсын дөньяга танытырга омтылалар.

«Өмет»нең төп рубрикалары арасында иң мөһимнәре: «Яңалыклар баганасы» – укучылар тарафыннан иң элек укыла торган, иң популяр сәхифә – илдә һәм төбәктә барган вакыйгалар белән таныштыра; «Ачык трибуна»да танылган сәясәтчеләр, икътисадчылар, Ульяновск өлкә Законнар чыгару җыелышы депутатлары, өлкә хөкүмәте вәкилләре, милли һәм дини берләшмә лидерлары белән әңгәмәләр урнаштырыла; «Татар авыллары: үткәне һәм хәзергесе» сәхифәсе туган якны өйрәнүчеләрнең, авылларда яшәүче тарихыбызга битараф булмаган шәхесләрнең үз авылларының тарихы һәм күренекле кешеләре (сугыш һәм хезмәт ветераннары, иң яхшы гаиләләр, галимнәр, дин әһелләре һ.б) турындагы материалларын үз эченә ала; «Милләт язмышы – мәктәптә» сәхифәсендә Ульяновск өлкәсе татар авыллары мәктәпләренең уңышлары һәм проблемалары, шулай ук шәһәр мәктәпләрендә татар этномәдәни компонентын үстерү, татар балалары өчен туган тел, дин дәресләре түгәрәкләре һәм төрле өстәмә факультативлар ачу мәсьәләләре күтәрелә; «Милли проектлар» сәхифәсендә «Мәгариф» өстенлекле милли проектын гамәлгә ашыру кысаларында грантлар алган укытучылар һәм гомуми белем бирү мәктәпләре, «Агросәнәгать комплексын үстерү» өстенлекле милли проектын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы тармагына дәүләт ярдәме күрсәтелү мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр урын ала; «Дин һәм җәмгыять» сәхифәсендә Ульяновск өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте һәм Русия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте эшчәнлекләре, абруйлы дин әһелләре, җирле мөселманнарның үткәндәге һәм хәзерге көннәрдәге тормыш үзенчәлекләре, дини бәйрәмнәр, йолалар һәм дини хасиятләре-

безгә караган башка бик күп мәсьәләләр турында материаллар бастырыла. Шулай ук «Татар халкы тарихы битләре», «Күренекле якташларыбыз», «Гаилә – тормыш чишмәсе», «Мин – яшь», «Балалар бите», «Әдәби бит» сәхифәләре дә бик популяр. Газетада басылган язмалар, бигрәк тә тарихи сәхифәләр төбәк тарихы белән кызыксынучылар санын елдан-ел артыра бара. Укучылар газетада урын алган язмалар үрнәгендә, андагы киңәшләрдән файдаланып нәсел агачларын – шәҗәрәләрен төзиләр, буыннар бәйләнешен, үзләренең ерак тамырларын барлыйлар, әби-бабалары яшәгән төбәкләр, авыллар тарихын өйрәнергә керешәләр һәм бу турыда язмалар юллыйлар.

Исхак Хәлимов санавы буенча, 35 ел эчендә редакциянең компьютер базасында җирле авторларның 130 дан артык җыентыгы әзерләнгән. Шулай ук «Сембер язлары» альманахының җиде томы әзерләнеп, нәшриятка тапшырылган. Газета ярдәмендә һәвәскәр һәм профессиональ авторларның төрле әдәби, шигъри һәм тарихи җыентыклары дөнья күргән.

«Өмет» газетасы татар халкының яшәеше-көнкүреше белән беррәттән тулаем ил тормышы белән таныштырып баруга да зур игътибар бирә. Соңгы елларда, махсус хәрби операция игълан ителгәннән бирле, басма әлеге теманы актив рәвештә яктыртып бара.

«Өмет» газетасы – Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе һәм «Сембер» татар эшмәкәрләре клубы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмияткә ия проектларның (Ульяновск һәм Димитровград шәһәрләрендә татар этномәдәни компонентлы гомуми белем бирү мәктәпләре ачу, Ульяновскида Татар мәдәнияте үзәгенә капиталь ремонт уздыру, Димитровградта, Ульяновскида Федераль Сабантуйлар, Иске Кулатка шәһәр тибындагы поселокта Бөтенроссия авыл Сабантуен уздыру һ.б.) мәгълүмати иганәчесе дә. Газета редакциясе Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе, «Сембер» татар эшмәкәрләре клубы, «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы, «Татар яшьләре үзәге» һәм «Яңа дулкын» яшьләр оешмалары, «Туган тел» мәгърифәтчелек җәмгыяте һәм башка иҗтимагый оешмалар белән тыгыз элемтәдә эшли.

«Өмет» газетасы юбилее уңаеннан оештырылган тантанага, шатлыклы вакыйганы уртаклашу өчен, татар басмасының иҗатташлары, дуслары һәм иганәчеләре җыелды. Миллият һәм мәдәният бәйрәменә, ерак араларны якын итеп Казан, Самара, Димитровград шәһәрләреннән, Иске Кулаткадан, Радищеводан һәм Иске Майна, Мәләкәс, Николаевка, Чардаклы, Яңа Малыклы районнарыннан якташларыбыз һәм милләттәшләребез килде, котлаучылар арасында Ульяновск өлкәсендә нәшер ителүче мордва һәм чуваш газеталарының баш мөхәррирләре дә бар иде. Әлеге басманың якын дусты, кирәк вакытта таянычы һәм терәге

дә булган абруй иясе, Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рәмис Сафин «Өмет» газетасының төбәк халкының өметләрен тулысынча аклавы, кирәк чакта яклаучысы да, киңәшчесе дә булуы, Ульяновск татарларына хезмәт итүе турында аеруча горурланып сөйләде. Баш мөхәррир Исхак Хәлимов белән икесенең, кайчандыр Казан дәүләт университеты студентлары булган ике яшь егетнең, Ульяновск төбәгенә килеп төпләнүләрен матур итеп искә алды, биредә канат ныгытуларын, уртак тел табып эшләүләрен ассызыклады.

Тантаналы кичә ахырында газетаның баш мөхәррире анда катнашучыларның барысына да рәхмәтен белдерде. ««Өмет» – ул барчабызның да шатлыгы, казанышы һәм киләчәккә өмете. «Өмет» чыгып килә икән, димәк, татар теле язма рәвештә сакланачак. Аның битләрендә халкыбызның тарихы чагыла, бүгенге тормышыбыз елъязма булып языла. Хәзер басмабыз электрон вариантка да күчерелә», – диде ул. Баш мөхәррир үз чыгышында «Өмет»нең чишмә башында торган ветераннарны: газетаның беренче баш мөхәррире Галимҗан Насыйров, шагыйрь Равил Шәфигуллин, журналист Айрат Ибраһимовларны, газета белән актив хезмәттәшлек итүчеләрдән Азат Курчаков, Дамир Шәрипов, Котдус Сафиуллин, Әнвәр Мөхәммәтрәхимов, Римма Алькаева, Лена Садыйкова, Гакыйль Сәгыйров һәм Рәшит Шабакаевларны аерым искә алды.

«Өмет» газетасының 2024 елның декабрендә узган ул бәйрәмендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Мансур Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты исеменнән котлау сүзе белән мин дә чыгыш ясадым. Анда 1990 елның декабрендә Ульяновск шәһәренең Гончаров урамындагы бер йортта урнашкан редакция бүлмәсендә «Өмет»нең кайбер хезмәткәрләре белән танышуым турында сөйләдем. Заманында «Татар Совет Энциклопедиясе» буларак күзалланган Татар энциклопедиясен әзерләүче бүлегебезнең җитәкчесе Фәрит Хакимҗанов мине Ульяновск өлкәсенә – якташларым янына – энциклопедия өчен анда яшәүче татарлар турында материаллар туплау максаты белән командировкага җибәргән иде. Инде аннан бирле бик күп вакыт үтте, ялгышмасам бу очрашу вакытында мин Исхак Хәлимов, Айрат Ибраһимов, Резеда Садыйкова, Рәмилә Сафиналар белән таныштым.

Шунысы да кызык булды, Айрат Ибраһимов белән без 1978 елдан бирле танышбыз икән. Күрешү мизгелендә, бер-беребезгә игътибар белән карап торганнан соң, икебез дә беренче тапкыр ничек танышуыбызны искә төшердек. Байтак еллар элек, көзге көннәрнең берсендә, Рязаново совхоз-техникумыннан туган авылым Әбдеригә (Лабитка) кайтырга машина көткәндә, Айрат ага Димитровградның Гау күпере тукталышында туктап, мине үзенең кызыл төстәге җиңел машинасына утырткан иде.

Аның, хатыны белән икәү, туган ягына – Башкортстанга кайтып барышы булган. Айрат ага юл буе «коммунизм» һәм «фашизм» төшенчәләренең бер үк мәгънәне аңлатуы турында сөйләп барды, төрле дәлилләр китерде. Хәзер аңлавымча, ул бу мәсьәләне шул чор журналистикасында өстенлек ала барган «кызган фактлар» күзлегеннән аңлатырга тырышты. Мин, ул вакытта 18 яшьлек егет, аның дәлилләре белән килешә алмадым. Совет илендә коммунизм таңы атачагына бик ышанап бетмәсәм дә, аны «фашизм» белән тиңләштерүне тарихи күзлектән бик үк дөрес дип тапмадым. Минем Исмагыйль бабам Искаков Бөек Ватан сугышында һәлак була, әтием – танкист Вәли Шәйдуллин өч ел буе немец фашистларына каршы сугыша. Нәрсә, ул сугышта шул ике идеология бәрелешмәде мени? Сугышка кадәр һәм сугыш елларында ике илдә дә уздырылган сәяси репрессияләр турында да фикерләребез аерылды. Мин бу мәсьәләдә дә үз фикеремнән кире кайтмадым. Әлеге фаҗигале процессларда җитәкчеләр белән беррәттән халыкларның да гаебе барлыгын исбатларга тырыштым. Чиялемар авылы борылышына килеп җиткәч, машина хуҗасы Айрат абый, биргән акчадан баш тартып, бәлки әле очрашырбыз дигән сыман, минем белән елмаеп саубуллашты. Ә бит очраштык! Ульяновскида, редакция бүлмәсендә! Шундагы «кабат танышу»дан соң, ул әлеге бәхәсне нигез итеп алып, бер татар газетасында мәкалә язып бастырган һәм аны академик Индус Раззак улы Таһиров бүлмәсендәге очраклы гына күрешүебез вакытында миңа тапшырган иде. Бу безнең соңгы күрешүебез булды.

Җәмәгать эшлеклесе, талантлы журналист Айрат Ибраһимов турында шунысын да әйтеп китәсем килә. Ул 1988 елда СССРда беренче татар иҗтимагый оешмаларының берсе булган «Туган тел» мәгърифәтчелек җәмгыятен нигезли һәм дәүләт органнарында терки. Аның һәм «Туган тел» җәмгыяте активистлары тырышлыгы белән «Өмет» газетасының беренче саны дөнья күрә, Ульяновск татар мәдәни үзәгенә нигез салына һәм өлкә телевидениесенең «Чишмә» программасы эфирга чыга. Ул татар мәгарифе, мәдәнияте проблемалары, шулай ук Федерация урамы, 33 нче йорттагы мәчетне җирле мөселман җәмгыятенә кайтару белән бәйле хезмәтләр яза һәм халык алдында чыгышлар ясый. Бу гамәлләрдән тыш Ульяновск шәһәрендә беренче булып «Нардуган», «Нәүрүз» бәйрәмнәрен, «Сембер җыры» конкурсларын башлап җибәрә, өлкә үзәгендә ана теле буенча беренче факультатив дәрес ача. 1997–2012 елларда Айрат Ибраһимов «Азатлык» радиосында татар-башкорт редакциясе хәбәрчесе булып та эшли. 2019 елда вафат булды, Исхак Хәлимовның туган авылы Татар Урайкиносы (Кызылсу) зиратында, хатыны Әминә ханым янәшәсендә җирләнде.

«Өмет» газетасы интернет заманында да үз беренчелеген бирергә җыенмый. Аның укучылары саны кимеми, тиражы тотрыклы. «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире Радик Сабиров үзенең сәләмләү хатында басмага менә мондый бәя бирә: ««Өмет» – Россия төбәкләрендә чыгучы иң шәп газеталарның берсе. 4 меңнән артык тираж шактый зур сан ул. Аның ничек җыелганын, аның ничек килгәнен мөхәррирләр һәм шушы газетада эшләүчеләр үзләре генә белә. Газетага ярдәм күрсәтүчеләргә рәхмәт. Газетага язылалар. Эчтәлеге начар булса, язылмаслар иде. Газетада, димәк, сыйфатлы, укырлык язмалар бар. Социаль челтәрләрдә актив эшлиләр».

Татарстан Республикасыннан читтә татар телендә газета чыгара башлау авыр булса, аның тиражын саклау икеләтә авыр. Ульяновск өлкәсендә чыгучы «Өмет» газетасы чыга башлавының беренче елларда ун мең тираж белән нәшер ителсә, 2025 елның башына тираж 4 мең данәдән артыграк булуга сөенәбез. Өлкәдә якынча 150 530 татар яши. Димәк, 60–70 татар гаиләсенә чама белән бер «Өмет» газетасы туры килә.

2022 елның 21 декабрендә Ульяновск өлкәсе губернаторының эчке сәясәт буенча урынбасары А.М. Коробко губерна администрациясе, Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе һәм Ульяновск өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте, «Сембер» татар эшмәкәрләре клубы һәм татар җәмәгатьчелеге вәкилләре, «Өмет» редакциясе хезмәткәрләре катнашында уздырылган киңәшмәдә газетаның киң кырлы эшчәнлеген түбәндәге сүзләр белән билгеләп үтә: ««Өмет» – сыйфатлы, бай эчтәлекле, абруйлы газета. Ул өлкә губернаторы эшчәнлеген дә киң һәм оста итеп яктырта. Интернет, социаль челтәрләр тормышыбызга ныклап үтеп керсә дә, басма матбугат, газеталар озак яшәячәк әле. Шул исәптән, «Өмет»тә яшәргә тиеш. Ә моның өчен, барлык резервларны эшкә җигеп, бөтен мөмкинлекләрне кулланып, газетабызның тиражын, ягъни укучылары санын кимендә ике тапкыр арттырырга кирәк». Шул ук вакытта А.М. Коробко тарафыннан өлкәдә эшләп килүче барлык мәдәният йортлары һәм клублар, китапханәләр, музейлар, дәвалау учреждениеләре, белем һәм тәрбия бирү оешмалары, шифаханәләр һәм кунакханәләр милли телләрдәге басмаларны, шул исәптән «Өмет»не дә яздырып алырга тиеш дигән таләп куела.

Тираж мәсьәләсе «Өмет»нең баш мөхәррирен дә күптәннән борчый. Ул билгеләп үткәнчә, бүген милли матбугатта тиражлар кимү иң авыр мәсьәлә булып тора. Исхак Хәлимов моны Татарстаннан читтәге төбәкләрдә яшәүче татарларның туган теле мәсьәләсе белән бәйләп аңлата. Ульяновск өлкәсендә дә татар телен фән буларак өйрәтә торган мәктәпләр елдан-ел кими бара. Мәсәлән, Ульяновскида, Димитровградта

берничә татар мәктәбе бар. Әмма калган уку йортларында татар телен укыту факультатив дәресләрдә, түгәрәкләрдә генә калган. Баш мөхәррир фикеренчә, «туган телләрен факультатив рәвешендә генә өйрәнгән балаларның киләчәктә милли тормышыбыз белән кызыксынып, татарча газета-журналлар укып, татар телендә радио тыңлап, тапшырулар карап яшәүләре шикле».

Ә бит Ульяновск төбәгендә татарларының күпчелек өлеше шәһәрләрдә яши. Шәһәр халкының азы гына «Өмет» газетасына язылa. Аны күбрәк татар авылларында алдыралар. Газетаны укучыларының шактый өлешен олы яшьтәгеләр тәшкил итә, чөнки аларның күбесе мәктәпне совет чорында, авыл мәктәләрендә туган телләрне өйрәнү өчен шартлар тудырылган заманнарда тәмамлаган кешеләр. Татарча укый-язу белән беррәттән, туган телләрендә иркен сөйләшеп, татарча уйлап яшәгән буын бу. Дөрес, урта яшьтәгеләр дә азмы-күпме укый. Әмма интернет челтәрләре ятмәсенә эләккән хәзерге яшьләр татар матбугаты белән бөтенләй диярлек кызыксынмый. Бу процесс киләчәктә тагын да кискенләшәчәк. Шуңа күрә «Өмет» газетасына даими укучыларын саклап калу, яңаларын тарту елдан-ел авырлаша бара. Шул сәбәпле басманың бүгенге көнүзәк мәсьәләсе – аның әбүнәчеләрен, укучыларын саклап калу.

Газетаның матди проблемаларына килгәндә, ул менә күп еллар инде өлкә губернаторы һәм хөкүмәте канаты астында автономияле өлкә учреждениесе буларак яши һәм өлкә бюджетыннан финанслана. Чыгымнар бертигез өлешләрдә өлкә хисабына һәм әбүнәчеләрдән, рекламадан, белдерүләрдән һәм котлау язмаларыннан алынган үз акчалары хисабына ябыла. Димәк, газета редакциясе бер елга үзенең чыгымнарын каплау өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсендә күрсәтелгән сумманы төрле ысуллар белән табарга тиеш була. Чыгымның зур өлеше әбүнәчеләрдән керсә, калганы түләүле хезмәтләр ярдәмендә туплана. Түләүле хезмәтләрнең байтагы шул ук 6-7 редакция хезмәткәре тырышлыгы белән табыла, урнаштырыла. Алар газетаның һәр санын эшләү һәм бастырып чыгару өчен күпме көч, вакыт, күз нурын түгәләр. Ләкин кайбер очракларда шул хезмәткәрләрнең туган телне яшәтү, мәдәниятне үстерү, гореф-гадәтләрне халыкка кайтару буенча куйган тырышлыгы милли нигилизм белән «авыручы» хәзерге яшьләр тарафыннан инкарь ителә, бу, әлбәттә, күңелләрне төшерә торган күренеш.

Соңгы елларда «Өмет» газетасы редакциясе һәм киң җәмәгатчелек басманы халыкка таныту, аңа онлайн язылу мөмкинлеге бирүче «куар-кодлы» («QR-код») стендларны шәһәр һәм авыл мәчетләрендә, мәдәният учакларында урнаштыру буенча зур эш башкара. Телеграм-канал аркылы кызыклы яңалыкларны күзәтеп бару өчен мөмкинчелек тудырыла.

«Өмет»не газета буларак саклап калуга «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы да өлеш кертә. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, аның ярдәмендә 2012 елдан бирле газетада «Без – бергә» кушымтасы чыгып килә, ул шулай ук укучыларны җәлеп итәргә булыша. Шул рәвешле, Ульяновск өлкәсенең «Өмет» газетасы редакциясе, өлкә татар милли-мәдәни автономиясе һәм татар җәмәгатьчелеге вәкилләре Татарстан Республикасы хөкүмәте, өлкә һәм җирле хакимиятләр белән берлектә, кулга-кул тотынышып, газетага ныклы терәк булып, аны киләчәктә саклап калу өчен зур эшләр, изге гамәлләр башкаралар.

«Өмет» газетасы 35 ел дәвамында татар халкының мәгърифәтен һәм мәдәниятен үстерүгә керткән әһәмиятле өлеше өчен Ульяновск өлкәсе һәм Татарстан Республиканың дәүләт бүләкләренә лаек була. 2015 елда – «Өмет» газетасы редакциясе халыклар арасында дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгытуга, массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә керткән зур өлеше, татар мәдәниятен һәм милли традицияләрен саклап калу һәм популярлаштыру буенча нәтиҗәле эшчәнлеге өчен «Халыклар дуслыгы» медале, 1990 елда – татар милли мәдәниятен пропагандалау буенча куйган зур хезмәте өчен, Ульяновск өлкә Башкарма комитеты мәдәният идарәсенең Мактау грамотасы, 1999 елда – нәтиҗәле хезмәте һәм милли мәдәниятне үстерүгә, өлкә икътисадын тотрыкландыруга керткән зур өлеше өчен һәм газетага нигез салынуга 10 ел тулу уңаеннан Ульяновск өлкәсе хакимиятенең Мактау грамотасы, 1999 елда – татар милли мәдәниятен үстерүгә, патриотизмны, халыклар арасында дуслыкны пропагандалауга зур өлеш керткәне өчен һәм газета оешуның 10 еллыгы уңаеннан Ульяновск өлкәсе Законнар чыгару җыенының Мактау грамотасы, 2010 елда – татар телен, мәдәниятен һәм милли гореф-гадәтләрне саклап калуга һәм үстерүгә зур өлеш керткәне өчен һәм газетаның 20 еллыгы уңаеннан Ульяновск өлкәсе губернаторының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

«Өмет» газетасы шулай ук Татарстан Республикасы «Татмедиа» ААҖнең (2015, 2023), татар милли әдәбиятын үстерүгә һәм пропагандалауга керткән зур өлеше өчен Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең (2015) Рәхмәт хатлары, яшьләр чараларын яктырту буенча актив эшчәнлеге һәм татар милли спорт көрәшен үстерүгә һәм пропагандалауга керткән нәтиҗәле өлеше өчен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының Мактау грамотасы (2015), Бөтендөнья татар конгрессы дипломнары (2023, 2024) белән бүләкләнә.

«Өмет» газетасы хезмәткәрләре үз газеталарын татарлар һәм башка милләтләр арасында таныту максатыннан төрле иҗади конкурсларда катнашалар, премияләргә, мактаулы исемнәргә һәм дипломнарга лаек була-

лар. Алар Бөек Ватан сугышында җиңүнең 50 еллыгы темасын яктырту буенча өлкә конкурсының «Танылу» («Признание», 1995) һәм «Бәллүр каләм – 2010» премияләре белән бүләкләнәләр, «Милли телдәге иң яхшы басма» номинациясендә өлкә иҗат (2009, 2010) һәм «Матбугатның алтын фонды – 2015» Бөтенроссия (2015) конкурсларында җиңүгә ирешәләр, Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм БДБ илләрендә нәшер ителә торган татар газеталары арасында 2 нче Бөтенроссия конкурсында лауреат исеменә (2010), һәм «Сембер китабы» еллык өлкә күргәзмә-конкурсында катнашучы сертификатларына (2016, 2017, 2018, 2019) ия булалар.

Журналистика өлкәсендәге күпкырлы хезмәтләре һәм газета үсешенә керткән өлешләре өчен газетаның 15 хезмәткәре һәм актив авторлары: Г.Ш. Сәгыйров, Р.Х. Шәфигуллин, Ш.Ф. Сәлахова, А.И. Ибраһимов, Р.Ә. Хисмәтов, Л.Б. Сабитова (Иделбикә), М.Җ. Рамазанов, Н.К. Шагаева, Г.Х. Хәйретдинова, М.К. Саюков һ.б. Сәхаб Урайский исемендәге әдәби премия белән бүләкләнә.

Югарыда китерелгән бүләкләр татар телендә чыгып килүче «Өмет» газетасының әһәмияте һәм аның Ульяновск өлкәсе һәм Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә танылуы турында сөйли.

Басма әбүнәчеләренә хыянәт итмәде, ул милли үзаңны үяту, татар халкында милли горурлык хисе, башка милләт вәкилләренә карата ихтирам, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү, дин һәм кан кардәшләребезнең милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү юлында армый-талмый эшләде, милләттәшләребезне борчыган социаль-икътисади мәсьәләләрне хәл итүгә этәргеч бирде. Газиз ана телебезнең хокукын яклау, дәрәҗәсен күтәрү, кулланылыш даирәсен киңәйтүгә, милли мәдәниятебез, традицион бәйрәмнәребез һәм гореф-гадәтләребезне саклау һәм үстерүгә зур өлеш кертте. Бу еллар эчендә «Өмет» газетасы татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер учагына гына түгел, ә үзенчәлекле милли һәм социаль-мәдәни мәнфәгатьләр клубына да әверелде. Менә шуңа күрә Ульяновск өлкәсе татарларының йөзек кашы булган «Өмет» газетасының киләчәге бүген өметле дә инде. Ул киләчәктә тагы да текәрәк үрләр яулар дип ышаныйк.

ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАРАГАН ХЕЗМӘТЛӘР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ. РЕЦЕНЗИЯЛӘР

ИНФОРМАЦИЯ О КРАЕВЕДЧЕСКИХ ТРУДАХ. РЕЦЕНЗИИ

ЯҢА КИТАП



Ф. Әхмәтшин. **Монда бөек тарих үзе яшәгән.**

Ике китапны берләштергән бу хезмәттә берничә татар авылы – Мишә тамагы (Япанча), Байчуга һәм Чулпан турында тирән, күпьяклы тарихи мәгълүмат тупланган. Аның авторы төрле архивларда эшләгән, басылган хезмәтләрдән файдаланып үзенең туган яклары турында гүзәл бер тарихи әсәр иҗат иткән. Бу китаплар алдагы буыннарыбызга да, хәзерге заман төбәк тарихы белән кызыксынучылар өчен дә әһәмиятле булачак.

Торопицын И.В. **Военная служба астраханских юртовских татар (вторая половина XVI – первая четверть XVIII вв.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2025. – 332 с.; 12 с. ил.**



Монография посвящена малоизученному аспекту служебной деятельности астраханских юртовских татар, связанному с их участием в различных военных кампаниях, которые вело Московское государство во второй половине XVI – первой четверти XVIII в. В книге рассматриваются военный потенциал тюркского населения Нижнего Поволжья, особенности использования царскими воеводами данного контингента в походах и войнах, характер вознаграждения юртовцев за службу и другие аспекты, связанные с военной деятельностью.

Издание адресовано историкам, краеведам, этнографам, всем тем, кто интересуется военной историей и жизнью тюркского населения Нижнего Поволжья.

ЮБИЛЯРЛАР ТУРЫНДА СҮЗ

СЛОВО О ЮБИЛЯРАХ

Фәнүзә Нуриева, Энҗе Кадирова

ИСКЕ ТАТАР БИСТӘСЕННӘН ЧЫКТЫМ ЮЛГА...

Профессор Фәрид Хәкимҗановка 80 яшь тулу уңаеннан

Казан шәһәрендәге Татарстан урамы буенча елга портына таба хәрәкәт иткәндә, һичшиксез, Иске Татар бистәсе аркылы үтми мөмкин түгел. Галим-тюрколог, филология фәннәре докторы, профессор Фәрид Хәкимҗанов 1945 елда нәкъ менә Иске Татар бистәсе белән Яңа Татар бистәсе арасындагы Кырый урамда (1960 нчы елларда бу урам бетерелде) туган. Татарлар гына яшәгән бу урамда милли мохит эчендә кайнаган-бөтерелгән үсмер, 7 яшен тутырып, Й. Сталин исемендәге 2 нче номерлы ир-егетләр татар (соңрак ул 12 нче номерлыга үзгәрә, хәзерге көндә – яһүдиләр уку йорты) мәктәбенә укырга керә. Мәктәпләрне кызлар өчен, егетләр өчен дип, аеру бетерелгәч, иптәшләре Таһир Якупов (соңрак – танылган

җырчы), Фердинант Гыймадиев (соңрак – биюче, Татарстанның халык артисты) һәм Рөстәм Сафиуллин (хәзерге көндә – Казанның «Рәфыйк» мәчете имамы) белән якындагы, Ш. Камал исемен йөрткән 80 нче номерлы база татар мәктәбенә күчерелә. Гадәттә мәктәптә белем алу чоры кешенең белемгә, зиһенгә баету чагы гына түгел, аның киләчәк яшәешенә сукмак салу вакыты буларак та күзаллана.

Фәрид тә биредә баш-аягы белән мәктәп тормышында кайный башлый: пионер оешмасын җитәкли, Пионер комбинатының башлыгы була, бию түгәрәгенә йөри, курай-кубызчылар оркестрында уйный, спорт залы булмаган мәктәпнең баскетбол һәм футбол командаларын оештырып, районда һәм шәһәр күләмендә алдынгы урыннарны яулыйлар (бу вакытта инде ул «Спартак» җәмгыяте футболчысы һәм хоккейчысы буларак исем казанган булса, инде баскеболчы буларак, Татарстанның «Хезмәт резервлары» җыелма командасында уйнавы белән танылa). Болар барысы да оештыру эшенең нечкәлекләрен, кешеләр белән мөгамәлә кору үзенчәлекләрен, кимчелеләреңнән арына белү кирәклеген холкыңа дус итү, үз фикереңне тормышка ашыра белү кебек мөһим сыйфатларны үзләштерергә ярдәм иткәндер, күрәсең. Биредә аның киләчәк тормыш юлын сайларга этәргән бер вакыйгага тукталмыйча мөмкин күнел. Патша заманында Казан Император университетында яхшы гына эшләп килгән Шәркыять бүлегенең бөтен мал-мөлкәте, укытучы-профессорлары белән Санкт-Петербургка күчерелүе Казанны ярлыландырып калдырган иде. Шушы бушлыкны ничек тә бетерү кирәклеге, Казан дәүләт университетында Шәрык телләре факультеты ачу теләге белән янган Татарстан мәгариф министры, танылган гарәп теле белгече, ЮНЕСКО әгъзасы, профессор Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов, бу олуг эшкә әзерләнеп тору хаҗәтеннән, аякка алдан киеп тору зарур дип, 80 нче мәктәп укучыларыннан берничә кешене сайлап алган һәм аларга гарәпчә өйрәтә башлаган. Өйрәтә алырлык кеше дә, укыту әсбаплары да таба алмагач, үзе килеп, аерым дәресләр үткәргән.

11 нче сыйныфны тәмамлагач (моңарчы яшәгән 10 сыйныфлык белем бирү системасына тагын бер сыйныф һәм яңа фән – җәмгыятьне өйрәнү фәне өстәлә; укыту программасын әвеш-тәвеш китерүне, яңа фән укытырлык кеше таба алмауны әйтеп тә торасы юк), Фәрид «Хезмәт резервлары» системасында яшьләр арасында баскетбол буенча СССР беренчелегендә катнашу өчен, Россия җыелма командасына, Орел шәһәренә чакырылган була. Әти-әниләреннән «Сине мәгариф министрлыгына чакырып хат килде» дигән телеграмманы алу белән, Казанга кайта да министрлыкка китә. Шәрык факультеты ачу тоткарлануы, хәзергә вакытлыча университетның Татар теле һәм әдәбияты бүлегенә кереп, укый башларга кирәкле-

ге хакында тәкъдим ала. Шулай итеп, барлык имтиханнарны да «бишле» билгесенә генә тапшырып (шул исәптән, чит тел сыйфатында гарәп телен дә), Казан дәүләт университеты студенты булып китә. Мәктәптә табигать фәннәре белән кызыксынган, алардан гел югары билгеләргә генә укып килгән укучының гуманитар фәннәр өлкәсенә аяк басуы күпләрдә гаҗәпсенү хисе уята, билгеле. Ул гына да түгел, яңа законнардагы, эш стажы булмаган кеше, семестр сынауларына катнашу хокукын югалтмыйча, 1 ел эшләргә тиеш дигән үзгәрешкә буйсынып, беренче уку елын үзе яңа гына тәмамлаган мәктәптә физика кабинеты лаборанты булып эшли. Әмма тормыш сикәлтәләре моның белән генә бетми: 2 нче курс башында ук аны армиягә алып (университетның үз хәрби кафедрасасы булса да), ерак Венгриягә 3 еллык хәрби хезмәткә җибәрәләр. Анда гвардия артиллерия полкының батарея өлкән хисапчысы итеп билгеләнгән егеткә математика, география, топография, картография кебек фәннәр белән яңадан очрашырга туры килә. Ул үзешчән сәнгатьтә катнаша, дивизиянең футбол буенча җыелма командасында уйный, җирле маҗар командасы уенчы сыйфатында баскетбол буенча ярышларда катнаша. Исеме полкның Мактау китабына кертелгән, портреты Дан аллеясына куелган Фәрид, 3 еллык хәрби хезмәтен тәмамлап, офицер погоннарын тагып, университетка I семестр сынауларына гына кайтып өлгерә. Монда да уку программасын үзләштерү белән генә чикләнмичә, университет тарихында беренче мәртәбә тарих-филология факультетында команда оештырып, туристлар фестивалендә катнашалар һәм III призлы урынны яулыйлар (4 кеше аерым төрләрдә чемпион була). Шулай ук беренче мәртәбә оештырылган баскетбол командасы университет беренчелеге ярышларында катнаша.

III курста укыган чагында, укуына зыян китермичә генә, ул «Татарстан яшьләре» газетасы белән хезмәттәшлек итә башлый. Укуын тәмамлагач та, газетада эшләвен дәвам итә һәм кыска вакыт арасында бүлек мөдире дәрәҗәсенә үсеп җитә.

1972 елның ахыры аның тормышына яңа бер үзгәреш китерә – Фәрид Сабирҗан улы СССР Фәннәр академиясенең Тел белеме институтына аспирант булып кабул ителә. Документлары угыр-фин телләре бүлегенә кабул ителсә дә, үзара аңлашып («Казаннан Тел белеме институтына беренче мәртәбә татар егете килгән, ул да булса угыр-фин телләре бүлегенә – моны табигый хәл дип санап булмый», ягъни), тюркология һәм монгол телләре мөдире Әдһәм Рәхим улы Тенишев аны үз бүлегенә күчертүгә ирешә. Аңа Идел-Урал өлкәсе өчен генә түгел, гомуми тюркология өчен дә мөһим һәм шул ук вакытта гаять четерекле булган теманы бирәләр. Ул да булса – Урта гасыр Идел болгарларыннан калган кабер ташларындагы язуларны укып, анализ ясау темасы. Фәнни

җитәкчесенең (ә бу вазыйфаны дөньякүләм танылган галим үз өстенә ала) фатирында эш планы хакында сөйләшеп утырганда, төп юнәлешләрне билгелиләр: тарихка бәйләнешле архивларларда эзләнергә, чагыштарма-тарихи лингвистик анализ методикасын өйрәнергә, борынгы язмаларның телен тикшергән хезмәтләр белән танышырга һәм, бәлки, иң мөһимедер, экспедицияләргә чыгып яңа ташъязмалар эзләргә. «Нинди булса да соравың туамы, берәр ярдәм кирәк буламы – уңайсызланып торма, туп-туры фатирга кил», дип фатыйхасын бирә галим. Шулай итеп, Фәрид Сабирҗан улының күпләр гранит ташын кимерү белән тиңли торган фән (безнең очракта, тюркология) дөньясына адым атлауы башлана. Без монда ике вакыйгага гына тукталып үтмәкче булабыз. Аның беренчесе – 1722 елда шәһри Болгарны зиярәт иткәндә, Рәсәй патшасы Петр I нең әмере белән күчереп алынган 50 ташъязманың текстлары табылу һәм аның фотокопиясен үз кулында булдыру; ә икенчесе – моңа кадәр билгеле булган болгар каберташъязмаларының саны ике дистәгә дә тулмаган булса, хәзер галимнең шәхси архивында аларның саны йөздән артып китә. Ташъязмалар текстларында кулланылган сүзләр саны аз булуын, күбрәк саннар очравын искә алсак, бу сүзләрнең саны бермә-бер арткан дигән сүз. Гарәп хәрефләре белән төрки тел сүзләрен язганда очраган үзенчәлекләргә дикъать итеп, галим кайбер сузык авазларны төгәлрәк күрсәтү өчен, 2–3 хәреф һәм өстәмә билгеләр (хәрәкәләр) кулланылганлыгын ачыклый. Бу исә текстларны язуда файдаланылган телнең авазлар системасын билгеләргә мөмкинлек бирә. Текстларның башка үзенчәлекләрен дә тикшереп, ул кабер ташъязмалары текстларын язганда, 3 төрле тел кулланылган дигән нәтиҗәгә килә, болар – гарәп теле (рәсми дин теле), дәүләтнең әдәби (рәсми) теле һәм халыкның сөйләм теле (хатирә буларак сакланып калган дәрәҗәдә).

Нәтиҗәдә, Идел Болгарстаны дәүләтендә XIII–XIV йөзләрдә куелган кабер ташъязмалар текстларын төрле яктан анализлап, Фәрид Сабирҗан улы 1976 елда Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең Тел белеме институты актлар залында «төрки телләр» белгечлеге буенча «Идел Болгарстаны язма истәлекләре теле (XIII–XIV гасырлар эпитафияләре материалында)» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. Диссертантның бернинди язуларга да карамыйча, фәнни хезмәтенең эчтәлеге белән таныштыруы, рәсми бәяләүчеләргә һәм сорау бирүчеләргә, кара тактага мисаллар язып, төпле итеп фикерен аңлатуы, фәнни бәхәстән читенсенмәве комиссия әгъзаларында да, залда утыручыларда да уңай фикер тудыра. Хәтта бу диссертацияне СССР Фәннәр академиясенең «Фән» нәшриятында бастырып чыгарырга кирәк дигән тәкъдим дә яңгырый.

Рәсми эш урыны мәсьәләсендә кайбер тәкъдимнәр булса да, Фәрид Сабирҗан улы туган җире Казанда, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына караган Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече фәнни хезмәткәр булып эшли башлый.

1978 нче елда галимнең «Язык эпитафий волжских булгар» дигән беренче китабы «Наука» нәшриятында басылып та чыга. Бу китабында галим урта гасыр Идел болгарларыннан сакланып калган каберташ язмаларның телен системалы рәвештә тикшереп чыга, аның үзенчәлекләрен ачыклый. Ул язмаларның аваз системасы үзенчәлекләрен язма телнең корылышы, башкарган вазыйфасын тик бәйләнеш җәһәтеннән дә тасвирлый. Төрки тел сүзен башка системадагы чит тел хәрефләре белән тапшырган вакытта килеп туган үзгәрешләргә дикъкать биреп, яңача укылышлар да тәкъдим итә. Язмаларны лингвистик кенә түгел, филологик һәм тарихи яктан да тикшереп чыгу Идел болгарлары тарихы белән кызыксынган галимнәр өчен саллы гына эзләнү хезмәте булып тора.

Бу вакытта СССР Фәннәр кадемиясе карамагында Тюркологларның совет комитеты әгъзалыгына кабул ителгән галим (акад. А.Н. Кононов җитәкчелегендә 50 кешедән оешкан бу оешма Советлар Союзындагы тюркология өлкәсендәге фәнни тикшеренү-эзләнүләрне җайлау һәм юлга салу белән шөгыльләнә) 1987 елда шул ук нәшриятта «Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык» дигән яңа китабын бастырып чыгара. Биредә галим урта гасырларда Идел Болгарстанында тел торышы, вазыйфа башкарган телләрнең кулланылышлары турындагы фикерләрен дәлилли. Аның Һ.В. Йосыповның «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику» (Юсупов, 1961) китабы белән янәшә куелган бу хезмәтләре дөнья тюркологиясендә танылып, «Идел-болгар эпиграфикасының бердәнбер белгече» исемен алырга [Алишина: 2006] һәм кайбер галимнәр өчен ышанычлы нигез булып торырга ярдәм иткән [к.: T. Tekin; 1988; M. Erdal: 1993].

Ф.С. Хәкимҗанов Идел болгарлары эпитафикасын өйрәнү, урта гасыр шартларында телләрнең вазыйфа башкару мөмкинлекләрен тәгаенләү, татар теле тарихы мәсьәләрен тикшерү белән генә чикләнми, «Языки мира. Тюркские языки» (Мәскәү, 1997; Бишкек, 1997), «Большой энциклопедический словарь. Языкознание» (Мәскәү, 1998), «Төрки дөьясының грамматик терминнар сүзлеге» (Анкара, 1997) кебек академик хезмәтләрне нәшер итүдә дә катнаша.

Фәрид Сабирҗан улы үзе үзләштергән белемнәр кысасында гына калмый, күп кенә Халыкара, Бөтенсоюз (Бөтенроссия) тюркологик съездларында, конференцияләрендә катнаша, фикерләре белән уртаклаша. Ул та-

тар галимәрннән беренчесе буларак, 1996 елда Парижда үткәрелгән XIV «Дөнья телләре, мәдәният һәм сәяхәтчелек» Халыкара ярминкәсендә Татарстан экспозициясе белән катнашып, бәхәс клубында «Татар теленең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге» дигән доклад белән чыгыш ясый.

1990 елда Татарстанның Министрлар Кабинеты карары белән татар энциклопедиясен әзерләү максатыннан, Татар совет энциклопедиясенең Баш Редколлегиясе корыла һәм күпкырлы эшчәнлеккә ия булган Фәрид Сабирҗан улы аның Җаваплы сәркатибе итеп билгеләнә – бу юнәлештә эшли алырдай сәләтле белгечләрдән аерым бүлек туплап, эшкә башлау да аңа йөкләнелә. Ул Төркия Җөмһүрияте хөкүмәте тарафыннан Анкара университеты профессоры итеп чакырылганчы, өч ел буена шушы эш белән шөгыльләнә.

1992 елда докторлык диссертациясен яклаган галим, Төркиянең төп университеты саналган Анкара университетында татар теле һәм әдәбиятын укытуны тагын бер тормыш сынавы итеп кабул итә. Чит илдә эшләү еллары башка милләт кешеләренә телне өйрәтү үзенчәлекләренә ныграк төшенергә, аның методикасын үзләштерергә ярдәм итә. Ул биредә чит ил студентлары өчен берничә уку әсбабы, русча-татарча-төрекчә сөйләүлек тә бастырып чыгара. Шушы ук вакытта ул 2 ел буена Татарстан мәгариф министры урынбасары вазыйфасын да башкара, Төркиядә белем алган Татарстан яшьләренең теге яки бу четерекле мәсьәләләрен хәл итү өчен, Төркия президенты һәм милли мәгариф оешмалары җитәкчеләре белән очраша. Берничә мәртәбә Төркия ватандашлыгын кабул итәргә тәкъдимнәр булса да, ул туган иленә кайта, яңа ачылган Татар дәүләт гуманитар институтында тел белеме кафедрасын оештыра. Институт 2005 елда ябылганчыга кадәр яшьләргә сыйфатлы итеп югары белем бирүдә, яшь галимнәрнең гыйльми әзерлекләрен күтәрү, аларның хезмәтләрен бастырып чыгаруда (бу вакытта ул Институтның «Гыйльми язмалар» мәҗмугасын, Gumantarya нәшриятын җитәкли, фәнни конференцияләр оештыра, моннан тыш, Татар тюркология мәркәзе башлыгы итеп сайлана, «Туран» гыйльми-мәдәни үзәгенең тюркология бүлеге җитәкчесе хезмәтләрен дә башкара; «Milli mədəniət» журналын чыгара башлый) үзе туплаган белемнәрен кызганмыйча, барлык көчен биреп эшли. Аның фәнни эшчәнлеген югары бәяләп һәм фәнни-оештыру хезмәтләрен искә алып, Татарстан хөкүмәте аңа «Татарстан Республикасының атказанган фән эшеклесе» дигән мактаулы исемне бирә.

Билгеле булганча, Татар гуманитар институты нигезендә Татар милли университеты оешырга мөмкин дип йөргәндә, Институтны ябып, ишеген ныклап бикләп куялар, ә студентларны Татар педагогия институтына күчереп, аның исемен Татар дәүләт гуманитар-педагогия институты дип

үзгәртәләр (билгеле, Гуманитар институт өчен Болак күпере янында салынган бина белән аңа тапшырылган «Татэнерго» ширкәтенең иске бинасы да шул вакытта тапшырыла). Яңа уку йортында нәшрият оештыру эше белән шөгыльләнгән Фәрид Сабирҗан улы, нәшрият уставы расланып, кирәкле документлар алынгач, ниндидер эчке каршылыклар килеп чыга, – нәтиҗәдә, ректор аңа татар теле кафедрасында эшләргә тәкъдим ясый. Студентларга «Татар теле тарихы»н һәм махсус курслар укыган галим биредә «Тенишев укулары» дигән махсус фәнни мәҗлесләр үткәрә башлый, журнал һәм фәнни җыентыклар чыгаруын дәвам итә. Ә инде 2014 нче елда, моңа кадәр Төркиядә, берничә ел чакырылып, кунак-профессор буларак, лекцияләр укыган галим, штат кыскартылу сәбәбеннән эштән киткәч, шунда ук Төркиянең Коҗатәпә университетыннан, штатка алынып, эшкә чакыру килә. Шулай итеп, галим икенче мәртәбә Төркия туфрагына аяк басып, университет штатында белем бирә башлый. Хәзер инде ул татар теле белән генә бәйле фәннәрдән тыш, татар фольклоры һәм әдәбияты тарихы, гомуми тел белеме, тюркологиягә кереш, алтаистика кебек фәннәрдән дә лекцияләр укый. Ел саен 15–20 диплом эше яздырган хөрмәтле профессор фактик материал буларак татар әдәбиятыннан җыелган үрнәк җөмләләрне туплап, төрле төр сүзлекләр өчен чимал җыйный. Һәм менә кире Казанга кайткач, «Татар теленең фразеологик сүзлеге»нең I томы кебек 672 битлек саллы хезмәтнең дөнья күрүе татар фәне өчен бәрәкәтле бүләк булып тора. Ишетүебезгә күрә, галимнең кульязма хәлендә тагын берничә сүзлеге бар икән.

Хөрмәтле профессорыбыз, мәсләктәшебез Фәрид Сабирҗан улына имәндәй саулыклар теләп, күңел түрендә саклаган уй-теләкләренең тормышка ашуын телибез!

Файдаланылган әдәбият

1. Алишина Х.Ч. Единственный специалист по волжско-булгарским письменам // Языковые уровни и их анализ (на материале языков разных систем–2005. Ежегодник / отв. ред. Ф.С. Хакимзянов. – Казань: Gumanitarya, 2006. С. 11–14.
2. Нуриева Ф.Ш., Кадирова Э.Х. О нашем профессоре, учителе и коллеге // Международный тюркологический журнал «Türkoloji Üzerine Araştımalar-Исследования по тюркологии». – Afyonkarahisar-Kazan, 2015, № 11 (Özel sayı), S. 5–41.
3. Хакимзянов Ф.С. Булгарский язык // Лингвистический энциклопедический словарь / гл. ред. В.Н. Ярцева. – М.: «Советская энциклопедия»,1990. С. 77.; 2-ое доп. изд. – М.: Научное ид-во «Большая Рос. энциклопедия», 2002. С. 77.

4. Хакимзянов Ф.С. Булгарский язык // Языки мира. Тюркские языки / отв. ред. Э.Р. Тенишев. – М.: «Инлрик», 1996. С. 47–52.
5. Хакимзянов Ф.С. Булгарский язык // Языки мира. Тюркские языки / отв. ред. Э.Р. Тенишев. – Бишкек: Изд. Дом «Кыргызстан», 1997. С. 47–52.
6. Хакимзянов Ф.С Булгарский язык // Большой энциклопедический словарь Языкознание / гл. ред. В.Н. Ярцева. – М.: Научное ид-во «Большая Рос. энциклопедия», 1998. С. 77.
7. Хакимзянов Фарид Сабирзянович. Биобиблиографический указатель / сост. Д.Ф. Хакимзянова. – Казань: Gumanitarya 2013. – 44 с.
8. Erdal M. Die Shprache der wolgabolgarischen Inschriften. – Wiesbaden: Harrassowitz. 1993. – 172 s.
9. Tekin T. Volga Bulgar Kitabeleri ve Volga Bulgarcası. – Ankara, 1988.
10. Türk Dünyası Gramer Kılavuzu Sözlüğü / haz. E.Gürsoy-Naskalı. – Ankata: TDK Yayınları 667, 1997 – 190 s. (төз.-авторларның берсе).

Редакциябез дә Фәрид дусны чын күңелдән олуг юбилее белән котлап кала!

Тәэминә апа Биктимирова юбилее уңаеннан әңгәмә

ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ

Солтан Исхаков фотосы

Мин, 1940 елның 6 октябрендә Әтнә районы Яңа Шимбер авылында туганмын. Туган көнемне метрика кәгазенә никтер 12 се дип язганнар. Әти – Сәфәров Әхмәт – 1933 елдан колхоз рәисе, әнием Сәфәрова Шәрифә (мулла кушкан исеме Шәфифә) – колхозчы. Әти 1941 елның июлендә Бөек Ватан сугышына китә. 1947 елда фронттан кайткач безнең белән яшәмәде. Без өч бала, әтинең әнисе Вәрига әбием, әни тәрбиясендә калдык.

1937 елда туган Гөлсәгыйдә апам өч ел буе авырып урын өстендә ятты. Ниһаять 1946/47 уку елында мәктәпкә йөри алыр хәлгә килде. Ул бик куанып авылыбызның мәктәбенә укырга йөри башлады. Минем дә

аннан каласым килмәде, мәктәпкә бардым. Укытучы Әтнә районы Күшәр авылы кызы Гыйлемханова Кәүсәрия ападан «мине дә укыт әле», дип сорагач, «балакай, синең яшең җитми, кит әле» диде. Әмма укытучы апаны яратуым сәбәп булды бугай, мин апама ияреп һәр көн мәктәпкә йөри идем. 1947 елның 28 февралендә, ниһаять мин 1 нче сыйныф укучысы булдым. «Ничек икенче елга калдырыйм, укый ала ул, 2 нче сыйныфка күчерәм» – дигән Кәүсәрия апа әниемә. Укырга кергәнче хәрефләрне таный идем инде. Беренче укытучым белән бер елдан ук аерылыштык, тик гомерем буе аны сагынып яшәдем, урыны оҗмахта булсын, чын педагог иде.

Авылыбызда мәктәп башлангыч кына, 7 еллык мәктәпне Түбән Көектә, 10 еллыкны Күлле Кимедә тәмамладым. 7 сыйныфны бетергәч, бер ел укудан аерылып тордым. Чөнки Киме мәктәбе бездән 8 чакырым ераклыкта урнашкан. Сугыштан соңгы авыр еллар, өс-баш начар, икенчедән, укыр өчен акча түләргә кирәк. Укудан аерылуымны бик авыр кичердем. Әниемә дә минем хәсрәтем начар тәэсир итте ахры, икенче уку елы җиткәч үзе үк «бар балам укы, ничек тә йөрерсең әле Алла боерса» – диде.

Бәхетемә, Киме мәктәбендә директор булып Түбән Көектә безне укыткан Мотыйк абый Кушаев эшли башлады. Интернатта торыр урын биреп, укыр өчен түләүне дә җиңеләйтеп ярдәм итте укытучым. Гомерем буе бу яхшылыкны кайтара алмаганмындыр кебек тоела, шуңа борчылган вакытларым була.

Аллага шөкер, олы җанлы укытучыларыбыз бар иде. Түбән Көек мәктәбендә Галәветдинов Һидият, Сабиров Наил, Шәрәфиев Хәмбәл, Заһидуллина Маһинур, Фазылҗанова Миңшәрәф (Түбән Көектән соң Киме мәктәбендә дә татар теленнән укытты), Хәмитов Габдрахман (мәктәп директоры иде, кызганыч, «халык дошманы» баласы дип утырттылар), һ.б. Авыр елларда алар эшләделәр безнең белән.

Күлле Кимедә укыганда балалар йортында тәрбияләнүчеләр белән бергә укыдык. И-и, алардагы матур өс-баш, аякларында ботинка, өстеннән резина галош... Форма күлмәкләре, алъяпкычлар без күргән нәрсәләр түгел инде. Кызыгып, көнләшеп карый идек аларга, яшермим. Укытучыларыбыз безнең карашны сизеп: «Көнләшмәгез балалар, аларның беркемнәре дә юк, сезнең әниләрегез исән, Аллага шөкер» – дип юаталар иде.

10 сыйныфта татар теленнән укыткан Әлфинур апа «үтенәм, зинһар чабатагызны мәктәпкә генә киеп кермәгез» дип тилмерә иде. Шимбә көн дәресләр беткәч, интернатка кереп тормыйча, авылга чабата киеп йөгерә идек шул.

1958 елда Казанга килеп бик авырлык белән «Казтранстрой» трестының «СМП-203» дигән төзелеш оешмасына эшкә урнаштым. Йөк ташучы, штукатур, маляр булып эшләдем. Егылып, умыртка сөягемне сындырдым һәм 1961 елда Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетына укырга кердем. Хыялым татар теле һәм әдәбияты укытучысы булу иде. Кызгангыч, әдәбият укытучысы була алмадым. 5-курста Казан егете Биктимеров Нариманга кияүгә чыктым. Казанда татар мәктәпләрен бетергән чор иде бу.

Көч-хәл белән Казан авиация институтының фәнни китапханәсенә эшкә урнаша алдым. 1967 елның апрелендә улыбыз Айрат туды. 1969 елның мартында институтның КПСС тарихы кафедрасында өлкән лаборант вазифасын башкара башладым. Бер үк вакытта кандидатлык имтиханнарына хәзерләнеп, аларны уңышлы тапшырдым. Кичке бүлектә семинар занятиеләре дә алып бара идем. 1974 елдан рәсми рәвештә ассистент, 1985 елдан өлкән укытучы булдым. Кафедраны тарих фәннәре докторы, профессор Якуб ага Шәрәпов җитәкли иде. Аңа да гомерем буе рәхмәт укыйм. Курыкмады, алды бит эшкә. Я. Шәрәпов – ТАССРның һәм РФнең атказанган фән эшлеклесе иде.

Институтта эшләгәндә 1976 елда Ростов-Дон, 1982 елда – Свердловск, 1989 елда – Минск шәһәрләре университетларында 6 шар айлык квалификация күтәрү курсларында укыдым. Курсларда уку мәҗбүри иде.

1982 елда «Деятельность партийных организаций Среднего Поволжья по вовлечению женщин в социалистическое строительство (1920–1926)» дигән темага кандидатлык диссертациясе якладым. Тарих фәннәре кандидаты дигән дәрәҗәм бар. Институтның профсоюз комитеты, 3 факультетның партбюро әгъзасы булып сайландым. «Белем» җәмгыяте буенча халыкка лекцияләр укыдым.

Институтта эшләгән вакытымны иң бәхетле елларым дип саныйм. Эш җиңел түгел иде, билгеле. Ул вакытта КАИ иң данлыклы институт, конкурс бер урынга 17 шәр кеше. Илнең бөтен почмакларыннан студентлар шул конкурсны үтеп керәләр. Партия тарихын укыту бик җаваплы эш санала. Күп укырга, күп белергә кирәк иде. Тырыштым, Аллага шөкер, татар кызы, авыл кызы булуым ярдәм иткәндер, кешедән ким булмаска тырыштым дип әйтә алам. Укыту рус телендә иде инде, анысы да үти алмаслык булмаган икән. Өйрәндек рус телен дә, рустан ким белмәдек дип әйтә алам, мактану булмасын.

Ни кызганыч, без яшәгән, без ияләнгән социалистик җәмгыять җимерелде. Институтта партия тарихы укыту туктатылды. «Ватан тарихы»н укытырга теләмәдем. 1993 елның мартында Бөтендөнья татар Конгрессы башкарма комитетына эшкә күчтем. Бу – милли күтәрелеш чоры иде.

Конгресста эшләсәм, туган халкыма күбрәк файда китерермен кебек тоелды. Күчкәнемә беркайчан да үкенмәдем, башта референт, соңрак бүлек мөдире булып эшләдем. 1992 елда Конгресс башкарма комитеты каршында төзелгән «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасына сайландым һәм аның рәисе урынбасары вазифасын башкардым. 1997 елның октябрендә Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих инситутында эшли башладым. Конгресста иҗат белән шөгыльләнергә мөмкинлек юк иде. Институтта башланган фәнни эш үзенә чакырып торган кебек, гел тарта иде. Эшемнән, институттагы атмосферадан канәгать булып эшләдем. Безнең бүлек «Татар мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге» дип атала иде. Бүлекне философия фәннәре докторы, директор урынбасары Фәрит Мирза улы Солтанов үзе җитәкләде. Мин 2013 елга кадәр өлкән фәнни хезмәткәр булып эшләп, пенсиягә чыктым.

Безнең бүлек «Татар педагогик фикере антологиясе» өстендә эшләде. Борынгы төрки чордан алып бүгенге көнгә кадәр татар халкында педагогик фикер үсешен чагылдырган бик әһәмиятле хезмәт бу. Китапта күренекле педагоглар һәм методистларның хезмәтләреннән өзекләр һәм алар турында кыскача биографик мәгълүматлар бирелә.

Институтта эшләгән чорда басылып чыккан китапларым:

Минем шәҗәрәм. – Казан: Мәгариф, 1999.

Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. – Казан: Печатный двор, 2002.

Ступени образования до Сорбонны. – Казан: Алма-Лит, 2003.

Ил язмышын салып иңнәренә. – Казан: Алма-Лит, 2006.

Татарстан реформалар чорында. Елъязма: 1985–2000. – Казан: Мәгариф, 2005 (тезүче автордашлар Р.Г. Хәйретдинов, Р.Ә. Бәдыйгов, К.Ф. Фәсхетдине).

Җәмәгать эшләренә катнашырга тырышам. Озак еллар Бөтентатар «Мәгариф» ассоциациясе әгъзасы булып йөрдем. Яшьләр, укучылар белән очрашуларга, мәчетләребезгә лекцияләр белән барам. 15 ел буе татар хатын-кызларының Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакяр хезмәтләре хакында «Татарстан» радиосыннан даими рәвештә чыгышлар ясадым. Хәзер дә ясыйм, тик инде сирәк.

Фәнни конференцияләрдә әле дә катнашам. Бөтендөнья татар конгрессы үткәргән чараларда да катнашырга тырышам. Сөембикә ханбикәбезнең тууына 500 ел тулу уңае белән элекке Дәүләт Советы депутаты Сүрия Усманова белән чаралар уздыруны (конференция, юбилей концерты) оештыруда башлап йөрдек. Күренекле иганәче, 1916 елда татар кызлары өчен Казанда гимназия ачкан Фатиха Аитованың музеен оештыруда башлап йөрдем. Музей №12 кызлар гимназиясендә ачылды.

Мин – Хезмәт ветераны. ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2002 елдан). Сөембикә беләзеге лауреаты (2007), «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» (2005) һәм «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләр өчен» (2010) медальләре иясе.

1975 елдан 1991 елга кадәр Коммунистлар партиясе әгъзасы булып тордым. Партиядә тору эшем белән дә бәйләнгән иде. Әгъза буларак үкенерлек гамәлләр кылмадым, үкенмим. Хәзер дә хәлдән килгәнчә җәмәгать эшләрендә катнашам. Туган төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең конференцияләрендә чыгышлар ясыйм, туган авылым Яңа Шимбернең тарихын төгәлләп киләм.

Барыбыз да Аллаһы Тәгаләбезнең миһербанында булыйк.

P.S. 2002 елның 22 ноябрендә миңа «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Бу исем озак еллар (15 ел буе) радиода сөйләгән өчен. 2004 елның 25 нояберендә Татар халкы Милли мәҗлесе идарәсе карары белән «Татар халкының мәшһүр кызы» исеменә лаек булдым. Милли мәҗлес рәисе Габдулла Галиулла кул куйган документ өемдә саклана.

Күренекле галимә, журналыбызның актив авторы, чын татар зыялысы булган Тәэминә ханым Биктимированы олуг юбилее белән котлыйбыз, аңа исәнлек-саулык, яңа иҗади уңышлар теләп калабыз.

Зәйтүнә Тычинских

«ТИМЕР ТУЙ» УҢАЕННАН

Бекениннар гаиләсе 2025 елның 1 июлендә 65 еллык бергә яшәү юбилеен – «тимер туйларын» билгеләп үттеләр. Икесе дә сугыш балалары: әти-әниләре Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар.

Сөнгатулла Хәкимчан улы ун яшендә ятим кала, әнисе авырып үлеп китә. Әтисенең туганнары аны һәм 14 яшьлек апасын үзләренә алып яшәтәләр. Сөнгатулла Сатылган 7 еллык мәктәбен тәмамалагач, Тубыл педучилищесына укырга керә, 1957 елны аны тәмамлагач Тубыл районынының Урман авылына башлангыч мәктәп мөдире итеп билгеләнә. Армиягә аны алмыйлар, чөнки 1952 елда колхозда печән эшләгәндә аттан егылып, шуннан бирле уң як янбаш буыны зәгыйфь булып кала, 3 группа инвалидлык бирелә.

Урман авылында 1957–1958 уку елында яңа башлангыч мәктәп ачыла, ләкин Сөнгатуллага ул мәктәптә эшләргә туры килми, чөнки Азановлар гаиләсе урын алмашырга сорап мөрәҗәгать итәләр: Нәфисә апа туган авылы – Урман авылына кайтып эшләргә, ә Сөнгатулланы аның урынына Саз артындагы Тәпкен авылына барып эшләргә үтенәләр. Сөнгатулла риза була һәм Тәпкен башлангыч мәктәбенә укытырга китә. Тәпкен мәктәбендә өченче ел эшләп торганда икенче укытучы булып февраль аенда Уразметова Заһидә эшләргә килә. Уразметова Заһидә Алим кызы Омск өлкәсе Усть-Ишим районы Тибенде авылында 7 классны тәмамлап, Тара шәһәренең 8 нче урта мәктәбен 1958 елны тәмамлагач, Тубыл пединсти-

тутына филология факультетына укырга керә. Икенче курсның 1 семестрын бетергәч, эшләргә уйлап китә, чөнки стипендиягә генә яшәү авыр, әнисе колхозчы, акча ягы кыен була. Шул сәбәптән Тубыл районына барып эш сорагач, ул Тәпкен мәктәбенә икенче укытучы итеп билгеләнә. Пединститутны читтән торып укып бетерә.

1960 елның февраль аеннан ул Бекенин Сөнгатулла белән бергә эшли башлый. Уку елы тәмамлангач, алар бергә Тубыл шәһәренә кайталар. Ул заманда әле вертолет, самолетлар очмаган. Кышын ат белән, җәен күлләр, сазлар аша көймәләрдә генә һәм җәяүләп шәһәргә җитәргә мөмкин булган. Электр уты соңгы елларда гына яна башлады, элек керосин лампа яктысында гына мөмкин иде кичләрен эшләргә. Тормыш шартлары да бик авыр булган. 1960–1961 нче уку елыннан башлап Бекениннарны Лайтамак 7 еллык мәктәбенә күчерделәр. Ә 1960 елның 1 июлендә Сөнгатулла белән Заһидә кушылалар һәм гаилә корып яши башлыйлар. Лайтамак мәктәбендә Сөнгатулла физика, химия, математика фәннәрен, Заһидә ханым рус теле, әдәбияте һәм немец телен укыталар.

Бекениннар гаиләсе

Шулай итеп, Саз ягында Сөнгатулла ага 43 ел, ә Заһидә ханым 40 ел эшлиләр. Заһидә ханым шул эшләү чорында директор да, завуч та була, 1971 елны хәзер дә эшли торган мәктәпне төзетеп чыга. Укытып эшләгән чорларын сагынып искә алалар алар. Хайван да асраганнар, бакча да утыртканнар, Сөнгатулла ага балык та тоткан, үрдәген дә аткан. Һәрвакыт концертларда да катнашканнар. Җәйге отпускларда турпоезд белән төрле илләргә, җирләргә ел саен йөрегәннәр. Болгариядә, Кавказда, СССРның Европа өлешендәге шәһәрләрдә, Казанда курсларда берничә мәртәбә булырга туры килде, дип тә искә алдылар.

«Өч балалы булдык. Олысы Булат – Выборгта авиатехниклыкка укып, аэропортта авиатехник булып эшләде, аннан соң электрообмоточный цех ачып, эшмәкәр булып китте, кызганыч, аневризма аортыдан 52 яшендә дөнья куйды. Гөлшат кызыбыз (уртанчысы) Төмән университетында химия факультетын тәмамлап, Төмән мотор төзү заводында инде 36 ел химик лаборатория җитәкчесе. Иптәше Айрат кияү белән (башкорт егете) 35 ел яшиләр. Кече улыбыз Азат ГПТУ–11ны тәмамлап, «Югор» оешмасында изолировчы булып эшләгән иде, 41 генә яшендә геморогический инсульттан 25 көн комада ятып, исенә килә алмады» – дип сөйләделәр.

2001 елда Тубылга күчте бу галә, ике бүлмәле фатир сатып алдылар. 4 оныклары бар: 2 егет, 2 кыз. 4 оныкчыклары, барысы да малайлар.

Икесе дә шигырьләр язалар: Сөнгатулла аганың 5 китабы, Заһидә ханымның 1 китабы басылып чыкты.

Икесе дә хезмәт ветераны, Заһидә ханым – мәгариф отличнигы, РСФСР министерствосының грамотасы белән бүләкләнгән, тагын В.И. Ленинның 100 еллыгына дигән медале бар.

Сөнгатулла ага мәктәптә профсоюз комитеты рәисе, авыл советы депутаты вазыйфаларын да башкарды. 1958–1959 уку елының нәтиҗәләренә карап, Б. Сөнгатулланы һәм Вәчир мәктәбе мөдире А. Ризмөхәммәтне, түләүсез путевка белән бүләкләгәннәр иде. Ул путевка белән икесе дә Свердловск шәһәрендә ял итеп кайттылар.

Сөнгатулла аганың бүләкләре турында да әйтеп үтү кирәктер.

2015 елда Җиңүнең 70 еллыгына багышланган «Фронтовые дали» дип аталган район вокал конкурсында, автор-башкаручы номинациясендә 1 ст. диплом һәм приз белән бүләкләнде.

Экология елына багышланган 2017 елда III өлкә ачык вокал конкурсында («Сибирский соловей» дип аталган) 2-дәрәҗәле диплом һәм приз белән дә бүләкләнде ул.

2020 елда Тубыл шәһәренең традицион «И туган тел, и матур тел» ачык конкурсында үз шигырьләрен укып, 1 нче дәрәҗәле диплом һәм хәтер бүләгенә ия булды.

Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессы оештырган «Әниләр көненә» багышланган конкурста 1 нче дәрәҗәле диплом – хәтер бүләге белән бүләкләнде. «Яшьлеккә сәяхәт» ансамбле составында һәм аерым «Искер җыен» фестивалендә катнашып күптөрле дипломнар, мактауларга лаек булды. Үзенең һәм башка авторларның шигырьләренә көйләр иҗат итә. Барлыгы 34 җыр язган. Аларны җырлар җыентыгы итеп бастырды Сөнгатулла ага.

«Яшәсен Искер–җыен»ны исемлесен Искер–җыен халыкара фестиваленең гимны дип атарга тәкъдимнәр булды.

Сөнгатулла абыйның 5 медале, 26 дипломы, 28 грамотасы, 30 рәхмәт хаты, Заһидә ханымның 4 медале, 13 дипломы, 24 грамотасы, 32 рәхмәт хатлары бар.

Бу бәхетле картларга редакциябез исәнлек-саулык теләп кала!

Аналар хакында

Кайда гына син яшәсәң дә,
Онталмыйсың туган ягыңны.
Кайсы гына телдә әйтелсә дә,
«Әни» сүзе һәрчак ягымлы

Дөньяда һәрбер кешегә
Гомер бирә бит аналар
Бар кешелек дөньясында
Тормышның нигезе алар.

Хөрмәт итик хатын-кызны,
Зурлыйк без аналарны.
Шул гадәтләргә өйрәтик
Яшүсмер малайларны.

Аналарның йөрәк җылысы
Галәмнәргә барып җитәрлек;
Балаларга ана мәхәббәте
Гүя кояш – түгел бетәрлек.

Онытмагыз, дуслар, онытмагыз
Әнкәйләрнең йөрәк җылысын.
Ешрак кайтыйк туган өйләргә без
Рәхмәтләрнең әйтик олысын.

Онтылмасын иде сызлаулары
Йөрәкләре алган яраның;
Яшәсеннәр игелеген күреп,
Үзе үстергән һәрбер баланың.

Бекенин Сөнгатулла

ТӨБӘК ТАРИХЫ БУЕНЧА КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР ҺӘМ ОЧРАШУЛАР
ХАТЛАР ҺӘМ КАЙТАВАЗЛАР

КРАЕВЕДЧЕСКИЕ КОНФЕРЕНЦИИ И ВСТРЕЧИ
ПИСЬМА И ОТКЛИКИ

Бекиров Надир

ПОПЫТКИ ИСКОРЕНЕНИЯ ИМЕНИ КРЫМСКИХ ТАТАР ИЗ ИСТОРИИ КРЫМА ПОСЛЕ ДЕПОРТАЦИИ 1944 ГОДА

(Письмо в редакцию)

Акт тотальной депортации народов Советского Союза и ликвидации их национально-государственных образований уже давно и совершенно официально признан геноцидом. Однако международная Конвенция о предупреждении преступления геноцида и наказании за него в том виде, в котором она была принята ООН 9 декабря 1948 г. говорит о физическом уничтожении народа и других мерах, направленных на его физическое уничтожение. В ходе работы над Конвенцией из предварительного текста были убраны нормы об уничтожении по социальному признаку, а также о преднамеренном уничтожении культуры и национальной идентичности того или иного народа.

Однако прямой геноцид народа, расовой или этнической группы в истории, как правило, сопровождался и тем, что впоследствии в международно-правовой теории было обозначено как культурный геноцид или этноцид, под которым как раз и понимается уничтожение культурного наследия, фактических проявлений культуры и национального самосознания.

Не обошла эта человеконенавистная практика и крымских татар. Скорее всего многие знают, что через несколько лет после депортации, но в условиях, когда весь крымскотатарский народ находился в спецпоселениях, разбросанных по нескольким союзным республикам за тысячи километров от родной земли, в положении, которые в международном праве, действовавшем и тогда и сейчас, обозначаются как рабство, понес огромные потери (от 30 до 46% численность по разным оценкам); были категорически запрещены крымскотатарский язык и другие проявления культуры в официальной жизни СССР.

25 мая 1952 г. в Симферополе состоялась «Объединённая научная сессии Отделения истории и философии Крымского филиала Академий наук СССР по вопросам истории Крыма». Задавали тон на этом собрании лица, широко известные как «выдающиеся советские историки»: академик Б.Д. Греков, доктор исторических наук Б.А. Рыбаков, будущий директор Института этнографии СССР В. Бромлей. Среди того, что оглашалось на этой сессии, звучали и такие оценки истории Крыма: «*В довоенное время, в угоду татарским буржуазным националистам, в некоторых исторических работах совершенно необоснованно преувеличивалась роль Крымского ханства... Выступивший с докладом на эту тему доктор исторических наук Н.А. Смирнов убедительно показал, что турецко-татарское господство превратило Крым в наиболее отсталую в экономическом и культурном отношении территорию в Европе...*». В решении сессии указывается также на «*необходимость критического пересмотра научно-популярной и справочной литературы по истории Крыма, изданной в послевоенные годы*», говорится, что нужно «*переработать экспозиции крымских музеев в соответствии с новыми научными данными, усилить работу в области подготовки кадров историков Крыма...*».

Далее сказано следующее:

«8. *С особенной силой все отрицательное влияние кочевников на развитие Крыма сказалось в эпоху татарского господства, длившегося здесь на три столетия больше, чем на Руси. Татары Крымской орды превратили полуостров в придаток своего экстенсивного полукочевого хозяйства... Крымское ханство было таким же паразитарным государством, как в свое время Хазария...*» А в 17 пункте решений сессии говорится: «*Значительное внимание буржуазная историография уделяла истории крымских татар; выяснялись земельные владения беков, доверчиво изучались ханские ярлыки, носящие явные следы фальсификации, преувеличивалось значение и высокий уровень татарского искусства. История Крымского ханства не рассматривалась как история паразитического государства, жившего за счет набегов и работорговли и тормозившего развитие земледельческого населения степей* (*казачества*) *и Крыма*».

Соответственно одной из важнейших задач ставилась: «*Заново пересмотреть историю кочевников, очистив ее от идеализации Хазарии, половцев и Крымского ханства*». По сути в середине XX в. откровенно указывалась цель проведения культурного геноцида коренного народа Крыма, которая подводила к тому, чтобы отрицать самое его существование, что выглядело вполне достижимым, поскольку еще в 1948 г. было принято официальное решение о том, что высылка и содержание в специальных поселениях осуществлена для крымских татар навечно.

Обращает на себя внимание, что нечто очень похожее состоялась 6 годами ранее, на сессии Академии наук СССР 25–26 апреля 1946 г. в Москве, где почти с тех же позиций был произведен погром истории «казанских» татар. Не случайно, думается, возглавлял его тот же самый академик, директор Института истории и Института истории материальной культуры АН СССР Б.Д. Греков. «*Целью конференции являлась разработка мер по реализации положений постановления Центрального комитета Всесоюзной Коммунистической партии* (*большевиков*) *от 9 августа 1944 г.* «*О состоянии и мерах улучшения массово-политической и идеологической работы в Татарской партийной организации*», *которым предписывалось* «*устранить допущенные отдельными историками и литераторами серьезные недостатки и ошибки националистического характера в освещении истории Татарии* (*приукрашивание Золотой Орды, популяризация ханско-феодального эпоса об Идегее*)».

Однако участие в этом собрании собственно татарских и некоторых, не потерявших еще совесть и человеческую сущность историков, позволило избежать тотального выкорчевывания из истории Татарстана как важных этапов в становлении татарского народа периодов Золотой Орды и Казанского ханства, так и превращения этнонима народа в предмет охаивания и уничтожения. «*В сформулированных докладчиками выводах и положениях татарские историки видели выход из ситуации огульного очернения прошлого татарского народа, которое, по существу, являлось средством духовного гнета каждого его представителя, начиная от школьников, только что приступающих к изучению отечественной истории, до студентов вузов и специалистов различных отраслей народного хозяйства*».

Обращает на себя внимание некий парадокс: крымских татар депортировали еще 18 мая 1944 г., а «теоретическое» обоснование необходимости погрома их истории и культуры состоялось только в 1952 г. Применительно к Татарстану же это произошло в 1946 г. В чем тут дело? Думается, что если не четкий ответ, то по крайней мере, явный ориентир – это дата постановлена ЦК ВКП(б), давшего старт этой попытке – 9 августа 1944 г. – спустя практически ровно три месяца с совершенно секретного Постановления ГКО «О крымских татарах», ставшего псевдоправовым основанием для депортации крымскотатарского народа, принятого 11 мая того же года.

В кругах людей того поколения до сих пор ходят разговоры о планах по депортации татар Поволжья, которое, к счастью, не состоялось. Очередная физическая расправа над целым татарским народам была заменена идеологической экзекуцией и, безусловно, сильнейшим давлением

на национальное самосознание и идентичность казанских татар, недвусмысленным намеком интеллигенции и политическому руководству республики, что может случиться, если «они не сделают правильных выводов» о том, кто такие татары, и как должны себя вести.

За крымских же татар принялись, когда убедились, что народ все же физически выжил, и надо готовить некие «научные» основания к тому, чтобы идеологически обосновать как закрыть ему, неожиданно выжившему путь домой навсегда.

После смены политического режима в СССР, смерти И. Сталина, прихода к власти Н. Хрущёва, в судьбе депортированных и подвергнутых геноциду народов вроде бы наметились перемены к лучшему. Так, 28 апреля 1956 г. Президиум Верховного Совета СССР издал указ «О снятии ограничений по спецпоселению с крымских татар, балкарцев, турок – граждан СССР, курдов, хемшилов и членов их семей, выселенных в период Великой Отечественной войны». Что это было за «снятие» следует из текста самого указа: «*Установить, что снятие ограничений по спецпоселению с лиц, перечисленных в статье первой настоящего Указа, не влечет за собой возвращение им имущества, конфискованного при выселении, и что они не имеют права возвращаться в места, откуда были выселены*».

Вдогонку этому указу появилось и Постановление ЦК КПСС от 24 ноября 1956 г. «О восстановлении национальной автономии калмыцкого, карачаевского, балкарского, чеченского и ингушского народов». Применительно к крымским татарам в нем был пункт 6: «*Признать нецелесообразным предоставление национальной автономии татарам, ранее проживавшим в Крыму, имея в виду, что бывшая Крымская АССР не была автономией только татар, а представляла собой многонациональную республику, в которой татары составляли менее одной пятой части всего населения, и что в составе РСФСР имеется татарское национальное автономное образование – Татарская АССР, а также то, что в настоящее время территория Крыма является областью Украины и заселена.*

Вместе с тем, учитывая стремление части татар, ранее проживавших в Крыму, к национальному объединению, разъяснить, что все, кто пожелает, имеют право поселиться на территории Татарской АССР. Обязать Совет Министров Татарской АССР и Татарский обком КПСС оказывать необходимую помощь в хозяйственном и трудовом устройстве татарского населения, которое будет прибывать на постоянное местожительство в республику».

Я сам родился в Казани в 1962 г., потом жил в Башкортостане, и 11 лет, до возвращения в Крым учился и работал в Казанском государственном университете, так что могу подтвердить, что ни Татарская АССР, ни поз-

же Татарстан, не делали никаких попыток реализовать это бесчеловечное решение. Скорее наоборот, общественность, интеллигенция и государственные органы Татарстана делали, что могли, чтобы помочь крымским татарам вернуться и наладить свою жизнь в Крыму, когда это стало возможно. Не так уж много зависело от них в этом вопросе…

Однако, в руках недобросовестных лиц, родство и сотрудничество между крымскими и поволжскими татарами используется, как это ни странно, в тех же целях, которые провозгласили в 1952 г. «научные» обоснователи коммунистической пропаганды: «Крым без крымских татар!» Некоторая часть людей, которые сделали себе имя и карьеру как представители крымскотатарской интеллигенции (среди них есть и люди с высшим филологическим образованием и даже учеными степенями), несколько десятилетий вбрасывают в крымскотатарский народ совершенно дикую и не основанную ни на чем, кроме их собственных домыслов, идею о необходимости срочного и добровольного переименования народа из крымских татар в «крымлы» или, как вариант, «крымов».

На эту тему я неоднократно выступал в печати, несколько лет назад опубликовал статью с тщательным разбором всех их аргументов, более двадцати крымскотатарских ученых провели специальную конференцию по этому вопросу, куда приглашали и идеологов «крымлыйства». Но от участия в ней они отказались, как и ранее убегая от честной научной дискуссии. Поэтому повторяться здесь не буду, скажу только, что цинизм этих людей заключатся в том, что они сами до сих пор для пропаганды своих идей используют газеты, каналы телевидения и интернета, ради популярности в народе, для того чтобы с полуоборота не оттолкнуть от себя крымских татар, сами же именуют себя «крымскотатарскими» (иногда не просто именуют, а прямо-таки настаивают на том, что они и есть «первые крымскотатарские»). Хотя в них же и они агитируют за свои сумасбродные и опасные для национального достоинства и всей будущности народа намерения.

Но еще более циничным является то, что «крымы», как и «крымлы» (еще вариант – «крымлыдес») является действующим самоназванием другого народа, насчитывающего десятки тысяч человек – крымских цыган – которые веками жили и живут в Крыму, а теперь уже и по всей России, со своим собственным языком, историей, культурой, обычаями, национальной идентичностью.

Надеюсь, что эта очередная попытка искоренить имя крымских татар из истории Крыма окажется такой же несостоятельной, как и все предыдущие.

И.Р. Утямышев

ВОЗВРАЩЕНИЕ К ИСТОКАМ

Одна из старейших в республике кирпичных мечетей, построена в 1791 г. на средства купца Габдуллы Утямышева. д. Маскара Кукморского района РТ.

Время неминуемо движется вперед. Меняется окружающий нас мир, преображаются города, природные ландшафты. Знакомая нам окружающая обстановка принимает другие очертания, оставаясь прежней лишь в воспоминаниях, иногда идеализированной, часто помимо нашего желания. Меняются люди, большинство из нас старается приспособиться к жестким внешним условиям, пытаясь выжить в сложной непрогнозируемой ситуации. Таковы реалии нового века с его непростыми требованиями. Однако, преемственность в развитии есть важное условие в предотвращении разрушительных процессов в обществе, принятия неверных непоправимых решений. Каждый человек проходит свой путь развития – уникальный и неповторимый с одной стороны и, в то же время, имеющий много общего с другими в его временном восприятии.

Период наибольшей жизненной активности всегда воспринимается как наилучший, хотя налицо технический прогресс, который дает много

неоспоримых возможностей, освобождает от громоздкой, рутинной работы, дает ощущение комфорта. Наиболее существенным и бесценным является период общения с близкими нам людьми, который начинается в раннем детстве и завершается с их уходом из этого мира. Размываются контуры прошедших событий, стираются детали, но неизменно остаются люди, их неугасающая теплота, неповторимые характеры. Несмотря на то, что в данный момент их уже давно нет рядом с нами, мы невольно соотносим свои действия с ними, продолжая познавать их. Эта незримая глубокая духовная связь и есть основа преемственности, которая хранится в нашей памяти.

По прошествии лет мы стали больше и глубже понимать родителей и других более ранних предков, их поступки, казавшиеся непонятными с точки зрения современных взглядов. Возможно, с возрастом многие моменты, казавшиеся незначительными, на которые не обращаешь внимания, становятся более важными и близкими.

6 июня 2025 г. в д. Маскара Кукморского района Татарстана после реставрации открылась Соборная мечеть Утямышевых, построенная в 1791 г. Это одна из старейших мечетей в республике. Изначально она имела минарет высотой 46 метров. Внутренние помещения имели красивую разноцветную роспись на стенах и потолке.

Деревня Маскара (Кукморский район) возникла в начале XVI в. Ее родоначальником был Ишман, служилый человек из Касимова, который ведет свое начало от Сулеймана (р. 1410 г.). От него ведет свое начало фамилия Утямышевых.

